أصول الإيمان

# ИМАН НИГЕЗЛӘРЕ

# ИМАН НИГЕЗЛӘРЕ

Төзәтелгән, икенче басма

«Даура» редакциясы
2024

УДК 297.18
ББК 86.38

**«Даура» редакциясы**

**Иман нигезләре** / «Даура» редакциясы, икенче басма, Зәйнуллин Р.Ф. редакциясе астында; урыс теленнән тәрҗемә: Сөләйман Солтан Кормаши. — Даура, 2024. — 128 б.

Бу хезмәт — бар мөселман дөньясына таныш булган мәшһүр галимнәребезнең хезмәтләренә таянып — Изге Коръән, пакь Сөннәт һәм беренче буын мөселманнары иман төшенчәсен ничек аңлаган, шул аңлауга нигезләнгән дөрес ислам инанулары хакында сөйли.

Әлеге китап ислам дини тәгълиматының нигезе булган гыйлемнең тиешле минимумын тәшкил итә һәм аларның һәрберсенә аңлатма бирә.

Ислам дине нигезе белән кызыксынучы киң даирә укучылар өчен каралган.

Нәшер итүченең язма рөхсәтеннән башка коммерция максатларында күчереп алу һәм тиражлау тыела!

© Даура, 2024
Email: *daura.publishing@gmail.com*

# Кереш сүз

Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка мактаулар, пәйгамбәрләрнең һәм илчеләрнең иң яхшысы булган Мөхәммәдкә сәламнәр һәм салаватлар булсын һәм соңыннан:

Күпләребезнең бала чагында өлкән буын кешеләрдән: «Иманлы булып үс, балам!» — дип әйткәннәрен ишеткәнебез бар. Бала чакта бу сүзләрнең мәгънәсен аңламасак та, аларның шушы догалары астында безгә бары тик яхшылык кына теләүләрен чамалый идек. Ә бит, фикерләп карасак, шушы сүзләрдә хаклык, никадәр тирән мәгънә салынган икән! Шуңа күрә дә аларның безгә муллык, сәламәтлек, яхшы билгеләргә уку ише теләкләрдән дә иң алда иман теләүләре юкка гына булмагандыр.

Мөселманнар өчен сер түгел, иман бик зур әһәмияткә ия, мөһим роль уйный һәм иман китергән кеше өчен бу тормышта да, Ахирәт тормышында да зур файда китерә. Әле ул гына да түгел, кеше белән бу тормышта да, Ахирәттә дә нинди генә яхшылык, хәерлелек булмасын, моның нигезе иманның дөреслегенә кайтып кала. Дөрес иман сәбәпле Аллаһ колының яшәеше бәракәтле, бәхетле була, ул күңелсезлекләрдән, явызлыклардан һәм бәхетсезлекләрдән котыла һәм Ахирәт тормышта мәңге бетми һәм аны беркайчан

да калдырмый торган бетмәс-төкәнмәс әҗергә лаек була. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Ир кешеме ул, хатын-кызмы, кем иман китергән килеш изге гамәлләр кылса, Без аны, һичшиксез, матур тормышта яшәтәчәкбез һәм** (Ахирәттә) **кылган гамәлләреннән күркәмрәк әҗерне бирербез»** «Ән-Нәхел», 97.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Һәм кем иман китергән хәлдә Ахирәтне теләп Ахирәт өчен тырышса** (Аллаһка буйсынса)**, аларның тырышлыгы шөкерлек белән кабул кылыныр** (югары бәяләнер)» «Әл-Исра» , 19.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Кем иман китергән хәлдә изге гамәлләр кылып Аның каршына килә, аларга** (Ахирәттә) **олуг дәрәҗәләр әзерләнгән»** «Та ha» сүрәсе, 75.

Коръәндә моның хакында сөйләүче аятьләр бик күп.

Кадерле укучы! Синең кулыңда — «Иман нигезләре» китабы. «*Иман*» сүзе «ышану», «тану», «раслау» дигәнне аңлата. Аллаһның Илчесе ﷺ «*Иман*»ның нәрсә икәнлеген аңлатып биреп: «***...Иман — Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Аның китапларына, Аның пәйгамбәрләренә, Кыямәт көненә, тәкъдирнең яхшысына да, яманына да ышануың ул***» — диде. Мөслим, 8.

Шулай итеп, иман югарыда санап киткән алты баганадан тора. Шушы алты баганага — Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Аның китапларына, Аның пәйгамбәрләренә, Кыямәт көненә, тәкъдирнең яхшысына да, яманына да ышанмый торып, беркем дә иман китергән булып исәпләнмәячәк икән. Шуңа күрә һәр мөселман кешесе шушы баганаларга карата игътибарлы булырга, аларны өйрәнергә һәм тормышында кулланырга тиешле.

Бу хезмәт — бар мөселман дөньясына таныш булган мәшһүр галимнәребезнең хезмәтләренә таянып — Изге

Коръән, пакь Сөннәт һәм беренче буын мөселманнары *иман* төшенчәсен ничек аңлаган, шул аңлауга нигезләнгән дөрес ислам инанулары хакында сөйли.

Кадерле укучы! Без сине шушы иман нигезләре белән танышу сәяхәтенә чакырабыз. Әлеге китап белән танышып сез үзегезгә бик күп файдалы мәгълүматлар алырсыз, борчыган, кызыктырган сорауларыгызга җавап табарсыз дип ышанып калабыз.

Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка мактаулар булсын! Аллаһ Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә, аның гаиләсенә һәм сәхабәләренә салаватларын һәм сәламнәрен насыйп итсен!

# Дин — ул Аллаһка гыйбадәт кылу кагыйдәләре җыелмасы

Аллаһ Тәгалә — Бар кылучы, Белүче, Хикмәт Иясе. Үзенең барнәрсәне чолгап алган гыйлеме, хикмәте, чиксез кодрәте сәбәпле шушы бөек галәмне бар кылды һәм анда тәртип урнаштырды. Бу халык кылу юкка гына, уен-көлке өчен генә түгел, ә Үзенең иләһи теләген тормышка ашыру өчен бар кылынды. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Без Күкләрне, Җирне һәм алар арасында булган нәрсәләрне күңел ачу өчен генә яралтмадык. Бөтенесен дә бары тик бер сәбәп белән** (Аллаһның хакыйкате) **яралттык. Ләкин аларның күбесе моны аңламый**» «Әд-Духан», 38-39.

Ул җеннәрне һәм кешеләрне халык кылды һәм аларның барлыкка килүләренең бөек хикмәте һәм күркәм максатлары хакында хәбәр итте:

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне бары тик Миңа гына гыйбадәт кылсыннар өчен яралттым. Мин алардан ризык сорамыйм, Мине ризыкландыруларын да сорамыйм. Хактыр ки, Аллаһ Үзе ризыкландыручы, чиксез кодрәт иясе»** «Әз-Зәрият», 56-58.

**«Ий, кешеләр! Сезне һәм сездән элек булган кешеләрне халык кылган Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз! Бәлки, тәкъва кешеләрдән булырсыз. Ул сезнең өчен Җирне бер ястык кебек түшәде, күкне бина кылды, сезнең өчен күктән яңгыр яудырды һәм җирдә сезгә ризык булсын өчен җимешләр үстерде. Шуңа күрә, белеп торган килеш, сез Аллаһка тиңдәшләр кылмагыз»** «Әл-Бәкара», 21-22.

Раббыбыз адәм баласына дөньяның барлыкка килүенең хакыйкатен аңлауны җиңеләйтте һәм ярдәм итте, шуның белән Ул Үзенең колларына карата булган зур рәхмәтен күрсәтте. Бу хакыйкать — Аллаһның бар икәнлеге һәм Ул бар нәрсәнең дә Халык кылучысы, ә кеше дигән зат — аның мәхлугы икәнлегендә. Бу хакыйкать — кешеләрнең барлыкка килүләренең максаты — бары тик Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылулары икәнлегендә. Моны Аллаһ Тәгалә барлык кешеләргә дә йөкләде, шуңа күрә барча кешеләр дә, телиләрме-юкмы, Аллаһның коллары булып торалар.

Аллаһ тарафыннан хакыйкатьне аңлауда күрсәтелгән җиңеллек һәм ярдәм шуннан гыйбарәт:

**1.** Аллаһ кешене тумыштан ук килгән сыйфат (*фитри иман*) белән бар кылган, шуның сәбәпле ул бары тик бер генә иләһ барлыгын һәм адәм баласы Аның әмерләренә буйсынып, Аңа гына гыйбадәт кылып яшәргә тиеш икәнлеген тоя. Әгәр дә ул кешеләрнең йогынтысына бирелмәгән булса, һичшиксез, үзенә салынган инстинктына иярер иде. Ләкин, кешедә булган нинди дә булса җитешсезлекләр, теге яисә бу кешеләргә охшарга тырышуы аны бу юлдан читкә тайпылдыра.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Ихластан, хәниф** (Аллаһка гына гыйбадәт кылучы) **булган хәлдә йөзеңне дингә юнәлт. Аллаһның кешеләрдә тумыштан ук бар кылган сыйфат шушы. Аллаһ халык кылган нәрсәдә үзгәреш юк. Хак иман — шушыдыр, ләкин күп кешеләр моны аңламый**» «Әр-Рум», 30.

Әбу Һурәйрадан хәбәр ителгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Һәрбер адәм баласы тумыштан ук бер Аллаһка гына гыйбадәт кылу халәтендә туа*** *(фитри иман),* ***ә соңыннан инде аның әти-әнисе аны яһүди, я насара, я утка табынучы итә. Хайваннар да бит үз балаларын бөтен һәм исән-имин килеш таба. Берәрсенең киселгән борын белән туганын күргәнегез бармы сезнең? Соңыннан Әбу Һурәйра Аллаһ Тәгаләнең сүзләрен укыды:*** **«Аллаһның кешеләрдә тумыштан ук бар кылган сыйфат шушы»** «Әр-Рум», 30**».** Әл-Бохари, 1359, 1385, 6599; Мөслим, 2658.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Бөек Аллаһ бүген Үзе миңа өйрәткән, сез белмәгән нәрсәне сезгә өйрәтергә әмер итте: «***Колларыма бүлеп биргән бар байлык та аларга рөхсәт ителгән***[1]***. Мин барча колларымны да Миңа буйсынучан итеп бар кылдым. Әмма шәйтаннар килеп аларны диннәреннән тайпылдырдылар, Мин аларга рөхсәт иткән нәрсәләрне тыйдылар һәм бернинди нигезсез Минем белән янәшә ялган иләһләргә гыйбадәт кылырга куштылар***»» Мөслим, 4/2197.

**2.** Аллаһ кешене акыл белән бизәде. Шуның аша ул һәрнәрсәне дә барлыкка китергән Халык кылучы бар икәнле-

[1] Мөшрикләр, җаһилияттән килгән гадәт белән, дөянең һәм сарыкның кайбер төрләрен, махсус, корбан чалу өчен генә асраганнар, андый хайван итен ашау кешегә хәрам булган. (Ибн Кәсир, 4/482). Аллаһ Тәгалә әйтә: «**Әй, сез кешеләр! Җирдәге (күңелегез теләгән бөтен хәләл, пакь) ризыкларны ашагыз! Берүк, (хәләл булган ризыкларны, хәрам диеп үзегезне тыймагыз, шулай итеп) шәйтан эзләреннән китә күрмәгез. Ул бит сезнең ачык дошманыгыз**» («Әл-Бәкара», 168).

ген аңлый. Акыл аша адәм баласы әйләнә-тирәсендә булган аятьләрне (иманга этәрә торган билгеләрне) күзәтергә, алар хакында уйланырга сәләтле.

Дөнья кисәкләре, җиһанда корылган күк, җир, йолдызлар, планеталар, кояш, ай, таулар, агачлар, диңгезләр, елгалар, безне бөркәп алган төн, көн һәм галәмнәрдә урнаштырылган абсолют, камил тәртип хакында фикерләп караган һәрбер акыл иясе дә шушы галәмнәрнең киң Кодрәтле, бөек Халык кылучысы, алар белән Идарә итүчесе бар икәнлеген аңлар. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Тиздән Без, моның** (Коръәннең) **хак икәнлеге ачык булганчыга кадәр, аларга** (мөшрикләргә) **дөнья буйлап һәм аларның үзләрендә үк Үзебезнең аятьләребезне күрсәтербез. Раббыңның һәрнәрсәгә шаһит булганлыгы җитмиме?**» «Әл-Фуссыләт», 53.

**3.** Аллаһ адәм балаларына пәйгамбәрләр җибәрде. Ул пәйгамбәрләр аларны бар кылучы — Аллаһ, Ул гына гыйбадәт кылырга лаеклы һәм Аннан башка гыйбадәт кылына торган барча нәрсәләрдән дә ерагаерга кирәклеге хакында сөйләделәр. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**«Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз үә ялган иләһләрдән ваз кичегез!» — дип әйтсеннәр өчен, Без һәрбер өммәткә дә илчеләр җибәрдек**» «Ән-Нәхел», 36.

Шулай ук Аллаһ әйтте:

«**«Миннән башка гыйбадәткә лаеклы бер иләһ тә юк! Шуңа күрә Миңа гына гыйбадәт кылыгыз!» — дигән дөреслекне вәхий итмичә, Без синнән әүвәл бер генә пәйгамбәр дә җибәрмәдек**» «Әл-Әнбия», 25.

Шулай итеп, Аллаһның шушы ярдәме сәбәпле, кеше дигән зат аңа бирелгән акыл аша бер генә иләһкә гыйбадәт кылырга кирәк икәнлеген йөрәге белән аңлый. Һәм нәкъ менә Үзенең расүлләре аркылы Аллаһ Тәгалә колларының

ни рәвешле итеп Аңа гыйбадәт кылырга кирәк икәнлеген хәбәр итте.

Аллаһка гыйбадәт — ул Аллаһка Үзе әмер иткән гамәлләрне кылып буйсыну һәм Ул тыйган гамәлләрне эшләүдән баш тарту. Кешенең теләсә кайсы гамәле яки сүзләрдә, яки эшләрдә чагыла. Эшләр, үз чиратында, билгеле, ягъни, тирә-юньдәгеләргә тышкы яктан күренеп тора торган һәм яшерен — кешенең йөрәгендә була торган булырга мөмкин.

Шулай ук, «*гыйбадәт*» төшенчәсенә шушындый билгеләмә дә бирергә була.

*Гыйбадәт* — ул Аллаһ яраткан һәм разый булган билгеле һәм яшерен барлык сүзләр һәм гамәлләр.

Аллаһ безгә Коръәндә, Сөннәттә әмерләр һәм тыюлар формасында иңдерелгән сүзләрне һәм гамәлләрне яратканын хәбәр итте.

*Дин* — ул Бөек Аллаһның әмерләрен һәм тыюларын үз эченә туплаган, бердәнбер Аллаһка гыйбадәт кылу кагыйдәләре җыелмасы.

Һәм Аллаһ Үзенең динен «*Ислам*» дип атады.

«**Дөреслектә, Аллаһ дине — Исламдыр**» «Әли-Гыймран», 19.

«**Кем дә кем, дин итеп, үзенә Ислам диненнән башканы теләсә, ул дин аннан кабул ителмәс һәм ул Ахирәттә отылучылардан булыр**» «Әли-Гыймран», 85.

«*Ислам*» сүзенең мәгънәсе: Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылу аша Аңа бирелү, дини бурычларны үтәү аркылы Аңа буйсыну, ширек һәм ширек әһелләреннән ерак булу.

# Йөрәк гамәлләре — гыйбадәтнең асылы

Без Аллаһка гыйбадәтне, Ул күрсәткән билгеле һәм яшерен булган сүз-гамәлләрдә чагыла дип искә алган идек.

Билгеле булган гамәлләргә: намаз, хаҗ, садака, әти-әниләргә, мөселман җитәкчеләргә хөрмәтле мөнәсәбәт, мөселманнарга ярдәм, корбан чалу һәм башка күп гамәлләр керә.

Ә яшерен гамәлләр — болар инде мәхлукатларның берсенә дә билгеле булмаган йөрәк гамәлләре. Бары тик Биек һәм Бөек Раббыбыз гына кешеләрнең йөрәкләрендә ни барлыгын белә:

«**Аллаһ аларның йөрәкләрендә ни барлыгын белә**» «Ән-Нисә», 63.

Йөрәк гамәлләреннән боларны атап була: Аллаһка иман, Аның фәрештәләренә иман, Аның китапларына иман, Аның пәйгамбәрләренә иман, Кыямәт көненә иман, тәкъдирнең яхшысына да, яманына да иман, Аллаһка мәхәббәт, Аллаһка тәвәккәл кылу, Аллаһның җәзасыннан курку, Аллаһның гафу итүенә өмет итү, Аллаһка ярдәм сорап дәшү, Аллаһка сыгыну сорап мөрәҗәгать итү, Аллаһ каршында тәүбә кылу, Аллаһ каршында ихласлык, дога белән Аллаһка дәшү.

Йөрәк гамәлләренең, гомумән, бар диннең дә асылы булып Аллаһка иман китерү һәм Ул нәрсәгә иман китерергә әмер иткән — шуңа иман китерү тора. Болардан башка гамәлләрнең мәгънәсе юк.

Аллаһ Тәгалә безгә йөрәгебез белән алты нәрсәгә иман китерергә әмер итте:

1. Аллаһка иман;
2. Аның фәрештәләренә иман;

3. Аның китапларына иман;

4. Аның пәйгамбәрләренә иман;

5. Кыямәт көненә иман;

6. Тәкъдирнең яхшысына да, яманына да иман.

Галимнәр боларны «Иманның алты баганасы» дип атады.

«**Ий, иман китергәннәр! Аллаһка, Аның Расүленә, аңа иңдерелгән Китапка, аннан алда иңдерелгән Китапларга да иман китерегез**» «Ән-Нисә», 136.

«(Гыйбадәтләрегездә) **Йөзегезне Көнчыгыш яки Көнбатышка таба юнәлдерүегез — изгелек кылу түгел. Чын изгелек ул — Аллаһка, Кыямәт көненә, фәрештәләргә, китапларга һәм пәйгамбәрләргә ышану**» «Әл-Бәкара», 177.

«**Ә кем дә кем Аллаһны, Аның фәрештәләрен, Аның китапларын, Аның илчеләрен һәм Ахирәт көнен инкарь итсә, ул хаклыктан бик ерак адашу белән адашкан була**» «Ән-Нисә», 136.

Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «***...Иман — Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Аның китапларына, Аның пәйгамбәрләренә, Кыямәт көненә, тәкъдирнең яхшысына да, яманына да ышануың ул***», — диде. Мөслим, 8.

Гарәп телендә «*иман*» сүзе «*әмәнә*» дигән фигыльдән ясалган, «ышану», «тугры булу», «ышанычлы» мәгънәсен аңлата.

Гарәп теле галимнәре әйтүенчә, «иман» сүзенең мәгънәсе — тану, раслау. Адәм баласының әлеге алты баганага ышануы — аларны йөрәк белән тану, инану. Шуңа күрә дә бу алты баганага инану йөрәк гамәлләренә керә.

Кешенең барлык гыйбадәте дә әлеге алты баганага инануда төзелә һәм бу — диннең асылы инде. Кеше теге яки бу төр гыйбадәтне кылганда, шушы алты баганага ышану һәрвакыт аның янәшәсендә. Адәм баласын билгеле яки яшерен булган гамәлләрне кылырга нәкъ менә шушы ина-

ну ашкындырып тора. Алда әле без йөрәк гамәлләренең барчасы да Аллаһка иман китерүгә нигезләнгәнлеген, аның белән аерылгысыз бәйләнгәнлеген күрербез.

# Йөрәк гамәлләренең төрләре

## Аллаһка мәхәббәт

Мәхәббәт — йөрәк гамәлләренең иң әһәмиятлесе булып тора, чөнки бер Аллаһны Аның бар булганы өчен генә дә ярату тиешле. Аллаһ колларының Аңа карата булган мәхәббәтләре Җәннәткә кергәч тагын да артачак кына, курку һәм аңа китерә торган сәбәпләр юкка чыккан булачак, чөнки Җәннәткә кергәннәр куркуны да, сагышны да белмәячәкләр.

Иман китергәннәрнең Аллаһка карата булган мәхәббәтләре хакында Раббыбыз Үзе дә, аның илчесе дә ﷺ әйтте. Мәсәлән, Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Кешеләр арасында шундыйлар бар, алар Аллаһтан башкаларны Аңа тиңдәш итәләр** (ширек кылалар) **һәм шуларны да** (үзләренең ялган иләһләрен) **Аллаһны сөйгән кебек сөяләр. Әмма иман китерүчеләрнең Аллаһны сөюләре күпкә көчлерәк**» «Әл-Бәкара», 165.

Шулай ук Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**...Ул аларны яратыр, алар да Аны яратырлар...**» «Әл-Мәидә», 54.

Ике «Сахих» җыентыгында да килгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Өч сыйфат белән аерылып торган кеше иманның ләззәтен татыр: Аллаһны һәм Аның илчесен барча нәрсәдән дә артык сөюче, теге яки бу кешене бары тик Аллаһ ризалыгы өчен генә яратучы һәм утка алып ташлауларын теләмәгән кебек, көферлеккә дә кире әйләнеп кайтырга теләмәүче***». Әл-Бохари, 16; Мөслим, 43.

Әле тагын Аллаһ Тәгалә Аңа буйсынучы колларын ярату хакында белгертте.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**...Аллаһ Ибраһимны Үзенә яраткан бәндәсе итеп алды**» «Ән-Нисә», 125.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Изгелекләр кылыгыз, Аллаһ изгелек кылганнарны сөя**» «Әл-Бәкара», 195.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...Аллаһ тәкъва булганнарны ярата**» «Әли-Гыймран», 76.

Моныңише мисалларны бик күп китереп була.

Аллаһ Тәгалә үзләренең Аллаһка карата булган мәхәббәтләре хакында белдерүчеләргә дөреслек мизаны барлыгына күрсәтте.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«(И, Мөхәммәд, син аларга болай дип) **Әйт: «Әгәр сез Аллаһны яратасыз икән — миңа иярегез, менә шул вакытта сезне Аллаһ яратыр...»**» «Әли-Гыймран», 31.

Башка төрле итеп әйтсәк, Аллаһка булган мәхәббәт, һичшиксез, Аллаһның илчесенә ﷺ иярүне күз алдында тота, ә Аллаһның илчесенә ﷺ ияру, һичшиксез, Аллаһның Үз колын ярата башлавына китерә.

Чын мәхәббәт — ул сине яратучы затка ярарга, аны канәгатьләндерергә омтылып торудан гыйбарәт. Ә бу исә ул яраткан нәрсәне ярату һәм ул сөймәгән нәрсәне сөймәүдә чагыла.

## Аллаһның газабыннан курку

Аллаһ Тәгалә куркуны һәркемнең бурычы итеп йөкләде һәм әйтте:

«**Әгәр сез иман әһелләре булсагыз, алардан түгел, ә Миннән** (генә) **куркыгыз!**» «Әли-Гыймран», 175.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«һәм бары Миннән генә куркыгыз!»** «Әл-Бәкара», 40.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Сез кешеләрдән түгел, ә Миннән куркыгыз»** «Әл-Мәидә», 44.

Аллаһ Тәгалә Аның каршында курку кичергәннәргә мактап бәя бирде:

**«Дөреслектә, Раббыларының газабыннан курыкканнар, аятьләренә** (иманга этәрә торган билгеләренә) **иман китергәннәр, Раббыларына тиңдәшләр кылмаганнар, Раббылары янына кайтарылачакларын белеп, куркып садакаларын ихлас күңелдән кайтарганнар — алар барысы да изгелекләр кылырга ашкынып торалар һәм бер-берсен шушы юлда уздырырга тырышалар»** «Әл-Муэминун», 57-61.

Әт-Тирмизи һәм Әхмәд җыентыкларында килгән хәдистә, Гаишә (Аллаһ аннан разый булсын) болай сөйләде: «Көннәрдән бер көнне мин: «Йә, Аллаһның илчесе, Аллаһның: «**...куркып, садакаларын ихлас күңелдән кайтарганнар...**» сүзләре зина кылган, хәмер эчкән, урлашкан кешеләрне күздә тотып әйтелгәнме?» — дип сорадым. Ул: «***Юк, и, Әс-Сиддык кызы! Монда сүз уразаларын тоткан, намазларын укыган, мохтаҗларга мал тараткан-нарның шушы гамәлләре кабул кылынмас дип куркулары хакында***»»[1].

## Аллаһка өмет

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Дөреслектә, иман китергән кешеләр, йортларыннан күчеп китеп Аллаһ юлында барлык көчен сарыф иткәннәр — Аллаһның Рәхмәтенә өмет итәләр. Аллаһ —** (гөнаһларны) **Кичерүче, Рәхимле»** «Әл-Бәкара», 218.

---

[1] Әт-Тирмизи, 3175; Ибн Мәҗәһ, 4198. Сахих хәдис, «Әс-Силсилә әс-Сахийхә», 162.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Кем Аллаһ белән кавышуга өмет баглый, белеп торсын, Аллаһ билгеләгән ул вакыт, һичшиксез, киләчәк. Аллаһ — Ишетүче, Белүче**» «Әл-Гәнкәбут», 5.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Кем дә кем Раббысы белән кавышырга өмет итә — изге гамәлләр кылсын һәм Раббысы белән янәшә беркемгә дә гыйбадәт кылмасын**» «Әл-Кәһф», 110.

Мөслимнең «Сахих» җыентыгында Җәбирдән (Аллаһ аннан һәм әтисеннән разый булсын) килгән хәдистә әйтелә: «Аллаһның илчесе ﷺ үләренә өч көн кала: «***Сезнең барчагыз да үз үлемен Раббысыннан бары тик яхшыны гына көтеп каршы алсын***», — диде». Мөслим, 2877.

Әл-Бохариның «Сахих» җыентыгында Әбу Һурәйрадан (Аллаһ аннан разый булсын) килгән хәдистә Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «***Бөек Аллаһ Тәгалә әйтә: «Минем колым Минем хакында ни уйлый — Мин шундый...»***». Әл-Бохари, 2675.

Аллаһ Тәгалә курку белән янәшә өмет хисе булганнарны искә алып болай дип әйтте:

«**Алар табына торган бу мәхлуклар үзләре Аллаһка якынаю юлларын эзлиләр. Үзләрен Аллаһка якын дип уйлап, Аның рәхмәтен өмет итәләр, Аннан куркып торалар. Чөнки Аллаһның газабы коточкыч бер газап һәм ул газаптан куркырга кирәк**» «Әл-Исра», 57.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Ахирәт көненнән курыккан, Раббының рәхмәтен өмет итүче, төнге сәгатьләрдә сәҗдәгә киткән, аягүрә басып намаз укыган...**» «Әз-Зүмәр», 9.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...Алар үзләренең ястыкларыннан аерылып курку илә өмет арасында Раббыларына ялварганнар...**» «Әс-Сәҗдә», 16.

Алда телгә алынганнарны исәпкә алып шуны әйтергә була: мөселман кешесендә курку да, өмет хисе дә булырга тиеш.

Үз тормышын Аллаһ юлында гыйбадәттә уздырган берәү шундый сүзләр әйткән: «Курку белән өмет кошның ике канатына тиң: әгәр дә алар икесе дә тигез булса, кош үзен тигез тотыр һәм очышы да камил булыр; бер канаты кыскарак булса — ул тиешенчә оча алмас. Әгәр дә инде ике канатыннан да мәхрүм калса — һәлакәт чигенә җитер».

Курку хисе, һичшиксез, өмет барлыкка килүгә китерә, әгәр дә бу алай булмаса, адәм баласы төшенкелеккә бирелер иде. Өмет, шулай ук, һичшиксез, курку хисе барлыкка килүгә китерә, әгәр алай булмаса, кеше үзен һәрвакыт иминлектә хис итәр иде. Шунысын да әйтергә кирәк, төшенкелеккә бирелү белән үзеңне иминлектә хис итү бертигез булу — шелтәгә лаек.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**...Аллаһның ярдәменнән өметегезне өзмәгез! Хактыр ки, кәферләрдән башкалар Аллаһ ярдәменнән өметен өзмәс**» «Йосыф», 87.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Раббысының рәхмәтеннән бары тик юлдан язганнар гына өмет өзә**» «Әл-Хиҗр», 56.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...**(Чынлыкта), **отылучы кавем генә үзен Аллаһның мәкереннән имин хис итә**» «Әл-Әграф», 99.

Адәм баласын Аллаһ тыйган гамәлләрне кылудан тотып кала торган курку мактауга лаек. Ә өметкә килгәндә, аның мактауга лаек ике төре бар:

1) Аллаһның нурына[1] нигезләнеп, дини бурычларны башкарганнан соң, Аллаһның әҗеренә өмет итү;

---

[1] «Аллаһның нуры» — Коръән һәм Сөннәт.

2) Гөнаһлар кылып Аллаһ каршында тәүбә иткәннән соң, Ул гөнаһларымны кичерер һәм рәхмәтен насыйп итәр, дип өметләнү.

Менә шундый өмет, колның Аллаһның юмартлыгын, рәхмәтен таныганына һәм аның Аллаһның рәхмәтенең киңлегенә карап торуын күрсәтә.

## Аллаһка дога белән дәшү

Аллаһ Сүбхәнәһү үә Тәгалә әйтте:

«**Раббыгыз әйтте: «Миңа дога кылыгыз — җавап бирермен. Әмма Миңа гыйбадәт итүдән тәкәбберләнеп баш тарткан кешеләр хур булган хәлдә җәһәннәм утына керерләр»**» «Гафир», 60.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Сез Раббыгызга түбәнчелек белән һәм яшерен рәвештә дога кылыгыз. Дөреслектә, Аллаһ — чиктән чыгучыларны сөйми**» «Әл-Әграф», 55.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Колларым синнән Минем хакында сорасалар, Мин — якынмын. Миңа дога белән дәшкәннәргә җавап бирермен. Шулай булгач, Минем әмерләремне кабул итеп үтәсеннәр һәм Миңа ышансыннар, бәлки туры юлны табарлар**» «Әл-Бәкара», 186.

Әт-Тирмизиның «Сунан»ында Нугмән бин Бәшир (Аллаһ аннан разый булсын) пәйгамбәребезнең ﷺ әлеге сүзләрен җиткерә: Аллаһның илчесе: «***Дога — гыйбадәтнең асылы!***» — диде һәм соңыннан Аллаһның сүзләрен укыды: «**Миңа дога кылыгыз — җавап бирермен. Әмма Миңа гыйбадәт итүдән тәкәбберләнеп баш тарткан кешеләр хур булган хәлдә җәһәннәм утына керерләр**» «Гафир», 60.[1]

---

[1] Әт-Тирмизи, 2969. Сахих хәдис. «Сахих әт-Тирмизи»не кара.

## Аллаһка ярдәм сорап мөрәҗәгать итү (истигәнә)

Аллаһ Сүбхәнәһү үә Тәгалә әйтте:

**«Бары тик Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм бары тик Синнән генә ярдәм сорыйбыз»** «Әл-Фәтихә», 5.

Күпләребезгә билгеле булган хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ Ибн Гәббәскә (Аллаһ аннан һәм әтисеннән разый булсын) дәшеп: «***Әгәр дә сорыйсың икән — Аллаһтан гына сора, әгәр ярдәм сорап мөрәҗәгать итәсең икән — Аллаһка гына мөрәҗәгать ит!..***» — дип әйтте.[1]

## Аллаһка сыгыну эзләү (истигәзә)

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Коръән укыйсы булсаң — Аллаһның рәхмәтеннән куылган шәйтаннан Аллаһка сыгыну эзлә»** «Ән-Нәхел», 98.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Таңның Раббысына, Ул халык кылган мәхлукларның мәкереннән Аллаһка сыгынам, дип әйт...»** «Әл-Фәләкъ», 1-2.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Кешеләрнең Раббысы, кешеләрнең патшасы, кешеләрнең иләһе булган Аллаһка шәйтанның мәкерле котыртуыннан сыгынам, дип әйт...»** «Ән-Нәс», 1-4.

## Бәлага очраганда коткару сорап Аллаһка мөрәҗәгать итү (истигасә)

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«...Раббыгызга коткару сорап дога белән дәштегез һәм Ул сезнең чакыруыгызга җавап бирде»** «Әл-Әнфәл», 9.

[1] Әхмәд, 2669; Әл-Хәким, 6303; Әт-Тирмизи, 2516. «Сахих әл-Җәмиг әс-сагыйрь», 7957.

Аллаһ илчесенең ﷺ шундый дога белән дәшкәне билгеле: «***Йә, Мәңге Тере, Яшәешне барлап торучы, Бөеклек һәм Юмартлык иясе, күкләрне һәм җирне Халык кылучы, коткару сорап Синең рәхмәтеңә мөрәҗәгать итәм***».[1]

## Аллаһка тәвәккәл кылу

Гади итеп әйткәндә, Аның сине саклавында шикләнмичә йөрәгеңнең Аллаһка ышануы[2]. Аллаһ Сүбхәнәһү үә Тәгалә әйтте:

«**...Әгәр дә сез,** (чыннан да), **мөэмин (иман китергән) булсагыз —** (ул чагында) **Аллаһка тәвәккәлләгез**» «Әл-Мәидә», 23.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Иман китергәннәр Аллаһка гына тәвәккәл кылсыннар**» «Ибраһим», 11.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Тәвәккәл итүчеләр бары тик Аллаһка гына тәвәккәл итсен**» «Ибраһим», 12.

---

[1] Әбу Дәуд, 1495; Ибн Мәдҗәһ, 3858; Ән-Нәсәи, 1299.

[2] Искәрмә: бу урында бик тә мөһим аңлатма биреп китү кирәк. Монда сүз берни дә эшләмичә нәтиҗә көтеп утыру хакында бармый. Хакыйкый тәвәккәл кылу — ул нинди дә булса эшне башкарып чыгар өчен барча сәбәпләрне дә кылып бетергәннән соң шул эшеңне Аллаһка тапшыру, нәтиҗәне Аннан көтү.

# Аллаһка иман

Бөек һәм Кодрәтле Аллаһка иман китерү — иманның иң беренче һәм иң мөһим баганасы. Ул бөек әһәмияткә ия һәм калган барлык баганаларның да: фәрештәләргә, Китапларга, пәйгамбәрләргә, Кыямәт көненә, тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан икәнлегенә иманның нигезе булып тора. Бу баганалар барысы да «Аллаһка иман» баганасына таяналар һәм шуннан төзеләләр.

Бөек һәм Кодрәтле Аллаһка иманның асылы булып бөтен йөрәк белән:

- бары тик Аллаһ кына бердәнбер Раббы;
- бары тик Аллаһ кына гыйбадәт кылырга лаеклы бердәнбер зат;
- бары тик Аллаһ кына иләһи исемнәре һәм сыйфатлары булган бердәнбер зат икәнлеген тану тора.

Менә шушы йөрәк белән танырга тиешле өч нигез, барысы бергә «гыйбадәтләрдә бер Аллаһны гына берләү» — *тәүхидне* тәшкил итә һәм бар дин төзелергә тиеш нигез булып тора.

Ислам — ул гыйбадәтләрдә бер Аллаһны гына берләү (*тәүхид*) дине, чөнки бу дин бар нәрсә белән дә Аллаһ Үзе генә идарә итүгә һәм бар гамәлләрен дә бернинди ярдәмче-

ләрсез бер Үзе генә башкаруга; Ул Үзе генә иләһи Яшәешкә, исемнәргә, сыйфатларга ия, Аңа охшаш беркем, бернәрсә дә юк һәм шулай ук Ул Үзе генә Аны иләһләштерергә, гыйбадәттә берләргә лаеклы, Аңа тиңдәш беркем, бернәрсә дә юк икәнлегенә нигезләнә.

Югарыда атап киткәннәрдән шуны аңларга мөмкин: барлык пәйгамбәрләр һәм илчеләр дә алып килгән тәүхид өч нәрсәне үз эченә ала:

1) **Аллаһны Раббылыкта берләү** (*тәүхид әр-рубубия*) — бары тик Аллаһның гына бар нәрсәнең дә Раббысы, Хуҗасы, Халык кылучысы, Идарә итүчесе, яшәтүче, үтерүче, файдасын да, зарарын да китерүче, авыр вакытларда догаларга бердәнбер җавап бирүче, бар нәрсәдән дә абсолют рәвештә хакимлек итүче, барча булган хәерлелекләр белән идарә итүче, бар гамәлләр дә Аннан гына тора һәм бу хакимлекне Аның белән беркем дә бүлешми, дип йөрәгең белән тану, инану.

2) **Аллаһны иләһ итүдә берләү** (*тәүхид әл-улүһия*) — бердәнбер иләһ — бары тик Аллаһ кына, шуңа күрә барча гыйбадәтләр дә Аңа гына багышланырга тиеш, дип йөрәгең белән тану, инану.

3) **Аллаһны исем-сыйфатларында берләү** (*тәүхид әл-әсмә үә әс-сыйфат*) — Аллаһның Ул Үзе Коръәндә яки Пәйгамбәребезнең ﷺ сүзләрендә, дөрес Сөннәтендә тасвирланган барлык исем-сыйфатларны йөрәгең белән тану, раслау һәм Аннан барлык җитешсезлекләрне, кимчелекләрне, мәхлукатлары белән бәйле булган барча охшашлыкларны да инкяр итү. Бу — Аллаһ һәрнәрсәне дә белә һәм һәрнәрсәгә дә көче җитүчән икәнлекне тану. Шулай ук Ул — Мәңге Тере, Яшәешне барлап торучы, Аны йокымсырау да, йокы да алмый. Аның теләге бернинди тайпылышсыз үтәлә, Аның хикмәте чиксез. Ул — бар нәрсәне дә Күрүче, Ишетүче, Шәфкатьле, Рәхимле. Ул Үзенең Гаршеннән югары һәм пат-

шалыгын биләп тора. Ул — Патша (әл-Мәлик), Кимчелексез (әл-Куддус), Иминлек-Тынычлык иясе (әс-Сәләм), Саклаучы (әл-Муэмин), Саклаучы, Коткаручы (әл-Хәфийз), Куәтле (әл-Гәзийз), Кодрәтле (әл-Каадир), Горур (әл-Мүтәкәббир). Аңа тиңдәш кылган барча нәрсәләрдән дә Аллаһ ерак тора һәм Ул бар нәрсәдән дә пакь. Болар — Аллаһның күркәм исемнәреннән һәм бөек сыйфатларыннан бары тик берничәсе генә.

Югарыда санап киткән өч нәрсә Коръәндә һәм Сөннәттә бихисап дәлилләр белән раслана.

Коръән тулаем тәүхид, аның шартлары, аның өчен вәгъдә ителгән әҗер турында, шулай ук күп иләһлек (*ширек*), аларның тарафдарлары һәм аларның гамәлләренә күрә бәясен бирү хакында.

Тәүхиднең әлеге өч төрен галимнәребез Коръән һәм Сөннәт текстларыннан чыгардылар. Шәригать текстларын җентекләп өйрәнү диннең асылын үзләштерү мөмкинчелеген бирде, ул да булса — коллардан таләп ителә торган тәүхид — ул Аллаһны бердәнбер Раббы, гыйбадәт кылырга лаеклы бердәнбер һәм иләһи исемнәргә, сыйфатларга ия булган бердәнбер зат икәнлегенә иман китерү. Кем боларны тулаем кабул итми, ул иман әһеленнән түгел.

# Аллаһны раббылыкта берләү (тәүхид әр-рубубия)

Бу — бары тик Аллаһ кына иләһи гамәлләр башкара икәнлеген йөрәк белән тану. Бу гамәлләргә түбәндәгеләр керә: бар итү, ризыкландыру, рәхмәтен күрсәтү, хакимлек итү, төскыяфәт ясау, бирү һәм мәхрүм итү, файда һәм зарар китерү,

үлгәннән соң тергезү, үтерү, тәкъдир кылу һәм башкалар. Боларны Аллаһтан башка беркем дә кыла алмый.

«*Рубубия*» дигән гарәп сүзе «*раббә*» фигыленнән ясала һәм ул «тәрбияләү» мәгънәсенә күрсәтә. «*Раббы*» сүзе «хуҗа», «тәрбияче» дигәнне аңлата. Раббылык — ул Бөек һәм Кодрәтле Аллаһның сыйфаты. Шулай итеп, «*рубубия*» сүзе «*раббы*» исеменнән барлыкка килгән һәм ул гарәп телендә берничә мәгънәгә ия: «хуҗа», «буйсынырга тиешле булган хуҗа», «әйберләрнең торышын үзгәртүче реформатор».

Дөнья кисәкләре, җиһанда корылган күк, җир, йолдызлар, планеталар, кояш, ай, таулар, агачлар, диңгезләр, елгалар, безне бөркәп алган төн, көн һәм галәмнәрдә урнаштырылган абсолют, камил тәртип хакында фикерләп караган һәрбер акыл иясе дә шушы галәмнәрнең киң Кодрәтле, бөек Халык кылучысы, алар белән идарә итүчесе бар икәнлеген аңлар. Акылы булган кеше, менә шушы барлыкка килгән нәрсәләр хакында тирәнрәк уйланган саен, аның акылын әлеге гаҗәеп мәхлукатлар ныграк биләп алган саен, боларның барысы да хаклык өчен һәм хаклык белән барлыкка килгәненә тагы да ныграк төшенә башлый. Җиһан — ул Аллаһның аятьләре (иманга этәрә торган билгеләрне) тупланган битләр һәм Аллаһ Тәгалә Үзенең бердәнберлеген, Үзе хакында хәбәр иткән бар нәрсәнең дә хак икәнлеген раслаган дәлилләр тупланган китап.

Нинди дә булса башка дин вәкилләре тарафыннан тәүхиднең әлеге төрен кире кагу хакында безгә бер очрак та билгеле түгел. Шулай ук, бу дөньяны бер-берсенә сыйфатлары һәм мөмкинчелекләре белән охшаш ике Халык кылучы бар кылган, дип белдергән очрак та билгеле түгел.

Кешеләрдән, бар нәрсәне дә халык кылуда Аллаһ белән янәшә кемдер катнашкан, яки, Аллаһ кына ия булган сыйфатларга тагын кем дә булса ия, дип раслаган бер генә хәбәр дә юк. Аллаһ белән янәшә кемгә-нәрсәгә дә булса гый-

бадәт кылган мөшрикләр дә (ялган иләһләргә табынучылар), фәрештәме ул, пәйгамбәрме, планета яки нинди дә булса сыныммы — барысының да Аллаһ хакимлегендә икәнлегенә инанганнар.

Мөслимның «Сахих» җыентыгында Ибн Гәббәстән килгән хәдистә (Аллаһ аннан һәм әтисеннән разый булсын), гарәплләрдән булган мөшрикләр тәлбияләрен[1] болай дип әйтә торган булганнар: «Менә мин Синең каршыңда, Синең хакимлегеңдә булганнардан кала синең тиңдәшләрең юк. Алар нәрсәгә ия — ул да синең хакимлегең астында». Ә Аллаһның илчесенә килгәндә, ул бер иләһлекне генә раслый торган сүзләрне әйтте: «***Мин Синең каршыңда, йә, Аллаһ, мин Синең каршыңда! Мин Синең каршыңда, Синең тиңдәшең юк, мин Синең каршыңда! Дөреслектә, барча мактау Сиңа, барча нигъмәт һәм патшалык Синеке, Синең тиңдәшең юк!***» Әл-Бохари, 1549; Мөслим, 1184.

Гарәпләрдән булган мөшрикләрнең Аллаһны бердәнбер Халык кылучы, дип таныганнарын Аллаһ Үз китабының бик күп аятьләрендә безгә хәбәр итә. Мисал өчен, Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Әгәр син алардан: «Күкләрне һәм җирне кем бар кылды?» — дип сорасаң, алар, һичшиксез: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. «Аллаһка мактаулар булсын!» — диген. Ләкин аларның күпләре аңламыйлар»** «Локман», 25.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Әгәр син алардан: «Күкләрне һәм җирне кем яралткан? Кояшны, Айны буйсындырып йөртүче кем?» — дип сорасаң, алар, һичшиксез: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. Шулай икәнен белгәч, ни өчен иман китерүдән баш тарталар»** «Әл-Ганкәбут», 61.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

---

[1] Тәлбия — гөмрә яки хаҗ кылган вакытта әйтелә торган зекер сүзләре.

**«Әгәр дә син алардан: «Үлгәннән соң Кем күктән су индереп үлгән җирне тергезде?» — дип сорасаң, алар, һичшиксез: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. «Барча мактау Аллаһкадыр!» — диген. Ләкин аларның күбесе шуны аңламый»** «Әл-Ганкәбут», 63.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Сора: «Сезгә күктән үә җирдән кем ризык бирә? Яки хуҗа булып сезгә күз һәм колакларны кем бирә? Җансыздан җанлыны кем чыгара, терене кем үтерә ала? Бөтен эшләр белән кем идарә итә?» Алар: «Аллаһ!» — дип әйтерләр»** «Йунус», 31.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Әйт: «Әгәр беләсез икән, әйтегез: бу дөньяга һәм андагы барча нәрсәгә кем хуҗа?» Алар: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. «Шулай булгач, нигә уйлап карамыйсыз?» — диген. «Җиде кат күкләрнең һәм бөек Гарешнең Раббысы кем?» — дип сора алардан. Алар: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. «Шулай булгач, сез Аллаһның җәзасыннан нигә курыкмыйсыз?» — диген. «Әгәр беләсез икән, әйтегез: барлык мөлкәтне кем үз карамагында тота? Кем һәрнәрсәне саклар һәм кемнән сакланып булмас?» Алар: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. «Никадәр сихерләнгәнсез!» — диген»** «Әл-Муэминун», 84-89.

Шуңа да карамастан, Аллаһтан башка да Халык кылучылар бар дип уйлаучы кешеләр бар. Мисал өчен, утка табынучылар караңгылыкны Аллаһ барлыкка китермәгән, диләр. Кадарилар, хайваннарның гамәлләрен бар кылучы Аллаһ түгел, дип исәплиләр. Гарәплpoints һәм башка халыклардан да булган кайбер мөшрикләр, бу иләһләре аларга файда китерәләр яки үзләреннән-үзләре зыян салалар, ә Аллаһ боларны эшләми, дигәннәр.

Шундый төр ширекнең[1] урынсыз икәнен Аллаһ Сүбхәнәһү үә Тәгалә Коръәндә күрсәтә. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Аллаһ бернинди дә баланың атасы булмады. Аңа тиң башка бер иләһ тә юк. Әгәр тагын бер иләһ булган булса, һәрберсе, халык кылган нәрсәсен үзе белән алып китәр иде һәм берсе икенчесеннән өстен булырга тырышыр иде»** «Әл-Муэминун», 91.

Аллаһның әлеге сүзләре фикерләп карап дәлилләнергә чакыруның үрнәге. Моның асылы — ике халык кылучының барлыгын кире кагу. Хакыйкый иләһ, һичшиксез, көчле, бар нәрсәне дә булдыра ала торган Халык кылучы булырга тиеш. Әгәр дә Аннан кала шундый ук хакимлеккә ия булган тагын бер иләһ бар дип күз алдына китерсәк, аның үзенең мәхлукатлары булган булыр һәм, шулай ук, көче, кодрәте белән аерылып торыр иде. Әмма уртак хакимлек икенче иләһкә ошап бетмәс иде һәм ул ничек тә булса «иптәшен» үзенә буйсындырып бар нәрсә белән дә үзе генә идарә итәргә теләр, әгәр дә инде булдыра алмаса, үзенең мәхлукатларын алып кайда да булса китәр иде.

Шулай итеп, әгәр дә халык кылучы икәү булган булса, ике нәрсәнең берсе котылгысыз булыр иде:

- яки һәрбер иләһ бар кылган нәрсәсен үзе белән алып китәр иде;
- яки бер иләһ икенче иләһ өстеннән күтәрелер иде.

Әмма, берничә иләһнең булу мөмкинлеге, без шаһид булган барча нәрсәләргә дә каршы килә. Чөнки халык кылынган һәрнәрсәнең дә — күкләр һәм җир, өстә һәм аста булган бар нәрсәләрнең дә билгеле бер тәртиптә, камил рәвештә үзара бәйләнештә булулары бар җиһан белән Бердәнбер, Бөек һәм Көчле иләһ идарә иткәнлегенә күрсәтә.

[1] Ширек — Аллаһның мәхлукатларын Аллаһ белән бергә бары тик Аңа гына хас булган нәрсәләрдә тигезләү, бергә кую. Ширек — иң зур гөнаһ.

## Аллаһның раббылыгында бер икәнлегеннән читкә тайпылу нәрсәдә чагыла?

Асылда, адәм баласының күңелендә бердәнбер булган Раббының барлыгы тумыштан ук килгән фитри иман, болар бихисап дәлилләр белән расланган булуына да карамастан, шулай да, бу мәсьәләдә читкә тайпылган кешеләр бар. Кешеләрнең Аллаһны Раббылыкта тану мәсьәләсендә бозылган инануларын кыскача гына түбәндәгечә тәртипкә салып һәм аңлатма биреп була:

**Беренче тайпылу.** Раббының барлыгына бөтенләй ышанмау. Әлеге карашлар атеистларга кагыла. Аларның фикеренчә, бар нәрсә дә табигать, вакыт сәбәпле, яисә үзеннән үзе барлыкка килгән һәм башкалар.

«**Алар: «Бу дөньядагы тормыштан башка тормыш юк. Үләбез һәм яшибез. Безне бары тик вакыт үтерә», — диделәр**» «Әл-Җәсияһ», 24.

**Икенче тайпылу.** Бар кимчелектән дә пакь Раббының кайбер үзенчәлекләрен кабул итмәү һәм Аның раббылыгына бәйле булган кайбер нәрсәләрне кире кагу. Мисал өчен, кешеләрнең әлеге күзаллавы, Аллаһның үтерә һәм соңыннан терелтә алуын, файдасын да бирүен, зарарын да салуын һ.б. кире кагуда чагыла.

**Өченче тайпылу.** Аллаһка гына хас булган нәрсәләрне башка берәүгә дә юнәлтү. Әгәр дә адәм баласы, Аллаһтан башка тагын кем дә булса шушы галәмнәр белән идарә итә ала — бар кыла, юк итә, үтертә, үлгәннән соң терелтә, рәхмәтен бирә, начарлыклардан саклый ала, дип инана икән, ул Аллаһка тиңдәшләр кылган булып чыга.

# Аллаһны исем–сыйфатларында берләү (тәүхид әл-әсмә үә әс-сыйфат)

Аллаһның исем-сыйфатларына иман китерү, мөселман кешесенең йөрәге өчен дә, гыйбадәте өчен дә зур тәэсир итә. Шушы инану аркылы ул гыйбадәтенең асылын аңлый башлый. Шушы иман сәбәпле ул Аллаһка тәвәккәлли, бер Аңа гына таяна башлый. Үзенең тәнен, нәфесен, хәтта уйларын да Аллаһ Тәгалә яраткан юлда гына саклый, куллана. Ул Аллаһ яраткан нәрсәне ярата, Аның өчен генә тыңлый, Аның өчен генә карый башлый. Шуның белән бергә ул Үзенең Раббысына зур өметләр баглый һәм Аның турында бары тик яхшыны гына уйлый.

Аллаһның исемнәре, Аның колына, Раббысын бар җаны белән яратырга ярдәм итә. Әлеге мәхәббәт мөселман өчен бу тормышта да, ахирәт тормышында да бәхетнең нигезе, хәерлелекләрнең ачкычы булып тора һәм бу мәхәббәт Аллаһка иң камил рәвештә гыйбадәт кылырга рухландыра. Шуны да әйтеп китәргә кирәк, Аллаһны йөрәгең белән никадәр каты яратуыңа карап, кеше өчен тән белән кылына торган гыйбадәтләр дә я җиңел, я авыр кылыначаклар.

Гыйбадәтне Аллаһ Тәгалә теләгәнчә камил рәвештә кылу, Аллаһны йөрәгең белән никадәр яратуыңа бәйле, ә шушы мәхәббәткә Аллаһның исем-сыйфатларын өйрәнеп кенә ирешеп була. Шуңа күрә дә Аллаһка иң камил рәвештә пәйгамбәрләр гыйбадәт кылганнар, чөнки алар Аллаһны исем-сыйфатлары аша таныганнар, шунлыктан, Аллаһка карата иң көчле мәхәббәт белән аерылып торганнар.

Аллаһны исем-сыйфатларында берләү (*тәүхид әл-әсмә үә әс-сыйфат*) — ул йөрәгең белән Аллаһны Ул Үзен Үзе тас-

вирлаган һәм Аның илчесе ﷺ Аны тасвирлаган исемнәр һәм сыйфатларына инану[1] һәм Аллаһ Үзеннән Үзе һәм Аның илчесе ﷺ Аннан инкарь иткән барлык исем-сыйфатларны да инкарь итеп[2], шулай ук аларның хакыйкый мәгънәсен танып, Аны тасвирлау.

## Аллаһны исем-сыйфатларында берләүнең нигезен нәрсә тәшкил итә?

**Беренчесе:** Аллаһ Тәгалә иң күркәм исемнәргә ия, бу исемнәрдән дә күркәм исемнәр була алмый. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Аллаһның күркәм исемнәре бар**» «Әл-Әграф», 180.

Шуны да әйтергә кирәк, Аллаһ барлык кимчелекләрдән дә пакь булган югары һәм камил булган сыйфатларга да ия. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Иң күркәм сыйфатлар Аллаһта гына**» «Ән-Нәхел», 60.

Монда сүз югары, камил, күркәм сыйфатлар хакында бара.

**Икенчесе:** Аллаһның исем-сыйфатлары хакында гыйлем өстән иңгән, чөнки алар хакындагы гыйлемебез Коръән һәм Сөннәт булып тора, шуңа күрә дә без бары тик аларга гына нигезләнергә, алар нәрсәгә күрсәтә — шуларны, бернәрсә дә киметмичә һәм арттырмыйча кабул итәргә тиеш.

**Өченчесе:** Аллаһны сыйфатлаганда раслау да, кире кагу да кулланыла, шуның белән бергә, Аллаһ Үз китабында әйткәнчә, раслау белән охшату һәм кире кагу белән

---

[1] Мисал өчен, Аллаһ Үз китабында әйтә: «**...Ул — Ишетүче, Күрүче**» («Әш-Шура», 11).

[2] Мисал өчен, Аллаһ Үз китабында әйтә: «**Ул тудырмаган да, тудырылмаган да**» («Әл-Ихлас», 3).

мәхрүм итү арасында бернинди уртаклык та булырга тиеш түгел:

**«Аңа охшаш бернәрсә дә юк! Ул — Ишетүче, Күрүче»** «Әш-Шура», 11.

**Дүртенчесе:** Безгә Аллаһның исем-сыйфатлары билгеле, әмма болар астында нәрсә күз алдында тотыла, болар барысы да тулаем Аллаһка гына билгеле. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«...Әмма алар Аллаһны гыйлемнәре белән чолгап ала алмыйлар»** «Та hа», 110.

Ике «Сахих» җыентыгында да Әбу Һурәйрадан хәбәр ителгән хәдистә (Аллаһ аннан разый булсын) Пәйгамбәребез ﷺ: «***Чынлыкта, Аллаһның 99 исеме бар, бердән башка йөз, һәм кем дә кем аларны санап чыкса — ул җәннәткә керер***», — дип әйтте. Әл-Бохари, 2736, 7392; Мөслим, 2677.

Бу очракта «санап чыгу» дигән сүзләр, әлеге исемнәрне аңлауны, ятлауны һәм аларның мәгънәләре мәҗбүр иткәнчә тормышта куллануны аңлата.

Ләкин, Аллаһның исемнәре туксан тугыз белән генә чикләнми, Аның безгә Коръәндә һәм Сөннәттә хәбәр итмәгән исемнәре дә бар.

Имам Әхмәд, Ибн Хиббән һәм башка мөхәддисләр Габдуллаһ ибн Мәсгудтән (Аллаһ аннан разый булсын) килгән хәдисне җиткерәләр. Әлеге хәдистә Пәйгамбәребез ﷺ: «***...Мин Синнән, Үзеңне Үзең исемләгән яки Китабыңда иңдергән яки мәхлукларыңның берсенә белгерткән яки Үзеңдә яшереп калдырган һәрбер исемең белән сорыйм...***», — дип әйтте[1].

Шулай итеп, Биек һәм Бөек булган Аллаһның бик күп исемнәре бар, һәм ул исемнәр сыйфатка да күрсәтә.

---

[1] Әхмәд, 1/391; Ибн Хиббән, 3/972; Әт-Тәбәрани, 10352.

Аллаһның кайбер исем-сыйфатларына мисаллар китереп китик. Аллаһның исемнәренә түбәндәгеләр керә:

## Аллаһ, Раббы (Әр-Раб), Мәрхәмәтле (Әр-Рахмән), Шәфкатьле (Әр-Рәхийм)

«Әл-Фәтихә» сүрәсендә Аллаһ Тәгалә:

«**Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка мактаулар булсын. Ул — Рәхимле, Шәфкатьле**» «Әл-Фәтихә», 2-3, — дип әйтә.

**Аллаһ** — бөекләп һәм мәхәббәт белән гыйбадәт кылынырга тиешле зат.

**Раббы** — бу исем бөтен раббылык сыйфатларына ия булуга ишарә итә, мәсәлән: халык кылу, ризыкландыру, идарә итү, үлгәннәрне терелтү, үтерү һ.б. Ул барлык булган нәрсәнең тулы хокуклы иясе, һәм Аның хокукларына дәгъва кылучы көндәше юк.

**Мәрхәмәтле (*Әр-Рахмән*), Шәфкатьле (*Әр-Рәхийм*)** — бу ике исем дә мәрхәмәтлелек белән булган бәйләнешкә күрсәтә, ләкин аларның һәрберсе үзенә аерым мәгънәне ала. Әр-Рахмән исеме Аллаһның Заты белән бәйле, дөньяда барча мәхлукларга да, ә ахирәттә мөэминнәргә генә мәрхәмәтлелек Иясе. Ә Әр-Рәхийм исеме Аллаһның сыйфаты белән бәйле, дөньяда да, ахирәттә дә мөэминнәргә генә ирешә торган мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек Иясе.

Аллаһның мәрхәмәтлелеге ике төргә бүленә — гомуми һәм хас. Гомуми мәрхәмәтлелекне Аллаһ барча булган мәхлукатларына да бирә, ә хас мәрхәмәтлелекне бары мөэминнәргә генә.

Гомуми мәрхәмәтлелеккә килгәндә, Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Дөреслектә, Аллаһ кешеләргә карата Шәфкатьле, Рәхимле**» «Әл-Хәҗ», 65.

Ә хас мәрхәмәтлелеккә килгәндә, Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**...Ул мөэминнәргә чиксез мәрхәмәтле**» «Әл-Әхзәб», 43.

## Бердәнбер (Әхәд), Мәңге, Ихтыяҗларны Үтәүче (Әс-Самәд)

Коръәннең өчтән беренә тигез булган «Әл-Ихлас» сүрәсендә Аллаһ Тәгалә әйтте:

«(И, Мөхәммәд, син аларга болай дип) **Әйт: «Ул Аллаһ — Бердәнбер, Ихтыяҗларны Үтәүче (*Әс-Самәд*)...»** «Әл-Ихлас», 1-2.

**Бердәнбер**, ягъни, Үзенең камиллегенә килгәндә Бердәнбер, Аңа охшаш һәм Аның белән камил сыйфатларын бүлешердәй беркем дә, бернәрсә юк.

**Ихтыяҗларны Үтәүче**, ягъни, коллар барча хәлләрендә дә, ихтыяҗларында да түбәнсенеп, ялварып Аңа омтылалар. Кайбер сәләфләр Әс-Самәд — Ул Даими, мәхлукатлар беткәннән соң Калучы, Мәңге мәгънәсендә, диделәр.

## Мәңге Тере (Әл-Хәй), Яшәешне барлап торучы (Әл-Каййюм), Биек (Әл-Галий), Бөек (Әл-Газыйм)

Бу исемнәр, Аллаһ тарафыннан, Коръәндәге иң бөек булган «Әл-Көрси» аятендә искә алына. Кем бу аятьне төнлә укып ята, шул кешене иртәнгә хәтле Аллаһтан җибәрелгән саклаучы саклар һәм шәйтан аңа якын да килә алмас. Әл-Бохари, 2311.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Аллаһ — Аннан башка гыйбадәт кылырга лаеклы һичбер иләһ юк. Ул — Мәңге тере, Ул — Яшәешне барлап торучы. Аны беркайчан да йокымсырау басмас, Ул беркайчан да йокыга китмәс. Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә — Аныкы. Кем** (Кыямәт көнендә) **Аның каршысында** (торганда), **Аның рөхсәтеннән башка** (берәрсе өчен) **шәфәгать кыла алыр икән? Ул һәрнәрсәнең үткәнен дә, киләчәген дә белә. Алар Аның гыйлеменнән, Ул Үзе теләп аларга белгерткән нәрсәдән башканы белмиләр,**

**чолгап ала алмыйлар. Аның Көрсие күкләрне һәм җирне үз эченә алды. Аларны саклау Аның өчен бер дә авырлык китерми. Ул — барнәрсәдән дә Биек һәм Бөек»** «Әл-Бәкара», 255.

**Мәңге тере (*Әл-Хәй*)** исеме Аллаһның яшәеше бар яктан да мәңге һәм камил икәнлекне, ә Ул Үзе йокымсырауга да, йокыга да, үлемгә дә бирешүчән түгел икәнлекне аңлата.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Һәрвакыт Тере, һич үлми торган Раббыңа тәвәккәл кыл!»** «Әл-Фуркан», 58.

**Яшәешне барлап торучы (*Әл-Каййюм*)** исеме Аллаһның, бернәрсәгә дә мохтаҗ булмыйча, Үзеннән Үзе яши икәнен аңлата, ә калганнар исә бары тик Аның сәбәпле генә яши.

**Биек (*Әл-Галий*)** исеме абсолют биеклеккә күрсәтә, мисал өчен, кодрәтендә биеклек, буйсынуда биеклек, асылы белән биеклек. Кодрәтендә биеклеккә килгәндә, бу — Аллаһка камиллек һәм биеклек сыйфаты хас дигәнне аңлата. Буйсынуда биеклеккә килгәндә, бу — Аллаһ барча мәхлукатларын да Үзенә буйсындырып, тулы хакимлек белән алар белән идарә итә дигәнне аңлата. Ә асылы белән биеклек — Ул Үзенең Гарше өстендә, мәхлукатларыннан югарыда, биектә. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Биек булган Раббыңның исемен тәсбих кыл...»** «Әл-Әгълә», 1.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Менә Аллаһ: «И, Гәйсә! Мин сине Үз хозурыма күтәрермен», — диде»** «Әли-Гыймран», 55.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Әллә соң сез, күктә булган Затның җирне тетрәндереп сезне йоттыруында шикләнәсезме? Әллә соң сез, күктә булган Затның сезгә гарасат җибәрүеннән шикләнәсезме?**

**нәсезме? Кисәтүләребезнең ни икәнен сез озакламый белерсез!»** «Әл-Мүлк», 16-17.

«Күк» дип монда югарылык, биеклек күздә тотыла, башкача әйтсәк, халык кылынган күкләрдән дә биек булу.

**Бөек (*Әл-Газыйм*)** исеме бөеклеккә бәйләнеше булган бар нәрсәгә дә күрсәтә.

## Әүвәл (Әл-Әүвәлү), Ахыргы (Әл-Әәхиру), Өстен, Ап-Ачык (Әз-Зааһиру), Иң Якын (Әл-Бәәтыйну), Белүче (Әл-Гәлийм)

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Ул — Әүвәлге, Ахыргы, Өстен һәм Иң Якын, Барысын да белеп торучы»** «Әл-Хәдийд», 3.

Аллаһның илчесе ﷺ бер хәдисендә бу дүрт исемгә дә аңлатма биреп китте: ***«И, Аллаһ!.. Син — Әүвәлге, Сиңа кадәр бернәрсә дә юк иде, Син — Ахыргы, Синнән соң бернәрсә дә булмас, Син — Өстен, Синнән өстә бернәрсә дә юк, Син — Иң Якын, Синнән аста бернәрсә дә юк...»***.[1]

Белүче: гыйлеме бар нәрсәне дә чолгап алган Зат. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Ярешен булган нәрсәләрнең ачкычлары — Аның хозурында. Алар турында Аннан башка беркем белми. Ул җирдә дә, диңгездә дә ни барлыгын белә. Хәтта агачтан төшкән яфрак турында да Ул белеп тора. Җир караңгылыгында —** («Ләүхел Мәхфуз» исемле) **аермачык Китапта[2] теркәлмичә калган бер орлык бөртеге дә, юеш яки коры булган бернәрсә дә юк»** «Әл-Әнгәм», 59.

---

[1] Мөслим, 2713; Әбу Дәуд, 5051; Әт-Тирмизи, 3400; Ибн Мәдҗәһ, 3873.

[2] «Ләүхел Мәхфуз» — күктә саклана торган үзгәрмәс язмыш китабы. Анда барча мәхлукларның язмышлары, тәкъдирләре язылган. Анда һәрбер үткән һәм булачак вакыйгалар теркәлгән. «Ләүхел Мәхфуз»дә язылганны Аллаһтан башка беркем белми.

## Ишетүче (Әс-Сәмийгъ), Күрүче (Әл-Бәсыйр)

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Һәм Ул — Ишетүче, Күрүче**» «Әш-Шура», 11.

Ул — Ишетүче, ә ишетү — Аның сыйфаты икәнне аңлата. Ул — Күрүче, күрү — Аның сыйфаты икәнне аңлата. Димәк, Ул барнәрсәне дә ишетә, күрә һәм бернәрсә дә Аннан яшеренеп кала алмый.

## Хикмәт Иясе (Әл-Хәкийм), Хәбәрдар (Әл-Хабийр)

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**...һәм Ул — Хикмәт иясе, Хәбәрдар**» «Сәбә», 1.

**Хикмәт Иясе.** Ул Үзе булдырган яшәеш һәм дини кануннары нигезендә бу тормышта да, Ахирәт тормышында да мәхлуклары өстеннән идарә итә һәм ничек тели — шулай хөкем кыла. Беркем дә Аның карарына каршы төшә алмый. Ул — Хикмәт Иясе, шуңа күрә дә Ул халык кылган бар нәрсәләр дә камил төгәллек һәм гүзәллек белән аерылып торалар.

**Хәбәрдар.** Ачык һәм яшерен булган бар нәрсәдән дә хәбәрдар.

Аллаһ Тәгаләнең сыйфатларына түбәндәгеләр керә:

## Йөз

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Фәкать олуглык үә юмартлык иясе булган Раббыңның йөзе калучыдыр**» «Әр-Рахмән», 27.

## Куллар

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Аның Куллары киң җәелгән»** «Әл-Мәидә», 64.

## Күз

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Раббыңның хөкеме килгәнче сабыр ит, дөреслектә, син Безнең Күзләребез каршында»** «Әт-Тур», 48.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«...Сине Минем Күз алдымда үстерер өчен»** «Та ha», 39.

Монда ике күз хакында сүз бара, шуңа күрә дә Аллаһның илчесе ﷺ: «***...Дөреслектә, сезнең Раббыгыз бер күзле түгел***», — диде. Әл-Бохари. 7407; Мөслим, 169.

Югарыда телгә алган өч сыйфат Аллаһның Заты белән булган сыйфатка күрсәтә.

## Гарештән югары булу

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Рахмән** (Рәхмәт иясе) **булган Аллаһ Гарештән югары күтәрелде»** «Та ha», 5.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Шуннан соң Ул Гареш өстенә югарыланды»** «Әл-Әграф», 54.

Алда атап киткән югарылык биеклеккә (иң югары чик), барча нәрсәдән дә биектә булуны, күтәрелеш һәм тотрыклылыкны күрсәтә. Әлеге сыйфат — Аллаһның гамәле белән бәйле булган сыйфатларына керә.

## Бергә булу

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Ул — күкләрне үә җирне алты көндә барлыкка китерде, соңыннан Гарештән югары күтәрелде. Җирдән**

**ни чыга, җиргә ни керә, күктән ни иңә, күккә ни менә — барысын да Ул белеп тора. Сез кайда гына булсагыз да, Аллаһ һәркайда да сезнең белән. Аллаһ гамәлләрегезне күреп тора»** «Әл-Хәдийд», 4.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Күкләрдә үә җирдә булганнарның барчасын да Аллаһ белеп торганын белмисең мени? Өч кеше сөйләшеп торганда, дүртенчесе Аллаһ булыр. Биш кеше серләшеп торганда, әлбәттә, алтынчысы Аллаһ булыр. Шуннан аз яки күбрәк кеше сөйләшкәндә дә Аллаһ, һичшиксез, алар янында булыр. Ахырда Кыямәт көнендә Ул аларга ни кылганнарын хәбәр итәчәк, Аллаһ бит бар нәрсәне дә белә!»** «Әл-Мүҗәдәлә», 7.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...Менә ул** (Мөхәммәд) **үзенең иптәшенә** (Әбу Бәкергә): **«Син кайгырма. Дөреслектә, Аллаһ — безнең белән!» — диде»** «Әт-Тәүбә», 40.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Дөреслектә, Аллаһ тәкъвалар** (гөнаһ кылудан курыкканнар) **һәм изге гамәлләр кылучылар белән»** «Ән-Нәхел», 128.

Аллаһның бергә булуы ике төрле була.

Беренчесе — һәркем, барча нәрсә белән дә бергә булу, моңа югарыда карап киткән «Әл-Хәдийд» һәм «Әл-Мүҗәдәлә» сүрәләре аятьләре күрсәтә. Бу — Аллаһның Үз мәхлукатлары хакындагы бар нәрсәне дә белүе белән бәйле.

Икенчесе — Аллаһ бар кылган кайбер мәхлукатлар белән бергә булу, моны без «Әт-Тәүбә» һәм «Ән-Нәхел» сүрәләре аятьләрендә күрдек. Монда сүз Аллаһка якын булганнар хакында, әлеге аятьләрнең мәгънәләренә караганда, Ул һәрвакыт аларга ярдәм, булышлык күрсәтә һәм аларны саклый.

## Килү

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Әллә соң алар** (Кыямәт көнне) **Аллаһның фәрештәләр белән, ак болытлар күләгәсендә килүен көтәләрме?**» «Әл-Бәкара», 210.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...Синең Раббың рәт булып тезелгән фәрештәләр белән килгәч...**» «Әл-Фәҗер», 22.

Монда сүз Аллаһ Тәгаләнең Кыямәт көнендә Үзенең колларына карата ахыргы карарын чыгарырга килүе хакында. Әлеге сыйфат — Аллаһның гамәле белән бәйле булган сыйфатларына керә.

## Беренче күккә төшү

Ике «Сахих»та да, Әбу Һурәйрадан (Аллаһ аннан разый булсын) килгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ безгә болай дип хәбәр итте: «***Һәр төннең азакы өченче өлеше җиткәч, Аллаһ беренче күккә төшеп: «Кем Миңа дога белән дәшә — Мин аңа җавап бирермен, кем Миннән нәрсә дә булса сораса, Мин аны бирермен, Миннән гафу итүне сораганны Мин гафу итәрмен!» — дип әйтә***». Әл-Бохари, 1145; Мөслим, 758.

Шулай итеп, әлеге хәдис Аллаһ Сүбхәнәһү үә Тәгаләнең һәр төнне беренче күккә төшкәнен дәлилли, һәм әлеге сыйфат Аллаһның гамәле белән бәйле булган сыйфатка керә.

## Сүз, Сөйләшү

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Муса** (билгеләнгән урынга) **Без билгеләгән вакытка килеп җиткәч, Раббысы аның белән сөйләште**» «Әл-Әгъраф», 143.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Менә Аллаһ әйтте: «И, Мәрьям улы Гәйсә!»**» «Әл-Мәидә», 116.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Әгәр мөшрикләрнең берәрсе синнән аны сыендыруыңны сораса, син аны Аллаһның сүзләрен ишеткәненә кадәр сыендырып тор»** «Әт-Тәүбә», 6.

Сүз, яки Аллаһның сөйләшүе Аның сыйфатларына керә. Аллаһ теләсә — сөйләшә, кайчан һәм ничек тели — шунда сөйләшә. Аның тавышы ишетелә, ә Аллаһның сүзләре, бер яктан, Аның Заты белән бәйле, икенче яктан — гамәле белән бәйле сыйфаты.

Коръән — күктән иңгән һәм халык кылынмаган Аллаһның сүзләре.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Ошбу Без иңдергән Китап (Коръән) — (бик) мөбәрак. Сез аңа иярегез...»** «Әл-Әнгәм», 155.

Әйткәнебезчә, Аллаһның сүзләре Аның сыйфатларыннан берсе, ә Аның сыйфатлары халык кылынмаган.

## Мәхәббәт

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«...Дөреслектә, Аллаһ изгелек кылучыларны ярата»** «Әл-Бәкара», 195.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Дөреслектә, Аллаһ тәкъва бәндәләрне ярата»** «Әт-Тәүбә», 4.

## Ризалык

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Аллаһ алардан разый булды, алар да Аннан разый калды»** «Әл-Мәидә», 119.

## Ачу

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«...Аллаһның аларга ачуы чыкты...»** «Әл-Фәтех», 6.

Бу исемнәр һәм сыйфатларның Аллаһка караганын без төгәл беләбез, чөнки шул исемнәр һәм сыйфатлар белән Аллаһ Үзен Үзе һәм Аның илчесе ﷺ атады. Монда Коръән һәм Сөннәттән һичнинди тайпылу да юк, чөнки аларның ачыктан-ачык мәгънәсеннән тайпылу һич тиешле түгел. Шулай ук әлеге исем-сыйфатлар артында нәрсә яшеренгәнлеген ачыкларга тырышу, Аның сыйфатларын кешеләргә хас булган сыйфатлар белән тасвирлау ярамый.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Аңа охшаш бернәрсә дә юк...**» «Әш-Шура», 11.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Син Аңа охшаш булган башка берәүне беләсеңме?**» «Мәрьям», 65.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...Һәм Аңа охшаш (тиң) булган беркем дә юк**» «Әл-Ихлас», 4.

## Аллаһны исем-сыйфатларында берләүне ничек дөрес итеп аңларга?

Аллаһ Тәгаләнең исем-сыйфатларын дөрес итеп аңлау — исем-сыйфатларны бозмыйча (*тәхрийф*), кире какмыйча (*тәгътыйль*), күзалламыйча (*тәкйиф*) һәм мәхлукатларының сыйфатларына охшатмыйча (*тәмсийл*), Аллаһ Үзен Үзе һәм Аның илчесе ﷺ сыйфатлаган барлык исем-сыйфатларга да абсолют рәвештә иман китерү, ышануда нигезләнә.

• **Бозу** (*тәхрийф*) — Аллаһның исем-сыйфатларының хакыйкый мәгънәсен үзгәртүдән гыйбарәт.

Ул ике төрле була:

1) Исем булган сүзгә артык хәреф өстәп, яки бер яисә берничә хәреф киметеп, хәрәкәләр өстәп бозу, мәгънәсен үзгәртү. Шулай итеп, адашкан төркем вәкилләре Аллаһ китабындагы «*истәвә*» сүзен үзгәрттеләр. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Рахмән** (Рәхмәт иясе) **Аллаһ Гарешкә күтәрелде (*истәвә*)**» «Та ha», 5.

«*Истәвә*» сүзенең якынча мәгънәсе «күтәрелде», ягъни, «югарыда», «биектә», дигәнне аңлата. Ә алар «*истәүлә*» дип үзгәртеп, «басып алды», «кулга төшерде» дигән, тамырыннан ук башка мәгънәгә ия булган аңлатма бирделәр.

2) Аллаһ һәм Аның илчесе ﷺ биргән мәгънәне аңа каршы килгән сүз белән үзгәртү. Мисал өчен, «Аллаһның Кулы» сүзендәге «*йәд*» (кул) сүзен «Аллаһның куәте» яки Аның «Рәхмәте» дип үзгәртү. Болай дип аңлау дөрес түгел, моның Коръән, Сөннәт текстларында да һәм билгеле булган гарәп теле кагыйдәләрендә дә бер нигезе дә юк.

• **Кире кагу** (*тәгътыйль*) — Аллаһның бар сыйфатларын да кире кагудан гыйбарәт. Моны Аллаһның бер сыйфаты да юк, дип фикер йөрткәннәр әйтә.

• **Күзаллау** (*тәкйиф*) — иләһи сыйфатларның образын тасвирлау, күзаллаудан гыйбарәт. Шулай итеп кайбер адашкан фирка әһелләре эшли. Алар Аллаһ сыйфатларының мәгънәсен бозалар, аларга аерым бер форма бирәләр һәм, мисал өчен, Аллаһның Кулы нинди, Ул ничек итеп Гаршеннән югары күтәрелгән, дип Аны күзаллыйлар. Болай итеп тасвирлау ялган булып тора, чөнки Аллаһның Үзеннән башка моның хакында беркем дә белми.

• **Охшату** (*тәмсийл*) — Аллаһның сыйфатларын мәхлукатлары сыйфатларына охшатудан гыйбарәт. Мисал өчен, андый кеше: «Аллаһның ишетүе безнең ишетүебез төсле», яки «Аллаһның Йөзе безнең йөзләребез төсле» дип әйтә. Аллаһ боларның барысыннан да өстен!

Аллаһның исем-сыйфатларын дөрес итеп аңлау өч кагыйдәгә нигезләнә, кем аларны аңласа һәм кабул итсә, шул

кеше бу мәсьәләдә беркайчан да адашмас. Әлеге кагыйдәләр түбәндәгедән гыйбарәт:

**1.** Бөек һәм Биек булган Аллаһның бер генә сыйфаты да мәхлукатлары сыйфатына охшаш түгел. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Аңа охшаш беркем дә юк һәм Ул — Ишетүче, Күрүче**» «Әш-Шура», 11.

Әлеге күркәм аять Аллаһның Үзенең мәхлукатлары арасында бернинди дә охшашлыгы юк икәнлегенә күрсәтә. Әлеге ишетү һәм күрү сыйфатлары Аллаһның бик күп мәхлукатларына да хас булуына карамастан, югарыда карап киткән аять аермачык итеп Аллаһның да ишетүе һәм күрүе барлыгына, әмма мәхлукатларының ишетүкүрүенә бер дә охшамаганлыгына күрсәтә.

Моны шулай ук Аллаһның сүзләре белән дәлилләп була:

«**Аллаһны беркем белән дә чагыштырмагыз**» «Ән-Нәхел», 74.

Шулай ук:

«**...һәм Аңа охшаш (тиң) булган беркем дә юк**» «Әл-Ихлас», 4.

**2.** Аллаһ Үзен Үзе атаган һәм сыйфатлаган, шулай ук Аның илчесе ﷺ сыйфатлаган исем-сыйфатлар Аның бөеклегенә хас рәвештә.

**3.** Аллаһ сыйфатларының затына төшенергә тырышу ярамый, чөнки мәхлукатлар моңа сәләтле түгелләр. Бу Аллаһның сүзләре белән дәлилләнә:

«**Ул аларның киләчәген дә, үткәннәрен дә белә, әмма алар Аны гыйлемнәре белән чолгап ала алмыйлар**» «Та ha», 110.

Сәламәт акылы булган кеше аңларга тиеш: аның акылының билгеле бер чиге бар һәм ул шул чиктән ары уза алмый. Бу аның ишетү һәм күрү мөмкинчелекләренең дә чиксез түгел икәнлеге белән бер. Мисал өчен, берәү, моңа ирешергә мөмкин түгел булуына да карамастан, үзенең акылы белән Аллаһ сыйфатларының заты хакында фикерләп ти-

рәнгә кереп китә икән, ул стена артында булган нәрсәне күрергә, бик ерактан килгән тавышны ишетергә өметләнүче белән тиң.

Коръән, Сөннәт Аллаһның бик күп күркәм исемнәрен, камил сыйфатларын искә ала һәм аларны тулаем санап чыгу мөмкин түгел. Без югарыда китергән исемнәр һәм сыйфатлар бары тик берничәсе генә.

Аллаһның бөеклегенә һәм камиллегенә хас рәвештә, һәрбер мөселман да бу иләһи исем-сыйфатларны танырга тиеш. Аллаһ Үзен Коръәндә ничек тасвирлаган, ул боларның барысын да танырга тиеш, чөнки, мәхлукатларына караганда, Аллаһ Үзе хакында яхшырак белә. Шулай ук, һәрбер мөселман, Пәйгамбәребез ﷺ Аллаһны үзенең Сөннәтендә ничек тасвирлаган — шуны да танырга тиеш. Чөнки ул, башка кешеләрдән аермалы буларак, Раббысы хакында яхшырак белгән. Ул алар арасында иң ихласлысы, иң оста теллесе, иң диндарлысы, иң тәкъвалысы булган. Беркемнең дә Аллаһның нинди дә булса сыйфатын кире кагарга яки Аның мәхлукатларыныкына охшатырга хакы юк, чөнки:

«**Аңа охшаш беркем дә юк һәм Ул — Ишетүче, Күрүче**» «Әш-Шура», 11.

# Аллаһны иләһлегендә берләү (тәүхид әл-улүһия)

«*Улүһия*» дигән гарәп сүзе «*иләһ*» сүзеннән ясала. «*Иләһ*» — мәхәббәт һәм бөекләү нигезендә буйсына торган зат. Аңа буйсыналар һәм Аның каршында түбәнсенәләр, Аннан куркалар һәм Аны телиләр, кайгылы вакытта Аңа сыгыналар һәм яшәешебезнең мөһим вакытларында Аңа дога белән

дәшәләр, хәерлелекне өмет итеп Аңа тәвәккәллиләр һәм Аннан сыенып урын эзлиләр.

Кеше күңелендә иләһкә карата булган шушы хисләр, иләһи затның адәм балаларына һәм барча мәхлукатларга да хас булмаган камил һәм бөек сыйфатларга ия булу сәбәпле барлыкка килә.

Аллаһны иләһлегендә берләү (*тәүхид әл-улүһия*) — бары тик бер Аллаһ кына хакыйкый иләһ һәм бары тик Ул гына Аңа гыйбадәт кылырга лаеклы, дип йөрәгең белән инану. Әгәр бары бер Аллаһ Тәгалә генә — Раббы һәм бары тик Ул гына камил исемнәргә, сыйфатларга ия икән, димәк, бер Ул гына хакыйкый иләһ!

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**«Бер Аллаһка гына гыйбәдәт кылыгыз үә ялган иләһләрдән ваз кичегез!» — дип әйтсеннәр өчен, Без һәрбер өммәткә дә илчеләр җибәрдек**» «Ән-Нәхел», 36.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Чөнки бу, Ул — Аллаһ хак булганы, ә Аннан башка гыйбадәт кылган нәрсәләр — ялган һәм шулай ук Аллаһ — Биек һәм Бөек булганы өчендер**» «Әл-Хәҗ», 62.

Һәм Аллаһ Тәгалә безгә Коръәндә, кешеләр иләһкә тиңләп гыйбадәт кыла торган барча объектлар да ялган, дип хәбәр итте. Ягъни, аларга буйсыну, дога белән дәшү, өмет, курку, ярдәм сорап сыену, тәвәккәл аша гыйбәдәт кылган кеше, алардан бернәрсә дә алмас.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Әллә алар бернәрсәне дә бар итә алмаган, ә үзләре юктан бар ителгән** (ясалган) **нәрсәләрне Аллаһка ширек** (тиңдәш) **кылалармы? Ә бит шул нәрсәләр аларга да ярдәм итә алмыйлар, үзләренә дә ярдәм күрсәтмиләр**» «Әл-Әграф», 191-192.

«**Сезнең Аннан башка дога кылып, мөрәҗәгать иткән нәрсәләрегез сезгә дә ярдәм итә алмыйлар, үзләренә дә ярдәм күрсәтмиләр**» «Әл-Әграф», 197.

«**Ул** (Аллаһ) **төнне көн белән аралаштырыр, көнне исә төн эченә кертер. Кояш белән айны үз әмере белән йөртер. Аларның һәрберсе билгеләнгән вакытка чаклы шулай йөрер. Боларның бөтенесен дә Аллаһ берүзе башкара. Барча милек — Аныкы, Аны инкарь итеп сез табынганнар исә хәтта бер хөрмә җимешенең ярысына да ия түгелләр. Әгәр сез аларны** (ялган иләһләрегезне) **чакырсагыз, алар сез чакырганны ишетмәс, ишеткән сүрәттә дә, сезгә җавап бирмәсләр. Кыямәт көнне Аллаһка тиң булудан ваз кичәрләр. Бу хакыйкатьне сиңа барча нәрсәләрдән хәбәрле булучы Аллаһтан башка һичкем әйтмәс**» «Фатыр», 13-14.

Кешеләрнең күпчелеге Аллаһны Раббы, Халык кылучы, Ризыкландыручы, Хуҗа дип таный, болар барысы да Аллаһның Раббылыкта бердәнберлегенә керә. Шул ук вакытта, кемгә дә булса зарар да, файда да китерә алмаган, бернәрсә белән дә ризыкландыра алмаган, бернәрсәдән дә мәхрүм итә алмаган төрледән-төрле предметларны, сынымнарны, үлгән әүлияләрне һәм фәрештәләрне, йолдызларны, агачларны гыйбадәтләрендә Аллаһ белән янәшә куялар, тиңдәш кылалар.

Аллаһ Тәгалә әйткәнчә:

«**Аларның күпләре Аллаһка тиңдәшләр кылып иман китерә**» «Йосыф», 106.

Пәйгамбәребез чорында яшәгән мөшрикләр Аллаһны Раббы, Халык кылучы, Ризыкландыручы, Хуҗа дип таныдылар, әмма шуның белән бергә галәмнәрнең Раббысы белән янәшә кемгә дә, нәрсәгә дә булса гыйбадәт кылдылар. Аларга догалар белән дәшеп, коткаруларын сорап һәм

хаҗәтләре белән мөрәҗәгать итеп, Аллаһка тиңдәшләр кылдылар.

Аллаһ Тәгалә Үзенең Китабында бик күп урында гарәп мөшрикләренең Аллаһны Раббылыкта берлеген, ягъни, *тәүхид әр-рубубияне* таныганнарын, әмма, шуның белән бергә, гыйбадәттә Аңа тиңдәшләр кылганнарын әйтә.

Шулай итеп, Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Әгәр син алардан: «Күкләрне һәм җирне кем яралткан, кояшны, айны буйсындырып йөртүче кем?» — дип сорасаң, алар, һичшиксез: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. Шулай булгач, нигә соң алар йөз чөерәләр?»** «Әл-Гәнкәбут», 61.

Аллаһ Сүбхәнәһү үә Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Әгәр дә син алардан: «Үлгәннән соң Кем күктән су иңдереп үлгән җирне тергезде?» — дип сорасаң, алар, һичшиксез: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. «Барча мактау Аллаһкадыр!» — диген. Ләкин аларның күбесе шуны аңламый»** «Әл-Гәнкәбут», 63.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Әгәр дә син алардан: «Сезне кем яралтты?» — дип сорасаң, алар: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. Шулай булгач, нигә соң алар йөз чөерәләр?»** «Әз-Зухруф», 87.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Әйт: «Әгәр беләсез икән, әйтегез: бу дөньяга һәм андагы барча нәрсәгә кем хуҗа?» Алар: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. «Шулай булгач, нигә уйлап карамыйсыз?» — диген. «Җиде кат күкләрнең һәм бөек Гарешнең Раббысы кем?» — дип сора алардан. Алар: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. «Шулай булгач, сез Аллаһның җәзасыннан нигә курыкмыйсыз?» — диген. Әгәр беләсез икән, әйтегез: «Барлык мөлкәтне кем үз карамагында тота? Кем һәрнәрсәне саклар һәм кемнән сакланып бул-**

**мас?» Алар: «Аллаһ!» — дип җавап бирерләр. «Никадәр сихерләнгәнсез!» — диген»** «Әл-Мөэминун», 84-89.

Пәйгамбәребез чорында яшәгән гарәп мөшрикләре сынымнар үзләреннән-үзләре яңгыр яудыралар, бу дөньяны ризыкландыралар һәм аның белән идарә итәләр дип уйламыйлар иде. Киресенчә, боларның барысын да бар кимчелекләрдән дә пакь булган Раббы гына булдыра ала дип ышана иделәр. Алар, Аллаһтан башка догалар белән дәшкән сынымнарының халык кылынган нәрсә икәнлекләрен һәм үзләренә дә, аңа гыйбадәт кылучыларга да үзлегеннән ни файда, ни зарар китерә алмаганнарын таныдылар. Алар бу сынымнар ишетә дә, күрә дә алмаганнары кебек, үтерә дә, терелтә дә алмаганнарын беләләр иде. Алар боларның барысын да бары тик бер Аллаһ кына булдыра алганына, бу хакимлекне Аның белән беркем дә бүлешмәгәнлегенә, ул сынымнарның да, үзләренең дә моңа көчләре җитмәгәнлегенә ышандылар. Алар бар кимчелектән дә пакь булган Аллаһ кына бердәнбер Халык кылучы, ә калган барлык мәхлукатлар да Аның мәхлукатлары, Ул — бердәнбер Раббы, ә калганнар тулаем Аның хакимлеге астындагы коллар икәнен таныдылар. Ләкин шуның белән бергә, Аллаһ каршында шәфәгать кылуларын сорап һәм Аңа якынаерга теләп, ул мөшрикләр Аллаһның мәхлукатларын Аңа тиңдәшләр кылдылар. Аллаһ алар хакында болай дип әйтте:

«**Аллаһтан башканы үзләренә яклаучы, ярдәмче итеп алганнар: «Без аларга безне Аллаһка тагын да ныграк якынайтсыннар дип кенә гыйбадәт кылабыз», — диләр»** «Әз-Зумәр», 3.

Ягъни, аларга ярдәм күрсәтелсен, ризык бирелсен, дөньяви эшләре тиешле тәртипкә китерелсен, дип алардан (алар аша) үзләренә Аллаһтан шәфәгать сораганнар.

Югарыды күренгәнчә, асылда, мөшрикләр Аллаһны бар нәрсәнең дә Раббысы дип таныдылар, әмма, шуңа да

карамастан, Аллаһ аларны мөселманнар дип атамады. Киресенчә, Аллаһ Сүбхәнәһү үә Тәгалә аларны күп иләһләргә табынучылар — мөшрикләр дип атады, аларга мәңгелек булган җәһәннәм белән янады. *Тәүхид әр-рубубияның* мәҗбүри булган шартын үтәмәгәнгә, ягъни, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылмаганга күрә, Аллаһ Үзенең илчесенә ﷺ аларның гомерләрен һәм малларын хәләл кылды.

Бар әйткәннәрдән дә шул ачык чагыла: мөселман булыр өчен, бер Аңа гына гыйбадәт кылмыйча торып, Аллаһны бердәнбер Раббы дип тану гына җитми һәм бу сине җәһәннәм утыннан сакламаячак. Әле ул гына түгел, Аллаһны гыйбадәтеңдә берләмичә торып Аның Раббылыгын гына тану, кешенең үзенә каршы бәхәссез дәлил булып тора. Чөнки Аллаһны Раббылыкта бер дип тану аны ихластан, бернинди дә тиңдәшләр кылмыйча, гыйбадәтен бердәнбер Аллаһка гына юнәлтергә өндәп тора һәм бер Аңа гына гыйбадәт кылу бурычын йөкли.

# «Ләә иләәһә иллә-Ллаһ» шәһадәте — тәүхид сүзләре

Тәүхиднең өч төргә бүленүе — аерым өч төр тәүхид бар һәм алар бер-берсе белән бәйләнмәгән, аның берсен генә куллансаң да җиткән, ә калганнарын санга сукмасаң да була, алар арасында мөһимрәге дә, мөһимлеге азрак булганы да бар дигәнне аңлатмый. Адәм баласы бары тик өч төрен дә кулланып яшәсә генә тәүхидне тормышка ашырып яшәүче булып исәпләнә. Кем дә кем шул тәүхиднең бер төрендә генә булса да Аллаһка тиңдәшләр кыла икән, ул, әйтерсеңлә, бар төрендә дә Аңа тиңдәшләр кылган була, чөнки алар арасында үзара бәйләнеш бик тыгыз.

Мисал буларак, дога белән бер Аллаһ кына булдыра ала торган нәрсәне башка берәүдән сораучы кешене китереп була. Бу кеше барлык өч төр тәүхидтә дә Аллаһка тиңдәшләр кыла.

Ул Аллаһка гыйбадәттә тиңдәшләр кыла, чөнки гыйбадәт төрләреннән булып саналган дога белән башка берәүгә дәшә, шулай итеп, Аллаһның иләһлектә бердәнбер (*тәүхид әл-улүһия*) икәнлегенә каршы килә.

Ә Аллаһның Раббылыкта бердәнбер (*тәүхид әр-рубубия*) икәнлегенә килсәк, бу кеше нинди дә булса файдага ирешергә, үзеннән нинди дә булса зарарны алуга өмет итеп, Аллаһтан башка берәүгә дәшә, чөнки, ул дога белән дәшкән затны Аллаһның мөлкәтендә идарә итә ала, аның үтенечен канәгатьләндерә ала дип ышана.

Аллаһның камил исемнәр һәм сыйфатларында бердәнберлегенә (*тәүхид әл-әсмә үә әс-сыйфат*) килгәндә, бу кешенең кылган гамәленнән шуны аңларга мөмкин: янәсе, дога белән дәшкән зат — ишетүче, якын, аңа дәшкәннәрнең барчасын да ишетә, аларның теләкләрен үти, сораганнарын бирә ала.

Бары тик Аллаһ кына хакыйкый иләһ икәнлеге «*Ләә иләәһә илл-ә-Ллаһ*» — Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы иләһ юк дигән шәһадәт сүзләрендә чагыла. Бу бөек шәһадәт кәлимәсенең мәгънәсе шуннан гыйбарәт: мәхлукатлары тарафыннан Аллаһтан башка беркем дә гыйбадәткә лаек түгел. Чөнки Аллаһтан башка беркем дә камиллек һәм бөеклек сыйфатлары, Ул гына Бөек Раббы һәм барча нәрсәне дә Халык кылучы кебек иләһи сыйфатларга ия түгел. Бары тик Ул гына галәмнәрдәге бар процесслар белән дә идарә итә, Ул гына барлык камиллек сыйфатлары иясе һәм барлык кимчелекләрдән дә ерак тора, шунлыктан, Аның каршысында гына түбәнсенергә һәм буйсынырга кирәк. Аллаһ Тәгалә мәхлукатларны берүзе генә иң баштан

халык кыла һәм аларны яңадан кире торгыза, боларны башкарганда Аның белән янәшә беркем дә катнашмый. Болар — бары тик Ул гына гыйбадәткә лаек һәм бу гыйбадәттә Аның белән бергә беркемнең дә булырга хакы юк дигәнне аңлата.

# «Ләә иләәһә иллә-Ллаһ» шәһадәт сүзләренең шартлары

Адәм баласының Ислам диненә кергәнлеген аңлаткан шушы бөек сүзләр йөрәктән чыксын, аны әйткән кешегә файда китерсен өчен җиде шарт үтәлергә тиеш. Моңа күрсәтмәләр Коръәндә дә, Сөннәттә дә бар. Монда сүз бу шартларны яттан белү түгел, ә аларның мәгънәләренә тотыну хакында бара. Шулай да булуы бар: кемдер әлеге шартларны санап бирә алмас, әмма шуларны үтәп яшәргә мөмкин. Ә башка берәү барлык шартларны да белергә мөмкин, әмма, шуңа да карамастан, киресен эшләргә мөмкин.

• **Беренче шарт — гыйлем**, аның капма-каршысы — белемсезлек, наданлык.

Монда сүз кире кагу (*ләә иләәһә*) һәм раслауны (*иллә-Ллаһ*) үз эченә алган әлеге шәһадәтнең мәгънәсен белү күз алдында тотыла.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Бел: Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы иләһ юк**» «Мөхәммәд», 19.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...Хакыйкатьне чын күңелдән белгәннәр шәфәгать итүдән мәхрүм түгел**» «Әз-Зухруф», 86.

Ягъни, Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы иләһ юк дип телләре белән әйткән шәһадәт сүзенең мәгънәләрен йөрәкләре белән белгәннәр турында сүз бара.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«(Һәрчак) **гаделлек белән** (генә) **эш иткән Аллаһ, гыйбадәткә Үзеннән башка лаеклы зат юклыгына таныклык** (шәһадәт) **бирде; фәрештәләр дә, гыйлем ияләре дә шулай эшләде. Аннан башка (гыйбадәткә лаеклы булган) бер иләһ тә юк, Ул — Бөек Кодрәт һәм Хикмәт иясе**» «Әли-Гыймран», 18.

• **Икенче шарт — ышану**, аның капма-каршысы — шикләнү.

Әлеге шарт, бу сүзләрне әйткән кеше, бернинди шикләнү хисе дә кичермичә, нәрсә әйткәнлегенә нык ышанудан гыйбарәт.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Бары тик Аллаһка үә Аның расүленә иман китергәннәр, соңрак шикләнмәгәннәр, Аллаһ юлында малын үә җанын кызганмыйча көрәшкәннәр генә мөэминнәр. Менә шундыйлар гадел кешеләр**» «Әл-Хуҗурат», 15.

Шулай итеп, Аллаһ Тәгалә Үзенә һәм Аның илчесенә карата булган иманның ихласлыгының шарты итеп шикләнү булмауны атады.

«Әс-Сахих»та Әбу Һурәйраның (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән килгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы иләһ юк һәм мин — Аллаһның илчесе дип шәһадәт китерәм, дөреслектә, кем шушы сүзләрдә шикләнмичә Аллаһны каршы алса, ул, һичшиксез, Җәннәткә керәчәк***». Мөслим, 27.

• **Өченче шарт — кабул итү**, аның капма-каршысы — кире кагу.

Бу — сүзләрдә чагылган һәм гамәлләрдә раслаган шушы шәһадәт таләп иткән нәрсәләрне йөрәк белән кабул итү һәм шәһадәтнең мәгънәсенә каршы килә торган бар нәрсәне дә кире кагу.

Аллаһның илчеләрен кире каккан кешеләр алай эшләмәде. Алар хакында Аллаһ Тәгалә болай дип әйтте:

«**Синнән алда да нинди генә җирлеккә кисәтүче пәйгамбәрләр җибәрсәк тә, андагы көр тормышта яшәгәннәр: «Дөреслектә, без ата-бабаларыбызны шундый дин тотканнарын күрдек, без дә алар тоткан юлдан барабыз», — диделәр**» «Әз-Зухруф», 23.

Ә имансызларга килгәндә, алар хакында Аллаһ болай дип әйтте:

«**Аларга: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы иләһ юк», — дигәч, алар йөз чөерделәр һәм әйттеләр: «Без тилергән бер шагыйрьгә ышанып, табынган иләһләребездән ваз кичәргә тиешмени?**» «Әс-Саффәт», 35-36.

«Әс-Сахих»та Әбу Муса Әл-Әшгәридән (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителгән хәдистә Пәйгамбәребез ﷺ болай дип әйтте: «***Дөреслектә, Аллаһ мине кешеләргә җибәргән күрсәтмәләр һәм гыйлем җиргә яуган яңгырга тиң. Җирнең бер өлеше уңдырышлы булган, ул үзенә суны сеңдергән һәм анда бик күп төрле үсемлекләр, үләннәр үскән. Икенче бер өлеше тыгыз булган, үзендә суны тоткарлаган һәм Аллаһ аны кешеләргә файдага юнәлдергән: алар бу суны үзләренә, малларына эчерергә, игеннәрен сугарырга кулланганнар. Яңгыр, шулай ук, үзендә суны тоткарламаган һәм бернәрсә дә үсмәгән тигез җиргә дә яуган. (Җирнең шушы өлешләре) Аллаһның динен аңлап, миңа җибәрелгән нәрсәләрдән файда алып, үзләре гыйлем алган һәм аны башкаларга да тапшырган кешеләр***

***белән бер, шулай ук, үзе моңа мөрәҗәгать итмәгән һәм миңа Аллаһ тарафыннан җибәрелгән күрсәтмәләрне кабул итмәгән кешеләргә тиң***». Әл-Бохари 79, Мөслим 2282.

• **Дүртенче шарт — буйсыну**, аның капма-каршысы — буйсынмау, карышу.

Бу — шәһадәт сүзләре ишарә иткән, ихластан бер Аллаһка гына гыйбадәт кылу таләбенә буйсыну, һәм Аннан башка кемгә дә, нәрсәгә дә булса гыйбадәт кылудан баш тарту.

Аллаһ Сүбханәһү үә Тәгалә әйтте:

«**...Раббыгызга юнәлегез һәм Аңа буйсыныгыз...**» «Әз-Зумәр», 54.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Кем игелек кылган хәлендә үзенең йөзен Аллаһка буйсындырды — шул ышанычлы тоткага тотынды**» «Локман», 22.

«Ышанычлы тотка» дип «ләә иләәһә илләә-Лләһ» сүзләре күз алдында тотыла.

• **Бишенче шарт — тугрылык** (дөреслек), аның капма-каршысы — ялганлап әйтү.

Монда сүз, адәм баласы бу сүзләрне әйткәндә, аның йөрәге теле белән «бер сүздә» булырга тиешлеге хакында бара.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Әлиф. Ләм. Мим. «Без иман китердек», — дип әйткәннән соң, безне калдырырлар, авырлыклар аша сыналмабыз дип уйлыйлармы әллә кешеләр? Без аларга кадәр яшәп киткәннәрне дә сынаулар аша уздырдык. Аллаһ, һичшиксез, дөресне сөйләүчеләрне дә, ялган сөйләүчеләрне дә беләчәк**» «Әл-Гәнкәбут», 1–3.

Икейөзлеләргә (монафикълар) килгәндә, алар хакында Аллаһ Тәгалә болай дип әйтте:

**«Кешеләр арасында: «Без Аллаһка һәм Ахирәт көненә иман китердек», — дип әйтүчеләр бар. Ләкин алар иман китерүчеләрдән түгел. Алар Аллаһны һәм иманга килүчеләрне алдамакчы булалар, ләкин башкаларны түгел, үзләрен генә алдыйлар, тик шуны сизмиләр. Аларның йөрәкләрендә чир бар. Аллаһ аларның чирләрен тагын да арттырды. Ялган сөйләүләре өчен, аларга үтә авыртулы газап** (билгеләнде инде)**»** «Әл-Бәкара», 8-10.

Ике «Сахих» җыентыгында да Мугәз ибн Җәбәлдән (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ болай диде: «***Үзенең йөрәге белән тугры булган хәлдә, кем генә Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы бер иләһ тә юк һәм Мөхәммәд — Аллаһның илчесе дип шәһадәт китермәсен, шул кешене Аллаһ, һичшиксез, Утка харам кылыр***». Әл-Бохари, 128; Мөслим, 32.

• **Алтынчы шарт — ихласлык**, аның капма-каршысы — ширек.

Монда сүз гыйбадәтләрне бары тик Аллаһ ризалыгы өчен генә башкару нияте белән, гамәлләребезне ширекнең барча булган катышмаларыннан да чистарту хакында бара.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«...Ә бит аларга Аның каршында ихластан динен чистартып, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга әмер ителгән иде»** «Әл-Бәййинә», 5.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Диндә ихлас булган хәлдә Аллаһка гыйбадәт кыл! Дөреслектә, пакь дин бер Аллаһка гына багышланырга мөмкин»** «Әз-Зумәр», 2-3.

Әл-Бохариның «Сахих» җыентыгында Әбу Һурәйрадан (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителгән хәдистә, Пәй-

гамбәребез ﷺ әйтте: «***Кыямәт көнендә минем шәфәгатем сәбәпле иң зур бәхеткә ирешүче кеше булып «Ләә иләәһә иллә-Ллаһ», — дип ихластан, чын йөрәгеннән әйтүче булыр***». Әл-Бохари, 99.

• **Җиденче шарт — мәхәббәт**, аның капма-каршысы — нәфрәт.

Бу мәхәббәт  шәһадәт сүзләренең үзләренә, алар нәрсә таләп итә һәм нәрсәгә күрсәтә — шуңа, һәм дә барча булган шартларны да үтәп аның буенча гамәл кылучыларга карата чагыла. Шулай ук, әлеге сүзләрнең капма-каршысы буларак, күп иләһләргә табыну һәм күп иләһләргә табынучыларга карата нәфрәт[1] күз алдында тотыла.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Кешеләрнең кайберләре Аллаһтан башкаларны Аңа тиңдәш итәләр һәм шул иләһләрен Аллаһны сөйгән кебек сөяләр. Ләкин иман китерүчеләрнең Аллаһны сөюләре күпкә көчлерәк**» «Әл-Бәкара», 165.

Ике «Сахих» җыентыгында да Әбу Һурәйрадан (Аллаһ аннан разый булсын) килгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Мине үзегезнең балаларыгыз, әтиегез һәм калган барча кешеләрдән дә артык яратмыйча торып, сезнең берегез дә чынлап торып иман китермәячәк***». Әл-Бохари, 14; Мөслим, 44.

Ике «Сахих» җыентыгында да Әнәстән (Аллаһ аннан разый булсын) килгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Өч сыйфат белән аерылып торган кеше иманның ләззәтен татыр: Аллаһны һәм Аның илчесен барча нәрсәдән дә артык сөюче, теге яки бу кешене бары тик Аллаһ***

---

[1] Искәрмә: «Нәфрәт» төшенчәсен дөрес аңлау бик мөһим! Монда сүз йөрәк белән кабул итмәү, яратмау, кешеләрнең Аллаһка тиңдәш кылуларын сөймәү, күрә алмау хакында бара. Гаделсезлек белән бутарга кирәкми. Мөселман кешесе һәрвакыт гадел булырга тиеш.

***ризалыгы өчен генә яратучы һәм утка алып ташлаулары́н теләмәгән кебек, көферлеккә дә кире әйләнеп кайтырга теләмәүче».*** Әл-Бохари, 16; Мөслим, 43.

# Гыйбадәтнең әркәннәре

Әйтеп киткәнебезчә, *«иләһ»* — ул мәхәббәт һәм бөекләү нигезендә буйсына торган нәрсә. Менә шушы мәхәббәт һәм бөекләү нигезендә буйсыну гыйбадәт була да инде, гарәп телендә *«гибәәдә»* сүзе белән билгеләнә. Юл хакында *«мугәббәд»* (*«гибәәдә»* сүзеннән ясалган) диләр. Юл аяк белән тапталып беткән, ягъни, бу юл буйсындырылган, диләр. Шуңа күрә дә моннан *«гыйбадәт»* сүзе барлыкка килә — Аллаһ каршында буйсынучанлык, юашлык.

Аллаһка буйсынучанлык — мәхәббәт һәм бөекләү нигезендә Ул әмер иткән эшләрне кылып һәм Ул тыйган гамәлләрне эшләүдән тыелып Аңа буйсыну. Колның йөрәгендә мәхәббәт һәм олылау үзенең Раббысын, Аллаһның Раббылыкта бердәнберлеген һәм Аллаһның исем-сыйфатларында бердәнбер икәнлеген танысач барлыкка килә.

- **Аллаһка мәхәббәт** — гыйбадәтнең мәҗбүри булган шарты булып тора. Әгәр кеше кемнең дә булса каршында коллык хисе белән буйсына, ләкин шул ук вакытта аны күрә алмый икән, аны аңа гыйбадәт кыла дип әйтеп буламы соң? Юк, әлбәттә!

Аллаһ Аңа карата иман китергәннәрнең мәхәббәте хакында болай дип әйтә:

**«Кешеләрнең кайберләре Аллаһтан башкаларны Аңа тиңдәш итәләр һәм шул иләһләрен Аллаһны сөйгән**

**кебек сөяләр. Ләкин иман китерүчеләрнең Аллаһны сөюләре күпкә көчлерәк»** «Әл-Бәкара», 165.

Ике «Сахих» җыентыгында да килгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Өч сыйфат белән аерылып торган кеше иманның ләззәтен татыр: Аллаһны һәм Аның илчесен барча нәрсәдән дә артык сөюче, теге яки бу кешене бары тик Аллаһ ризалыгы өчен генә яратучы һәм утка алып ташлауларын теләмәгән кебек, көферлеккә дә кире әйләнеп кайтырга теләмәүче***». Әл-Бохари, 16; Мөслим, 43.

Мәхәббәттән кала, Аллаһка гыйбадәт, һичшиксез, үз эченә курку һәм өметне дә алырга тиеш.

• **Аллаһ каршында курку.** Кеше, шулай ук, Аллаһ каршында курку сәбәпле, Аның әмерләрен һәм тыюларын үтәп Аңа буйсына. Аллаһ бит безне Аны тыңламаган өчен Үзенең газабы белән куркыта. Кеше йөрәгендәге Аллаһ каршындагы әлеге курку Аның әмерләрен һәм тыюларын бозу белән бәйле һәм ул мәҗбүри булып тора.

Аллаһ кешеләргә Аннан куркырга әмер итте:

«**Әгәр сез иман әһелләреннән булсагыз, алардан түгел, ә Миннән куркыгыз!**» «Әли Гыймран», 175.

«**Һәм бары Миннән генә куркыгыз!**» «Әл-Бәкара», 40.

Шулай ук Аллаһ каршында курку, кешенең кылган гыйбадәте Аллаһ тарафыннан кабул кылынмавы сәбәпле дә булырга мөмкин. Аллаһ Тәгалә әйткәнчә:

«**Дөреслектә, Раббыларының газабыннан курыкканнар, аятьләренә** (иманга этәрә торган билгеләренә) **иман китергәннәр, Раббыларына тиңдәшләр кылмаганнар, Раббылары янына кайтарылачакларын белеп, куркып садакаларын ихлас күңелдән кайтарганнар — алар барысы да изгелекләр кылырга ашкынып торалар һәм бер-берсен шушы юлда уздырырга тырышалар**» «Әл-Муэминун», 57-61.

Әт-Тирмизи һәм Әхмәд җыентыкларында килгән хәдистә, Гаишә (Аллаһ аннан разый булсын) Пәйгамбәребездән ﷺ әлеге аять хакында сорады: «Йә, Аллаһның илчесе, Аллаһның: «**...куркып, садакаларын ихлас күңелдән кайтарганнар...**» сүзләре зина кылган, хәмер эчкән, урлашкан кешеләрне күздә тотып әйтелгәнме?» Ул: «***Юк, и, Әс-Сиддык кызы! Монда сүз уразаларын тоткан, намазларын укыган, мохтаҗларга мал таратканнарның шушы гамәлләре кабул кылынмас дип куркулары хакында***». Әт-Тирмизи, 3175.

• **Аллаһка өмет.** Аллаһ Тәгалә безгә Аңа өметләнергә әмер итә. Кешенең гыйбадәт кылгандагы йөрәгендәге өмете мәҗбүри булырга тиеш. Аллаһ Тәгалә әйткәнчә:

**«...Аллаһның ярдәменнән өметегезне өзмәгез! Хактыр ки, кәферләрдән башкалар Аллаһ ярдәменнән өметен өзмәс»** «Йосыф», 87.

Кешенең өмете кылган гөнаһлардан соң Аллаһның гафу итүен көтү белән дә бәйле булырга мөмкин. Адәм баласы, кылган гөнаһлары өчен үкенгәннән соң, Аллаһның кичерүенә өмет итә.

**«Гөнаһ кылып үзләренә зарар иткән колларыма әйт: «Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзмәгез, чөнки тәүбә итеп төзәлгәндә, Аллаһ гөнаһларны ярлыкаучыдыр! Ул — Ярлыкаучы, Рәхимле»»** «Әз-Зумәр», 53.

**«Һәм әгәр алар фәхешлек кылсалар яисә үзүзләренә золым итсәләр, алар Аллаһны искә алалар, гөнаһларын кичерүен үтенәләр. Кем кичерсен инде аларның гөнаһларын Аллаһтан башка?»** «Әли Гыймран», 135.

**«Нигә сез Аллаһтан ярлыкау сорамыйсыз? Бәлки, ул сезгә мәрхәмәтле булыр»** «Ән-Нәмел», 46.

Кешенең өмете, Аллаһ адәм баласының кылган гыйбадәтен кабул кылыр һәм аның өчен Үзе вәгъдә иткән әҗерен бирер дип көтү белән дә бәйле булырга мөмкин.

**«Ахирәт көненнән курыккан, Раббының рәхмәтен өмет итүче, төнге сәгатьләрдә сәҗдәгә киткән, аягүрә басып намаз укыган...»** «Әз-Зумәр», 9.

**«Дөреслектә, иман китергән кешеләр, йортларыннан күчеп китеп Аллаһ юлында барлык көчен сарыф иткәннәр, Аллаһның Рәхмәтенә өмет итәләр. Аллаһ — (гөнаһларны) Кичерүче, Рәхимле»** «Әл-Бәкара», 218.

Галимнәр әлеге өч төр йөрәк гамәлләрен гыйбадәтнең баганалары дип атадылар. Чөнки алар, һичшиксез, гыйбадәт кылучының йөрәгендә булырга тиешләр.

# Ширек, көферлек, монафикълык

Аллаһ Аңа иман китерергә һәм Аның бер Үзенә генә гыйбадәт кылырга әмер итте. Әлеге әмерне үтәмәү өч формада чагылырга мөмкин: ширек, көферлек, монафикълык.

## Ширек

«*Ширек*» сүзе «*шәрикә*» дигән фигыльдән барлыкка килгән һәм «(ниндидә булса бер эштә) катнашучы, иптәш булу» дигән мәгънәгә күрсәтә. Ә «*ширек*» сүзе үзе «уртаклашу, партнерлык» дигәнне аңлата.

Гомуми мәгънәдә ширек — бары Аллаһка гына хас булган нәрсәләрдә Аңа тиңдәшләр кылу. Шундый ширекнең өч төре бар:

Ширекнең беренче төре — ул Аллаһка Аның Раббылыгында тиңдәшләр (*ширек*) кылу, ягъни, Аллаһның мәхлукатларын Аның Раббылык сыйфатларында тигезләү яки бу сыйфатларның кайберләрен Аннан башка берәүгә юнәлтү.

Мәсәлән: халык кылу, ризыкландыру, үтерү, галәмнәр белән идарә итү һ.б. Аллаһ Сүбханәһү үә Тәгалә әйтте:

**«Сезне күктән һәм җирдән ризыкландыручы Аллаһтан башка барлыкка китерүче берәр зат бармы? Аннан башка гыйбадәт кылырга лаеклы иләһ юк! Сез хаклыктан никадәр тайпылгансыз!»** «Фәтер», 3.

Ширекнең икенче төре — Аллаһның иләһи исемнәр һәм сыйфатларында Аңа тиңдәшләр кылу, ягъни, Аллаһның мәхлукатларын шушы кайбер исем-сыйфатларында Аның белән тигезләү. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Аңа охшаш беркем дә юк һәм Ул — Ишетүче, Күрүче»** «Әш-Шура», 11.

Ширекнең өченче төре — Аллаһка гыйбадәттә тиңдәшләр кылу, ягъни, гыйбадәт кылырга хакыйкый иләһ буларак, бары тик Аның гына хакы булган гыйбадәттә Аның мәхлукатларын Аллаһ белән тигезләү. Бу намаз, ураза, дога, коткару сорап дәшү, корбан чалу, нәзер һәм башка барлык төр гыйбадәтләргә дә кагыла. Булсын ул зур, кечкенә, мәҗбүри һәм ихтыяри, яшерен һәм билгеле.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Кешеләрнең кайберләре Аллаһтан башкаларны Аңа тиңдәш итәләр һәм шул иләһләрен Аллаһны сөйгән кебек сөяләр. Ләкин иман китерүчеләрнең Аллаһны сөюләре күпкә көчлерәк»** «Әл-Бәкара», 165.

**Зур ширек** — башка затны Аллаһка тиңләп, аңа да Аллаһка гыйбадәт кылган кебек гыйбадәт кылу. Бу төр ширек кешене Ислам диненнән чыгара һәм аның калган бар гамәлләрен дә юк итә. Әгәр дә кеше шундый халәтендә тәүбә кылмыйча үлеп китсә — Җәһәннәмдә мәңге газаплануга дучар ителәчәк. Ул анда үлмәячәк тә, газаплары берникадәр дә җиңеләйтелмәячәк.

**Кече ширек** — зур ширеккә китерергә мөмкин булган барлык гамәлләр, шулай ук дәрәҗәсе белән зур ширеккә

җитмәгән, Коръәндә һәм Сөннәттә ширек дип аталган сүзләр һәм гамәлләр. Аллаһ Тәгалә теләсә, бу гөнаһлы бәндәне Хисап көнендә кичерәчәк, әгәр тели икән, каты газап белән газаплаячак.

Зур һәм кече ширек арасында берничә аермалык бар, әмма алар арасында аеруча мөһимнәре булып түбәндәгеләре тора:

1) Зур ширек Аллаһ Тәгалә тарафыннан бары тик тәүбә кылып кына кичерелә ала, ә кече ширек Аның тарафыннан тәүбәсез дә кичерелергә, шулай ук, Аның теләге буенча, газапка да тартылырга мөмкин.

2) Зур ширек, аны кылган кешенең барлык гамәлләрен дә файдасыз итә, ә кече ширек, аның кайсы гамәленә кергән — шул эшен генә файдасыз итә.

3) Зур ширек, аны кылган кешене диннән чыгарып имансыз итә, ә кече ширек адәм баласын Исламнан чыгармый.

4) Зур ширектә үлгән кеше мәңгелек Җәһәннәмгә керә һәм Җәннәткә керү мөмкинчелегеннән мәхрүм кала, ә кече ширек бу мәсьәләдә башка гөнаһларга тиң.

## Ширек ничек барлыкка килгән?

Ширекнең нигезе һәм кешелек тормышында әлеге кимчелекнең барлыкка килүенең сәбәбе булып борынгы изгеләрне чиктән тыш узып бөекләү, мактау, ихтирам итү тора.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Алар** (Нух халкы)**: «Табына торган иләһләрегезне ташламагыз! Вәд, Сувәг, Йәгус, Йәгук, Нәсрләрдән ваз кичмәгез!» — диделәр. Шулай итеп, алар байтак кешеләрне юлдан яздырды.** (Я, Раббым!) **Син ул залимнәргә адашудан башка һичнәрсә арттырып бирмә»** «Нух», 23-24.

Вәд, Сувәг, Йәгус, Йәгук, Нәср — болар Нух кавемендә яшәгән изгеләрнең исемнәре. Үлемнәреннән соң кешеләр

аларның сынымнарын ясадылар һәм аларга әлеге исемнәрне бирделәр. Моны алар үзләренең борынгы изгеләрен бөекләү, алар хакындагы хәтирәләрне мәңгеләштерү һәм аларның яхшылыклары, өстенлекләре хакында искә төшереп тору өчен эшләделәр. Соңыннан нәкъ менә әлеге эшләре, Аллаһтан кала шушы изгеләрен иләһләштереп, аларга гыйбадәт кылуга китерде.

Нух кавеме гыйбадәт кылган сынымнар соңрак гарәпләр арасында да барлыкка килә дип хәбәр ителә. Вәдкә Дәүмәт әл-Җәндәләдәге Киләб кабиләсе гыйбадәт кылган, Сувәгкә — Хузәйл кабиләсе. Йәгускә башта Мурәд кабиләсе, ә соңыннан Сәбә тирәсендәге Җәүф урынында Бәну Гутайф кабиләсе гыйбадәт кылган. Йәгукка Хәмдән кабиләсе гыйбадәт кылган, ә Нәср Зул-Киләә гаиләсендә, химьярилыларда булган.

Бу сынымнарның исемнәре белән Нух кавеменең изге ирләрен атаган булганнар. Алар үлгәч, иблис кабиләдәшләренә алар еш утырган җирләргә сынымнарын куярга һәм аларның исемнәре белән атауны күңелләренә сала. Алар шулай эшлиләр дә, ләкин ул чагында әле бу сынымнарга гыйбадәт кылмаганнар. Бу буын үлгәннән соң һәм гыйлем юкка чыккач, аларга гыйбадәт кыла башлыйлар.

Шулай ук, алар Адәм нәселеннән булган изгеләр булган дип тә хәбәр ителә. Ул изгеләргә ияргәннәр алардан үрнәк ала торган булганнар Алар үлгәннән соң, алардан үрнәк алган иярченнәре: «Әгәр дә без аларның сүрәтләрен ясасак, алар хакындагы хәтирәләр бездә Аллаһка тагын да катырак гыйбадәт кылу теләген уятып торачак», — диделәр. Шулай итеп, аларның сүрәтләрен ясадылар. Бу буын үлгәч аларны икенче буын алыштырды. Иблис аларга вәсвәсә кыла башлады: «Сезнең ата-бабаларыгыз аларга гыйбадәт кылдылар һәм алар сәбәпле яңгырлар ява иде». Шулай итеп, кешеләр аларга гыйбадәт кыла башладылар.

Игътибар итегез, аларның гамәлләрендә берьюлы ике вәсвәсә берләште. Беренчесе — алар изгеләренең каберләрендә җыела башладылар; икенчесе — аларның сынымнарын ясап, алар җыелып утыра торган урында ул сынымнарны урнаштырып, үзләре шул урыннарда утыра башладылар. Менә бу гамәлләр кешелек тарихында беренче тапкыр Аллаһка тиңдәшләр кыла башлауга китерде. Шуңа күрә дә, менә шушы ике гамәл һәрбер чорда һәм һәрбер илдә ширекнең барлыкка килүенә китерә торган иң бөек алшарт, иң куркыныч юл булып тора.

## Ширекнең кайбер төрләре

• **Гыйбадәтнең төрләреннән булып саналган догада Аллаһка тиңдәшләр кылу.**

Дога — гыйбадәтнең бер төре булганлыктан, аның белән Аллаһтан башка кемгә булса да дәшү ширек булып санала. Шунлыктан, кем дога белән Пәйгамбәребезгә ﷺ, фәрештәгә, изге бәндәгә, кабергә, ташка яки теләсә кайсы башка мәхлукатка дәшә — ул ширек кылучы һәм имансыз кеше була.

Аллаһ Сүбхәнәһү үә Тәгалә әйтте:

**«Кем дә кем, Аллаһ белән янәшә башка иләһләргә дога белән дәшсә, аның бу эшкә һич дәлиле юктыр. Аның хисабы Раббысы хозурындадыр. Дөреслектә, кәферләр уңышка ирешә алмас»** «Әл-Муэминун», 117.

Шулай ук Аллаһның сүзләре:

**«Көймәдә барган чакта (куркыныч янаганда) алар, ихластан диннәрен чистартып, Аллаһка дога белән ялваралар. Аларны коткарып исән-сау килеш коры җиргә чыгарып бастыргач, шул ук мизгелдә Аллаһка тиңдәшләр кыла башлыйлар»** «Әл-Гәнкәбут», 65.

**• Гыйбадәтнең төрләреннән булып саналган нияттә Аллаһка тиңдәшләр кылу.**

Изге гамәлләрен Аллаһның ризалыгы һәм Аның Җәннәтенә лаек булу өчен дип түгел, ә бары тик дөньяви максатларына ирешү яки рия һәм дан казаныр өчен генә кылучыларның гамәлләре шундый. Аллаһ Тәгалә хәбәр иткәнчә, андый кешеләр зур ширек кыла:

«**Берәү дөнья тереклеген генә һәм дөнья тормышының матурлыгын теләсә, Без аларга моны мул итеп бирербез, аларга дөньяви эшләренә кимчелек китерелмәс. Әмма ахирәттә аларга уттан башка җәза булмас, аларның тырышлыклары бушка һәм гамәлләре файдасыз**» «Һуд», 15-16.

Бу төр ширек бик тә яшерен, әмма үтә дә куркыныч.

**• Буйсынуда Аллаһка тиңдәшләр кылу.**

Кем дә кем, Аллаһның шәригатенә каршы килгәнен белә торып та, Аллаһ тыйган нәрсәләрне рөхсәт иткән, ә рөхсәт иткән нәрсәләрне тыйган, алар үзлегеннән теләсә нәрсә сөйләргә хаклы һәм башкалар аларга ияргә тиешләр, дип мәхлукатларга буйсынса — ул аларны үзенә иләһ итеп алган — аларга гыйбадәт кылган була һәм зур ширек кыла. Аллаһ Тәгалә моның хакында болай дип әйтте:

«**Алар** (яһүдләр һәм насаралар) **хәбәрдарларын** (галимнәрен) **һәм заһидларын** (монахларын), **Аллаһ урынына, раббы итеп алдылар. Алар Мәрьям улы Мәсихне дә үзләренә иләһ иттеләр. Ә бит аларга Бер Иләһкә генә гыйбадәт кылу әмер ителде. Аннан башка табынуга лаеклы зат юк. Аллаһ — алар Аңа ширек кылган нәрсәләрдән пакь**» «Әт-Тәүбә», 31.

Бу аятьтә сүз, ә аның мәгънәсе бернинди дә каршылык тудырмый, дога белән галимнәргә, монахларга мөрәҗәгать итү түгел, ә Аллаһның әмерләренә каршы өндәүләрендә,

ягъни, Аллаһның кануннарын бозуда аларга буйсыну хакында бара. Гади бин Хәтим исемле сәхабә: «Ә без бит аларга гыйбадәт кылмыйбыз!» — дигәч, Пәйгамбәребез ﷺ аңа әлеге аятьне шулай итеп аңлатып бирде. Гөнаһ кылырга әмер иткәндә һәм Аллаһның канунын бозганда аларга буйсыну — бу аларга гыйбадәт кылу булып санала инде дип Пәйгамбәребез ﷺ аңа аңлатып бирде. Ул Гадидан: «***Әллә соң алар Аллаһ рөхсәт иткән нәрсәне тыйганнан соң сез дә моны тыймыйсызмы? Әгәр алар Аллаһ тыйганны рөхсәт иткәч сез дә моны үзегезгә рөхсәт итмисезме?***» — дип сорады. Гади (Аллаһ аннан разый булсын): «Әйе, нәкъ шулай!» — дип җавап бирде. Шунда Пәйгамбәребез ﷺ аңа: «***Аларга гыйбадәт кылу менә шул инде ул***», — диде. Әт-Тирмизи, 3095.

- **Мәхәббәттә Аллаһка тиңдәшләр кылу.**

Монда сүз гыйбадәти мәхәббәт хакында бара. Бу — мәхәббәт объектын бөекләү, ихтирам итү, шулай ук аның каршында түбәнсенү һәм буйсынуны күз алдында тота. Шундый төр мәхәббәт белән бары тик бернинди дә тиңдәшләре булмаган Аллаһны гына яратып була. Әгәр дә кол әлеге мәхәббәтне Аллаһтан башка берәүгә юнәлтә икән — ул зур ширек кылган булып исәпләнә. Моңа Аллаһның әлеге сүзләре дәлил булып тора:

«**Кешеләрнең кайберләре Аллаһтан башкаларны Аңа тиңдәш итәләр һәм шул иләһләрен Аллаһны сөйгән кебек сөяләр. Ләкин иман китерүчеләрнең Аллаһны сөюләре күпкә көчлерәк**» «Әл-Бәкара», 165.

## Нәрсә ул көферлек?

Тел ягыннан «*куфр*» дигән гарәп сүзе «каплау», «төрү» дигәнне аңлата. Шәригатьтәге мәгънәсе исә иманның тулаем капма-каршысына күрсәтә һәм Аллаһка һәм Аның илче-

сенә ﷺ ышанмауны аңлата. Кәфер булып чынлап торып та хаклыкны ялган дип исәпләүче һәм, шулай ук, шул хаклыкка шикләнүчене, яки үзенең көнчелеге, горурлыгы, хисләренә иярү сәбәпле кире борылучыны атап була. Шушы сыйфатлар аңа Коръәнгә һәм Сөннәткә ияреергә комачаулыйлар.

## Көферлекнең нинди төрләре бар?

Көферлек, ширек төсле үк, зур һәм кечегә бүленә. Зур көферлек кешене мәңгелек Җәһәннәмгә дучар итә, ә кече көферлек өчен кеше газапка лаек була, ләкин мәңгелеккә түгел.

• **Зур көферлек** биш төрдә чагыла:

***Беренче төр*** — кешенең хаклыкны ялган дип исәпләве (*куфр әт-тәкзиб*). Бу көферлек пәйгамбәрләр һәм илчеләр ялганчы булганнар дип инануны күз алдында тота. Аларны үзенең сүзләрендә яки йөрәгендә ялганчылар дип исәпләгән кеше кәфер була. Аллаһ Тәгаләнең сүзләре моңа дәлил булып тора:

«**Аллаһ турында ялган сөйләгән яки үзләренә хакыйкать килгәннән соң да аны ялганга чыгарганнардан да залимрак кем бар? Әллә кәферләрнең урыны Җәһәннәмдә булмасмы?**» «Әл-Гәнкәбут», 68.

***Икенче төр*** — хаклыкны кире кагу һәм тәкәбберлек сәбәпле булган көферлек (*куфр әл-ибәәи үә әл-истикбәәр*). Мондый кеше Аллаһ илчесенең ﷺ хак икәнлеген белә һәм аның Аллаһтан хаклыкны алып килгәнлеген дә белә, ләкин тәкәбберлеге, кирелеге сәбәпле аның әмерләренә буйсынмый һәм фәрманнарын үтәми.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Менә без фәрештәләргә: «Сез Адәмгә сәҗдә кылыгыз!» — дип әмер иттек. Бөтенесе сәҗдә кылды. Иллә-**

**мәгәр иблис, әмеремне кире кагып, тәкәбберләнде. Шуның белән ул кәфер булды»** «Әл-Бәкара», 34.

***Өченче төр*** — шикләнү сәбәпле булган көферлек (*куфр әш-шәк*). Әлеге төр көферлек пәйгамбәрләрнең дөреслекләрендә икеләнү һәм аларга карата ышанычлык кичермәүдә чагыла. Көферлекнең әлеге төре, шулай ук, «фаразлауда булу» дип тә атала, чөнки фаразлаулар, шикләнүләр ышанганлыкның, инанганлыкның капма-каршысы булып тора.

Аллаһ Тәгаләнең сүзләре моңа дәлил булып тора:

«(Масаеп, күкрәк киереп) **үзенә-үзе золымлык кылып бакчасына керде һәм: «Боларның кайчан да булса юкка чыгуына мин ышанмыймын», — диде. «Кыямәт көне килер дип уйламыйм мин. Әгәр дә** (Кыямәт булып) **Раббымның хозурына килеп бассам, һичшиксез, болардан да яхшырак байлыкка ирешәчәкмен»** «Әл-Кәһф», 36-37.

Иптәше аңа җавап буларак әйтте:

**«Син үзеңне туфрактан, соңрак тамчыдан яралткан, аннан соң сине адәм рәвешенә китергән Аллаһны инкарь итәсеңмени? Миңа килгәндә, Ул Аллаһ минем Раббымдыр һәм мин Раббыма һичбер нәрсәне тиңләмим»** «Әл-Кәһф», 37-38.

***Дүртенче төр*** — хаклыктан йөз чөерү сәбәпле булган көферлек (*куфр әл-иград*). «Йөз чөерү» дип монда Исламнан тулаем йөз чөерү, ягъни, Аллаһның илчесе ﷺ алып килгән нәрсәдән колагы, йөрәге һәм гыйлеме белән йөз чөерүне атап була.

Аллаһ Тәгаләнең сүзләре моңа дәлил булып тора:

**«Кәферләр аларны кисәткән нәрсәләрдән йөз чөерә»** «Әл-Әхкаф», 3.

***Бишенче төр*** — икейөзлелек сәбәпле булган көферлек. Бу кешенең инануында икейөзләнүдә, ягъни, көферлеген яшереп үзен иманлы кеше дип күрсәтүчедә чагыла.

Аллаһ Тәгаләнең сүзләре моңа дәлил булып тора:

«**Чөнки алар башта иман китерде, ахырда иманнан чыкты. Соңрак аларның йөрәкләренә йозак салынды, хәзер инде алар берни аңламый**» «Әл-Мунәфикун», 3.

• **Кече көферлек** — бу төр көферлек кешене кәфер итми, әмма аны каты газапларга дучар итәчәк, ләкин Җәһәннәмдә мәңгелеккә калмаячак. Чынлыкта, кече көферлек — Аллаһ биргән нигъмәтләргә шөкер итмәү, үзенә Коръән һәм Сөннәт текстларында «көферлек» дип аталган барлык гамәлләрне җыя, әмма зур көферлек дәрәҗәсенә җитми. Түбәндә кече көферлекнең кайбер мисалларын санап китәрбез.

Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «***Кешеләрдәге ике сыйфат көферлек булып санала: нәсел агачын гаеп итү һәм мәет булганда акырып-бакырып елау***». Мөслим, 67.

Ул ﷺ шулай ук әйтте: «***Миннән соң*** (минем үлememнән соң) ***бер-берегезнең башын чабып көферлеккә кайтмагыз***». Әл-Бохари, 121; Мөслим, 65.

Бу һәм башка мисаллар кешене Исламнан чыгармый торган кече көферлеккә карый.

## Монафикълыкның ике төре

• **Зур монафикълык**

Мондый төр монафикълык инану белән бәйле. Гади итеп әйткәндә, Исламга бәйләнеш барлыгын әйтеп, көферлекне яшерү. Аллаһ Тәгалә әйткәнчә, моның ише гөнаһта гаеплеләр Җәһәннәмнең иң түбән катында булачаклар.

**«Дөреслектә, монафикълар Утның иң аскы катында булырлар һәм син аларга ярдәмче таба алмассың»** «Ән-Нисә», 145.

• **Кече монафикълык**

Аны тагын «гамәлдәге монафикълык» дип тә атыйлар, ә бу исә, аның чагылышлары бик күп икәнлекне аңлата. Мисал өчен, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Монафикъны өч сыйфат аерып тора: әгәр ул нәрсә хакында булса да сөйли икән — алдый, нәрсәдер вәгъдә итә икән — сүзендә тормый, әгәр аңа нәрсә дә булса да ышанып калалар икән — хыянәт итә (сата)***». Әл-Бохари, 33; Мөслим, 59.

Әлеге хәдис Әбу Һурәйра (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән җиткерелә.

Шулай ук Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Кем дә кем үзендә әлеге дүрт сыйфатны берләштерә — шул чын монафикъ булып тора. Ә кемгә бу сыйфатларның берсе генә булса да хас булса, аннан котылганчыга кадәр бу кешедә монафикълык өлеше булыр. Болар: аңа ышаныч күрсәткәндә — хыянәт итә, нидер сөйләгән чагында — алдый, кем белән дә булса килешү төзегәндә — килешүне үтәми, кем беләндер талашканда — бөтен чикләрне узадыр***». Әл-Бохари, 34; Мөслим, 58.

Әлеге хәдисне Габдуллаһ ибн Гамр (Аллаһ аннан разый булсын) җиткерә.

# Фәрештәләргә иман

Әлеге иман — Аллаһның нурдан бар кылган фәрештәләре бар, Ул аларга билгеле бер вазыйфалар йөкләде һәм фәрештәләр шул эшләрне кылу белән мәшгульләр, шулай ук, Аллаһ аларга тулысынча Аның әмерләренә буйсыну сәләтен һәм шуларны башкарып чыгарга көч бирде дип каты инанудан гыйбарәт.

Аларга иман үз эченә гомуми һәм хас иман китерүне ала.

Хас мәгънәдә иман китерү — Аллаһ һәм Аның илчесе ﷺ исемләп атаган фәрештәләргә һәм аларның сыйфатлары, гамәлләре хакындагы мәгълүматка инану күз алдында тотыла. Ә гомуми мәгънәдә иман китерү — фәрештәләр хакындагы гомуми булган мәгълүматка инанудан гыйбарәт.

Мөслим үзенең «Сахих»ында, шулай ук имам Әхмәд үзенең «Муснәд»ендә Гаишәдән (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителгән хәдистә, Аллаһның илчесе ﷺ: «***Фәрештәләр — нурдан, җеннәр — дөрләп янган уттан, ә Адәм — сезгә нәрсә дип әйтелгән булган — шуннан халык кылынганнар***», — диде.[1]

---

[1] Мөслим, 2996; Әхмәд, 6/158. «Сахих әл-Җәмиг әс-Сагыйр», 3238.

Фәрештәләргә хас булган атрибутларның берсе — канатлар.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Күкләрне һәм җирне яралткан, фәрештәләрне икешәр, өчәр, дүртәр канатлы илчеләр иткән Аллаһка мактаулар булсын. Үзенең мәхлукларында ни тели, шуны арттыра, чөнки Аллаһның һәр нәрсәгә кодрәте җитә**» «Әл-Фәтыр», 1.

Аллаһның илчесенә килгәндә ﷺ, ул Җибрил фәрештәне нинди кыяфәттә халык кылынган булган — шул кыяфәттә күргәнен һәм аның алты йөз канаты булганлыгын хәбәр итте.

Аллаһның әмере белән, фәрештә кеше кыяфәтенә дә керә ала. Мәсәлән, Җибрил (Аллаһның аңа сәламе булсын) Мәрьям каршына күркәм йөзле кеше образында килеп басты. Аллаһның илчесенә килгәндә ﷺ, аның каршына ул ап-ак киемдәге, ялтырап торган кап-кара чәчле кеше кыяфәтендә килде. Шулай ук Аллаһ Ибраһим һәм Лут пәйгамбәрләргә җибәргән фәрештәләр дә кеше кыяфәтендә иделәр, Аллаһның аларга сәламе булсын.

Фәрештәләрнең гыйбадәтләре, тулаем буйсынулары хакында Аллаһ Тәгалә менә нәрсә хәбәр итте:

«**Дөреслектә, Раббың хозурында булучылар** (фәрештәләр) **Аңа гыйбадәт кылудан һич тәкәбберләнмиләр, алар,** (тәсбих әйтеп), **Аны кимчелекләрдән пакьлиләр һәм Аңа гына сәҗдә кылалар**» «Әл-Әграф», 206.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Аның янындагылар** (фәрештәләр) **тәкәбберләнмиләр, Аңа гыйбадәт кылудан армыйлар. Алар армый-талмый кич-көндез Аллаһка тәсбих** (мактау) **әйтәләр**» «Әл-Әнбия», 19-20.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**«Ярлыкаучы Аллаһ бала тудырды** (Фәрештәләр — Аллаһның кызлары)», **— диделәр. Аллаһ бар кимчелектән дә пакь! Алар бит бары тик дәрәҗәле коллар гына. Алар Аллаһ әмеренән кала бер сүз дә сөйләми, бары тик Аллаһ әмере буенча гына гамәл кылалар. Ул аларга кадәр дә, алардан соң да ни буласын белеп тора. Алар бары тик Аллаһ разый булганнарга гына шәфәгать кыла алачаклар һәм үзләре Аннан куркып-калтырап торалар**» «Әл-Әнбия», 26-28.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...Аллаһның әмеренә каршы килми торган, бары тик Аллаһ боерганны гына үти торган фәрештәләр...**» «Әт-Тәхрим», 6.

Коръәннең төрле аятьләрендә, хәдисләрдә фәрештәләрнең исемнәре, аларга тапшырылган вазыйфалар хакында искәрмәләр бар. Мисал өчен, Җибрил фәрештәгә (Аллаһның аңа сәламе булсын) пәйгамбәрләргә вәхи тапшыру вазыйфасы йөкләтелгән булган. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«(И, Мөхәммәд! Син аларга): **«Кем Җибрилгә дошман була ала?»**[1] **— дип әйт. Ул бит аны** (Коръәнне), **Аллаһның әмере белән, синең йөрәгеңә моңа хәтле булган дөрес хәбәрләрне раслар өчен, туры юлга күндерер өчен, мөэминнәрне** (Җәннәт вәгъдә итеп) **шатландырыр өчен иңдерде**» «Әл-Бәкара», 97.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Ул** (Коръән) **— галәмнәрнең Раббысыннан иңдерелде. Аны имин рух** (Җибрил фәрештә) **алып килде.** (Аллаһның колларын) **кисәтүче** (үгетче) **булсын дип, синең күңелеңә** (Коръән) **иңдерелде**» «Әш-Шугәрә», 192-194.

Кайбер хәдисләрдә Микәил фәрештәгә (Аллаһның аңа сәламе булсын) яңгырлар һәм үсемлекләрнең үсешен күзәтү,

---

[1] Бу аять, Җибрилне дошман күреп, Микәилне дус күргән яһүдләргә җавап итеп иңдерелгән (Әт-Табари, 1/307).

ә Исрафил фәрештәгә (Аллаһның аңа сәламе булсын) Кыямәт көне җиткәч быргыга өрү вазыйфалары йөкләтелүе хакында хәбәрләр бар.

Аллаһның илчесе ﷺ төнге намазларында дога белән дәшкәндә өч фәрештәнең исемен атады: «***Я Аллаһ, Җибрил, Микәил, Исрафилнең Раббысы, күкләрне һәм җирне Халык кылучы, билгеле булганны да, яшеренне дә Белүче! Син Үзеңнең колларыңны бер-берсе белән нәрсәгә карата каршылыкта булганнар, шуларны хәл итәсең. Үзеңнең рөхсәтең белән, каршылыклар хасил булган юлдан мине хаклыкка юнәлт. Дөреслектә, кемне телисең, шуны Син туры юлдан алып барасың***».[1]

Коръәндә Җәһәннәм сакчысы булган Мәлик (Аллаһның аңа сәламе булсын) исемле фәрештә хакында да телгә алына. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**««И, Мәлик! Синең Раббың безнең җаныбызны алсынсана!» — дип әйтерләр»** «Әз-Зухруф», 77.

# Фәрештәләрнең төрләре

**1.** Алар арасында Гарешне күтәреп баручылар бар. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Гарешне күтәреп баручылар һәм аны әйләндереп алганнар Раббыларына мактау әйтәләр, Аңа инаналар һәм иман китергәннәр өчен гафу сорыйлар...»** «Гафир», 7.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«...Раббыңның Гарешен сигез фәрештә күтәрер»** «Әл-Хәкка», 17.

[1] Мөслим, 770; әт-Тирмизи, 3420; Әбу Дәуд, 767; ән-Нәсәи, 2/212; Ибн Мәдҗәһ, 1357.

**2.** Алар арасында кешеләрне саклау вазифасы тапшырылганнар бар. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Һәр кешенең алдында да, артында да Аллаһ әмере белән сакларга куелган фәрештәләр бар**» «Әр-Рагд», 11.

**3.** Алар арасында кешеләрнең гамәлләрен язып баручылар бар. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Дөреслектә, сезнең өстегездә сакчы фәрештәләр бар. Ул фәрештәләр Аллаһ хозурында хөрмәтлеләр, алар сез кылган барлык гамәлләрегезне дә белүче**» «Әл-Инфитар», 10-12.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Адәмнәрнең уң ягында һәм сул ягында язып баручы ике фәрештә бар. Кешенең авызыннан чыккан бер генә сүз дә күзәтүче тарафыннан язылмый калмый**» «Әл-Каф», 17-18.

Монда сүз Һәркемнең уң һәм сул ягында урнашкан фәрештәләр хакында бара. Уңда урнашканы — изге гамәлләрне, сулда урнашканы — бозык гамәлләрне яза.

**4.** Аналарның карынында булган яралгыга җан өрү вазыйфасы йөкләтелгән фәрештәләр.

Моның хакында Ибн Мәсгуднең (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән килгән хәдистә хәбәр ителә: «Дөрес һәм ышанычка лаек Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «***Дөреслектә, сезнең һәрберегез дә анагызның карынында кырык көн буена тамчы орлык кыяфәтендә формалаша. Соңыннан ул анда шуның кадәр көн кан төере кебек һәм шуның кадәр көн тән кисәге кыяфәтендә була. Соңыннан аңа фәрештә җибәрелә һәм җан өрелә. Ул фәрештә дүрт нәрсәне язып куерга әмер ала: аның*** (кешенең) ***ризыгын, әҗәлен, гамәлләрен һәм бәхетле яисә бәхетсез булачагын***». Әл-Бохари 3208, Мөслим, 2643.

**5.** Үлем вакытында кешеләрнең җанын алу вазыйфасы тапшырылган фәрештәләр.

Сүз үлем фәрештәсе[1] һәм аның ярдәмчеләре хакында бара. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«(И, Мөхәммәд, син аларга болай дип) **Әйт: «Сезнең җанны алырга вазифаландырылган үлем фәрештәсе җаныгызны алачак. Ахырда Раббыгыз каршына кайтарылачаксыз», — диген**» «Әс-Сәҗдә», 11.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...Берәрегезгә үлем килсә, илчеләребез аның җанын алыр. Бу эштә алар хилафлык кылмаслар**» «Әл-Әнгәм», 61.

Моннан тыш, башка төрдәге фәрештәләр дә бар.

[1] Искәрмә: безнең халыкта үлем фәрештәсен «Газраил» дип атау гадәткә кергән. Әмма динебездә моны раслый торган дәлилләр юк. Шуңа күрә дә җаннарны алучы фәрештәне «Газраил» дип түгел, ә бары тик «үлем фәрештәсе» дип атасак дөрескә туры килер.

# Китапларга иман

Монда сүз Аллаһ Тәгалә тарафыннан илчеләренә (аларга Аллаһның сәламе булсын) иңдерелгән һәм үзендә хак сүз, кешеләргә туры юлны күрсәткән китаплар хакында бара.

Без Коръәндә атап кителгән китапларга ышанабыз. Менә алар:

- Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә ﷺ иңгән Бөек Коръән.
- Мусага пәйгамбәргә (Аллаһның аңа сәламе булсын) иңгән Тәүрат. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Дөреслектә, Без, туры юлга юнәлтү һәм нур итеп, Тәүрат (китабын) иңдердек**» «Әл-Мәидә», 44.

- Гайсә пәйгамбәргә (Аллаһның аңа сәламе булсын) иңгән Инҗил. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Без аларның эзләреннән үк Мәрьям улы Гайсәне җибәрдек. Без аны, аңа кадәр булган Тәүратны раслаучы иттек һәм үзенә Инҗил бирдек. Анда туры юлга юнәлтү һәм нур бар. Без аны** (Инҗилне) **аңа кадәр булган Тәуратны раслый, туры юлга юнәлтә һәм тәкъва бәндәләргә үгет-нәсыйхәт кыла торган** (китап) **иттек**» «Әл-Мәидә», 46.

- Дауд пәйгамбәргә (Аллаһның аңа сәламе булсын) бирелгән Зәбур. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**...Һәм без Даудка Зәбур бирдек**» «Әл-Исра», 55.

• Ибраһим һәм Муса пәйгамбәрләргә (Аллаһның аларга сәламнәре булсын) индерелгән сәхифәләр. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Муса һәм Аллаһның әмерен тулысынча үтәгән Ибраһимгә бирелгән сәхифәләргә язылганнан хәбәрдар түгел иде мени ул?**» «Əн-Нәҗем», 36-37.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Хактыр ки, бу турыда әүвәлге китапларда да, Ибраһим һәм Мусага иңдерелгән сәхифәләрдә дә язылган иде**» «Əл-Əгълә», 18-19.

Моннан тыш, без Аллаһ Тәгалә Үзенең башка пәйгамбәрләренә дә башка төр Китаплар иңдергәненә ышанабыз.

Ә Коръәнгә иман китерүгә килгәндә, башка китапларга иман китерүдән кала, ул аңа иярүне таләп итүе һәм башка Китапларда килмәгән үзенчәлекләре булуы белән аерылып тора.

# Пәйгамбәрләргә иман

Мондый иман, Аллаһ Тәгалә барлык халыкларга да, тиңдәшләре булмаган бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырып илчеләр җибәргәнлегенә каты инануны күз алдында тота. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**««Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз һәм ялган иләһләрдән ваз кичегез!» — дип әйтсеннәр өчен, Без һәрбер өммәткә дә илчеләр җибәрдек»** «Ән-Нәхел», 36.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Үзенә кисәтүче килмәгән бер генә өммәт тә юк»** «Әл-Фәтыр», 24.

Аллаһ Үз китабында исемләп атап киткән барча пәйгамбәрләргә дә ышану тиешле. Аларның саны егерме биш: Адәм, Нух, Идрис, Худ, Салих, Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Йосыф, Лут, Шөгәйб, Юныс, Муса, Харун, Ильяс, Зәкәрия, Яхья, әл-Ясәг, Зүл-Кифл, Дауд, Сөләйман, Әюб, Гайсә һәм Мөхәммәд, аларга Аллаһның салаватлары һәм сәламнәре булсын.

Без, шулай ук, Аллаһ Тәгалә әйткәнчә, алардан кала да илчеләр булганлыгына ышанабыз:

«**Без** (кешеләргә)**, моңа кадәр сиңа кыйссаларын инде сөйләгән илчеләр дә һәм кыйссаларын сиңа әле сөйләмәгән илчеләр дә җибәрдек»** «Ән-Нисә», 164**.**

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Хактыр ки, синнән алда да пәйгамбәрләр җибәрдек. Кайберләре турында сиңа сөйләдек, кайберләре турында берни дә сөйләмәдек»** «Гафир», 78**.**

Без, шулай ук, аларның изге, дөрес, гадел, тәкъва булганлыкларына һәм аларга Аллаһтан әмер ителгән булган барча нәрсәне дә кешеләргә җиткергәннәренә, тулысынча аңлатып биргәннәренә ышанабыз. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Аятьләребезне ачык-төгәл итеп аңлатудан, кисәтүдән башка пәйгамбәрнең бүтән вазифалары бармы әллә?»** «Ән-Нәхел», 35.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Пәйгамбәргә бары** (Аллаһның әмерләрен) **ирештерү вазифасы йөкләтелгән»** «Ән-Нур», 54**.**

Билгеле бер пәйгамбәргә ышану барча пәйгамбәрләргә дә ышану белән тыгыз бәйләнгән. Шуңа күрә дә, кем аларның берсенә генә булса да ышанмаса, башка пәйгамбәрләргә дә ышанмаган кебек, Аллаһ Тәгаләгә дә ышанмаган була. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Сез** (аларга)**: «Без Аллаһка һәм безгә иңдерелгәнгә** (Коръәнгә) **иман китердек. Без, шулай ук, Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкубка һәм бәнү Исраил кабиләләреннән булган пәйгамбәрләргә иңдерелгәннәргә һәм, шулай ук, Муса һәм Гайсәгә һәм башка пәйгамбәрләргә Раббылары тарафыннан бирелгән нәрсәләргә дә иман китердек. Без берсен икенчесеннән аермыйбыз. Без — Аңа** (Аллаһка) **буйсынучылар** (мөселманнар)»**, — дип әйтегез. Әгәр алар сез иман китергән нәрсәләргә иман китерсәләр, туры юлга күнүчеләрдән булырлар. Ә инде**

**йөз чөерсәләр, алар** (сезгә) **капма-каршылыкта булырлар. Тик Аллаһ сине алардан саклар, Ул бит — Ишетүче һәм Белүче»** «Әл-Бәкара», 136-137.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Аллаһның илчесе Раббысыннан иңдерелгән нәрсәләргә иман китерде, мөэминнәр дә** (шулай эшләде)**. Алар барысы да Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Китапларына һәм илчеләренә иман китерделәр. Алар: «Без илчеләрнең берсен дә аермыйбыз», — диделәр»** «Әл-Бәкара», 285.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Дөреслектә, бар шундыйлар** (мәсәлән, яһүдләр һәм насаралар) **— алар Аллаһны һәм Аның илчеләрен инкяр итеп көферлек кылалар, алар Аллаһ белән Аның илчеләрен аерырга телиләр** (Аллаһка иман китереп тә, Аның илчеләренә иман китермиләр)**, алар: «Без кайберләренә генә иман китерәбез, ә кайберләрен инкяр итәбез»», — диделәр; алар шуның** (шушы килделе-киттеле иман һәм көферлек) **арасында үзләренә юл табырга телиләр»** «Ән-Нисә», 150-151.

Ә Мөхәммәдкә ﷺ иман китерүгә килгәндә, безгә ул үзе белән алып килгән бар нәрсәгә дә тулысы белән ышанырга һәм бернинди дә тайпылышсыз аңа ияреергә тиешбез.

# Гаять кыюлыкка ия булган расүлләр (Улүлгазм)

Әлеге исем белән Нух, Ибраһим, Муса, Гайсә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрләрне атыйлар, аларның барчасына да Аллаһның салаватлары һәм сәламнәре булсын!

Аллаһ Тәгалә әлеге расүлләр хакында болай диде:

**«Һәм без пәйгамбәрләрдән сүз алдык: синнән, Нухтан, Ибраһимнан, Мусадан һәм Мәрьям улы Гайсәдән. Хактыр ки, Без алардан катгый ант сүзе алдык»** «Әл-Әзхәб», 7.

**««Динне тотыгыз һәм аңа карата фикер каршылыкларына тарымагыз!» — дип Нухка вәсыять иттек. Сиңа вәхи иткәнебезне Ибраһимга да вәхи иттек. Мусага да, Гайсәгә дә вәсыять иткәнебезне Аллаһ сезгә дә дин итте»** «Әш-Шура», 13.

# Мөхәммәд ﷺ — барча җеннәр һәм кешеләр өчен дә Аллаһның илчесе

Безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ барча җеннәр һәм кешеләр өчен дип җибәрелде.

Аның барча җеннәргә дә җибәрелгәнлеген Аллаһның сүзләре дәлилли:

**«Коръән тыңласыннар дип, бер төркем җенне синең янга җибәрдек. Коръән тыңларга әзерләнеп беткәч, алар бер-берсенә: «Тыныгыз! (тын да алмыйча тыңлагыз!)» — диделәр. Коръән укылып беткәч, алар кисәтүче булып үз кавемнәренә әйләнеп кайтты. Алар: «Әй, кавемебез! Хак сөйлибез: без Мусадан соң иңдерелгән һәм үзеннән алда килгән (бозылган китапларны) дөресләүче, хакыйкатькә һәм туры юлга юнәлтүче бер Китап сүзен тыңладык. Әй, кардәшләребез! Аллаһның кисәтүчесенә буйсыныгыз, Аллаһка иман китерегез һәм Аллаһ сезнең бер өлеш гөнаһларыгызны кичерер һәм сезне әче газаптан коткарыр», — диделәр»** «Әл-Әхкаф», 29-31.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«(И, Мөхәммәд, син болай дип) **Әйт: «Җеннәр кавеменең бер төркеме** (мин Коръән укыганда) **тыңлап, иман китергән икән. Бу турыда мин вәхи аша белдем», — диген. Җен кавеменнән булганнарның бер төркеме болай дигән: «Чыннан да, без туры юлга өнди торган, гадәттән тыш гүзәл Коръән сүзләрен тыңладык һәм иман китердек. Моннан соң без Раббыбыздан кала беркемгә дә гыйбадәт кылмаячакбыз»»** «Әл-Җин», 1-2.

Җеннәрнең Пәйгамбәребез ﷺ янына килүләре, аның ﷺ алар белән сөйләшүе һәм Коръән укуы турында мәгълүматлар бар.

Аның ﷺ барча кешеләр өчен дә җибәрелгәнлегенә килгәндә, моңа бик күп Коръән аятьләре күрсәтә. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Без сине бөтен кешеләргә бары тик сөенечле хәбәр бирер өчен һәм кисәтер өчен генә җибәрдек»** «Сәбә», 28.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«(Син аларга болай дип) **Әйт: «И, кешеләр! Мин — Аллаһның сезнең барчагызга җибәрелгән Расүле...»** «Әл-Әграф», 158.

«(Син аларга болай дип) **Әйт: «Бу Коръән миңа, аның ярдәмендә сезне һәм башка, ул** (Коръән) **ирешкән кавемнәрне кисәтү өчен вәхий ителде»** «Әл-Әнгәм», 19.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Без сине барча кешеләргә Расүл итеп җибәрдек. Шаһит буларак, Аллаһ Үзе җитә»** «Ән-Нисә», 79.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Фурканны** (Коръәнне) **галәмдәгеләрне кисәтү булсын дип, Үзенең колына иңдергән Аллаһ бөекләрнең бөеге»** «Әл-Фуркан», 1.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Без сине бары тик галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрдек»** «Әл-Әнбия», 107.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«...Син китапка ия булганнарга һәм китапсыз наданнарга: «Ә сез буйсындыгызмы (мөселман булдыгызмы)?» — дип әйт. Әгәр инде буйсынсалар, һидаятькә күнгән булырлар. Әгәр дә йөз чөерсәләр, (нишлисең бит), синең өстеңдә — белгәнеңне җиткерү бары тик»** «Әли Гыймран», 20.

Җәбир бин Габдуллаһ (Аллаһ аннан һәм әтисеннән дә разый булсын) Пәйгамбәребезнең ﷺ әлеге сүзләрен җиткерде: «***Минем өчен миңа кадәр булган бер генә пәйгамбәргә дә бирелмәгән биш нәрсә бирелде: дошманнарымның йөрәкләрен бер айлык юл аралыгындагы курку хисе биләп алу белән ярдәм бирелде; барлык җир дә минем өчен намаз уку урыны һәм паклану чарасы ителде, шуңа күрә дә, минем өммәтемдәге кешене кайда гына намаз вакыты тотмасын, шул урында намазын укысын; миңа кадәр булган бер генә пәйгамбәргә дә рөхсәт ителмәгән хәрби табыш малы миңа рөхсәт ителде; миңа шәфәгать кылу мөмкинчелеге бирелде һәм башка пәйгамбәрләр үз халыкларына гына җибәрелгәндә, мин барлык кешеләр өчен дә җибәрелдем***». Әл-Бохари, 335; Мөслим, 521.

Әбу Һурәйрадан (Аллаһ аннан разый булсын) килгән хәдистә Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Мөхәммәднең җаны Кемнең Кулында — шул зат белән ант итәм! Нинди генә яһүди яки насара булмасын, минем хакында ишетеп тә, мин җибәрелгән нәрсәгә иман китермичә үлеп китсә, һичшиксез, Җәһәннәм әһелләреннән булыр***». Мөслим, 153.

Аллаһ илчесенең ﷺ Исламга чакырып үзенең хатларын төрле илләргә җибәргәнлеге билгеле. Персия патшасына, Рим императорына, Мисыр җитәкчесенә, Эфиопия императорына һәм башкаларга.

Мөхәммәднең ﷺ җибәрелгәнлеген таныган, ләкин: «Ул гарәпләр өчен җибәрелгән илче», — дигән яһүдиләрнең һәм насараларның сүзләренә килгәндә — алар урынсыз, чөнки

кем дә кем Аллаһ илчесе алып килгән нәрсәнең хаклыгын таный икән, ул аны һичшиксез тулаем танырга тиеш. Ә Аллаһның илчесе ﷺ үзен бар кешеләр өчен дә җибәрелгәнен әйтте.

Шулай ук, пәйгамбәрлегенең билгеләре аның өчен хак һәм андый билгеләрнең күп булуына да карамастан, Мөхәммәд ﷺ алып килгән шәригатьне ялган дип атаучылыр да булды.

# Мөхәммәд ﷺ — соңгы пәйгамбәр

Аллаһ Тәгалә әйткәнчә, безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ — соңгы пәйгамбәр:

«**Мөхәммәд сезнең арагыздагы бер генә ирнең дә атасы түгел. Ул фәкать Аллаһның илчесе һәм пәйгамбәрләрнең соңгысыдыр**» «Әл-Әхзәб», 40.

Әлеге аятьнең мәгънәсе Мөхәммәднең ﷺ соңгы пәйгамбәр булганлыгына, аннан соң бүтән пәйгамбәрләр булмаячагына күрсәтә.

Галимнәр арасында пәйгамбәр (*ән-нәби*) һәм илче (*әр-расүл*) арасында аерманың нидә икәнлеге хакында фикер каршылыклары булды. Кайберләре: «Алар арасында бернинди дә аерма юк. Шуңа күрә дә барлык пәйгамбәрләр дә расүл, ә барлык расүлләр дә — пәйгамбәр», — диделәр. Ә башкалары исә пәйгамбәр һәм расүл арасында аерма бар, расүлнең миссиясе пәйгамбәрнекенә караганда үзенчәлеклерәк һәм бу, әгәр дә Мөхәммәдтән соң ﷺ башка пәйгам-

бәрләр булмый икән, димәк, расүлләр дә булмаячагын аңлата.[1]

Моңа бик күп хәдисләр дә күрсәтә.

Мисал өчен, ике «Сахих»та да, Әбу Һурәйра (Аллаһ аннан разый булсын) җиткергән хәдистә, Аллаһның илчесе ﷺ болай дип әйтте: «***Дөреслектә, мин һәм миңа кадәр булган пәйгамбәрләр, йорт төзеп, аны бизәп һәм тулаем үзгәртеп, шул йортның бер почмагында кирпич сыярлык урын калдырган кешегә тиң. Кешеләр бу йорт тирәли йөреп, гаҗәпләнеп: «Нигә бу урынга соңгы кирпич куелмаган?» — дип сөйләшә башладылар. Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Мин инде ул кирпич. Мин — пәйгамбәрләрнең мөһере***». Әл-Бохари, 3535; Мөслим, 2286.

Шулай ук, ике «Сахих»та да Җубәйр бин Мутгимнан (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителгән икенче бер хәдис тә килә. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Минем биш исемем бар: Мин — Мөхәммәд һәм Әхмәд, һәм мин — Әл-Мәхи*** (Сөртүче)***, шуның аркылы Аллаһ көферлекне сөртәчәк, һәм мин — Әл-Хәшир*** (Туплаучы, Җыючы)***, шуның аягы янында кешеләр җыелачак, һәм мин — Әл-Гәкиб, аннан соң инде бүтән пәйгамбәрләр булмас***». Әл-Бохари, 3532; Мөслим, 2354.

Мөслим үз җыентыгында Пәйгамбәребезнең ﷺ Әбу Һурәйрадан (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителгән сүзләрен җиткерә: «***Башка пәйгамбәрләрдән минем алты өстенлегем бар: миңа кыска, әмма эчтәлекле сөйләү сәләте бирелгән; миңа дошманнарымның күңелләренә курку хисе салыну белән ярдәм ителде; миңа хәрби табыш***

[1] Дөресрәк фикергә килгәндә, шәригатьтә пәйгамбәр (*ән-нәби*) дип Аллаһтан вәхий алып үзе шул гамәлләрне кылырга һәм иман китергәннәргә шуны әмер итәргә тиеш булган кешене атыйлар. Расүлгә килгәндә, ул Аллаһтан вәхий алып аны Аллаһтан йөз чөергәннәргә ирештерергә әмер ителүче. Расүл иман әһелләренә дә, кәферләргә дә җибәрелгән.

***малы рөхсәт ителде; бар җир дә миңа чиста һәм намаз укырга яраклы кылынды; мин барлык кешеләр өчен дә җибәрелдем һәм соңгы пәйгамбәр булдым***». Мөслим, 523.

Әл-Бохари һәм Мөслим Сәгд бин Әбу Вәккастан (Аллаһ аннан разый булсын) килгән хәдисне җиткерәләр. Пәйгамбәребез ﷺ Гали бин Әбу Талибка (Аллаһ аннан разый булсын) әйткән: «***Миннән соң бүтән пәйгамбәрләр булмаячак аермасы белән генә, Харун Муса каршында нинди урын алып торган булса, минем янәшәмдә шул ук урынны аласың килмиме әллә синең?***» Әл-Бохари, 4416; Мөслим, 2404.

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ соңгы пәйгамбәр икәнлеген ачыктан-ачык раслый торган башка бик күп дөрес хәдисләр дә бар.

Үзенең «Тәфсир»ендә Ибн Кәсир болай дип язган: «Аллаһ Тәгалә Үзенең Китабында, ә Аллаһның илчесе ﷺ үзенең бик күп хәдисләрендә, аннан соң бүтән пәйгамбәрләр булмаячагын хәбәр иттеләр. Кешеләр, аннан соң үзен пәйгамбәр дип атаган барчасы да ялганчы, яла ягучы, Дәдҗәл, адашкан һәм башкаларны адаштыручы икәнлеген белсеннәр өчен».

# СОҢГЫ КӨНГӘ ИМАН КИТЕРҮ

Соңгы көн (*Кыямәт көне*) — үлгәннән соң терелү Көне. Аллаһ колларын каберләреннән исәп-хисап һәм тиешле бәя бирер өчен торгызачак һәм хөкем итәчәк. Шуннан соң аларның бер өлеше Җәннәткә, ә икенче бер өлеше Җәһәннәмгә керәчәк.

Бу көн әлеге дөньяның соңгы көне булганына күрә «Соңгы көн» дип атала. Аллаһ Тәгалә бу бөек көн, ул көндә ниләр булачагы хакында, шулай ук, аның якынлашканлыгын күрсәтә торган билгеләрне кешеләргә хәбәр итте. Коръәндә аның хакында әйтелмәгән бик сирәк кенә сүрәләр бардыр.

Мисал өчен, Аллаһ Тәгалә бу Көн белән ант итә:

**«Кыямәт Көне белән ант итәм...»** «Әл-Кыямәһ», 1.

Аллаһ Тәгалә Үзенең илчесенә ﷺ кешеләр терeләчәкләре хакында ант итергә әмер итте. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Кәферләр үлгәннән соң кире терелмәячәкбез дип уйлыйлар. Әйт син аларга: «Киресенчә, Раббым белән ант итәм, сез, һичшиксез, яңадан терeләчәксез, ахырда**

**гамәлләрегез турында сезгә хәбәр биреләчәк, — диген. — Бу эш Аллаһ өчен бер дә кыен түгел»** «Әт-Тәгәбун», 7.

Аллаһ Тәгалә бу Көнгә иман китергәннәрне мактап телгә ала:

«**...Алар сиңа иңдерелгәнгә һәм сиңа хәтле** (булган илчеләргә) **иңдерелгәнгә иман китерәләр. Алар Ахирәт көненең булуына катгый инаналар. Алар — үзләренең Раббыларыннан булган туры юлга күнүчеләр һәм алар** (гына) **өстенлеккә ирешүчеләр»** «Әл-Бәкара», 4-5.

Аллаһ Тәгалә Соңгы Көнгә ышанмаганнарны шелтәли:

«**Дөреслектә, Аллаһ белән очрашуны ялган дип санаучылар һәм туры юлдан бармаганнар хәтәр зарар күрәчәк»** «Йунус», 45.

Аллаһ Тәгалә бу көннең якынлашканын хәбәр итте:

«**Кыямәт көне якынлашты һәм ай ярылды»** «Әл-Камәр», 1.

## Ачык күренеп тора торган мисаллар һәм фикерләүгә нигезләнгән дәлилләр аша, аллаһ тәгалә бу көннең киләчәген дәлилли

***Ачык күренеп тора торган мисалларга килгәндә***, Аллаһ Тәгалә кешеләргә бу дөньяда үтергәннән соң кире терелткәннәр хакында хәбәр итте. Ул шундый алты хәлне искә ала:

***Беренчесе:*** Аллаһ Тәгалә әйтте:

**««Ий, Муса, без Аллаһның Үзен үз күзләребез белән ап-ачык итеп күрмичә, сиңа ышанмыйбыз», — дип карап торганда, сезне яшен сукты. Бәлки шөкер итәрсез дип, үлгәннән соң сезне яңадан терелттек»** «Әл-Бәкара», 55-56.

Монда сүз Муса пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе булсын) кабиләдәшләре хакында бара. Әлеге сүзләрне әйткәннән соң Аллаһ аларны үтерде һәм соңыннан кире терелтте.

***Икенчесе:*** Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Менә сез кеше үтердегез һәм шул хакта** (кем үтерде дип) **бер-берегезне гаепләп ызгыштыгыз. Аллаһ — яшергәнегезне ачып күрсәтүче. Без аларга: «Сез аңа** (мәеткә) **аның** (чалган сыерыгызның) **бер әгъзасы белән сугыгыз!» — дидек. Менә шулай итеп, Аллаһ мәетләрне терелтә, сезгә аятьләрен-билгеләрен күрсәтә. Бәлки сез акыл йөртеп карарсыз»** «Әл-Бәкара», 72-73.

Монда сүз, шулай ук, Исраил кавеменнән булган Муса пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе булсын) кабиләдәшләре хакында бара. Алар үтерүченең кем икәнен белергә теләп бер-берсе белән бәхәсләшә башладылар. Шул хәлләрдән соң аларга сыерны корбан чалып, шуның бер әгъзасы белән мәеткә сугырга әмер ителде. Шулай эшләгәннән соң мәет терелеп үзен үтергән кешегә күрсәтте һәм кире үлде.

***Өченчесе:*** Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Син, меңләгән сандагы халыкның, үлемнән куркып, яши торган җирләрен ташлап чыгып китүләре турында фикер йөртеп карамадың мени? Аллаһ аларга: «Үлегез!» — диде. Шуннан соң Ул аларны терелтте. Дөреслектә, Аллаһ — кешеләр өчен фазыйләт иясе. Ләкин кешеләрнең күбесе шөкер итми»** «Әл-Бәкара», 243.

Монда сүз Исраил кавеменнән булган кешеләр хакында бара. Бер-берсе арасында чума авыруы таралгач, алар, котылып калырга теләп, йөгерә башладылар. Ә Аллаһ Тәгалә аларны үтерде, соңыннан терелтте.

***Дүртенчесе:*** Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Син, шулай ук, җимерелеп беткән авыл яныннан үтеп баручы кеше турында да фикер йөртеп кара. Ул кеше: «Бу үлеп беткән авылны Аллаһ ничек терелтер икән?» — диде. Шулчак, Аллаһ аны үлеләндерде. Йөз ел үтте һәм Ул аны янә терелтте. (Аллаһ аннан): «Син биредә никадәр вакыт булдың?» — дип сорады. Ул: «Монда бер көн яисә көннең бер өлеше дәвамында булдым», —**

**диде. Аллаһ аңа: «Алай гына түгел, син бу урында йөз ел булдың. Әнә, бер дә үзгәрмәгән ризыгыңа һәм эчемлегеңә кара. Шунда ук ишәгеңә дә кара. Без бит моны, кешеләргә сине дәлил итеп китерер өчен эшләдек. Хәзер инде сөякләргә кара. Без аларны җыябыз, шуннан соң аларны иткә төрәбез», — диде. Бар да ачыклангач, теге кеше: «Хәзер, һичшиксез, Аллаһның бар нәрсәгә кодрәте җитүен беләм инде», — дип әйтте»** «Әл-Бәкара», 259.

Шулай итеп, җимерелеп беткән бистә яныннан узып барган бу кеше, Аллаһ Тәгалә моның барысын да кире терелтә алуын күз алдына да китермәгән булган. Шуннан соң Аллаһ аның үзен йөз елга үтертте һәм соңыннан кире тергезде.

*Бишенчесе:* Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Менә Ибраһим: «И, Раббым! Син миңа мәетләрне ничек терелтүеңне күрсәт» — диде. Аллаһ: «Син иман китердең түгелме соң инде?» — дип сорады. Ул: «Әлбәттә, китердем, ләкин йөрәгем тынычланыр иде», — диде. Аллаһ аңа: «**(Алай булса), **дүрт кош алып, аларны үзеңә китереп кысып, суй. Аннан соң, түшкәләрен кисәкләргә бүлеп, һәрбер тау башына берәр кисәген куй. Шуннан соң син аларны чакыр. Алар синең янга шундук очып килер. Аллаһ — Бөек Кодрәт һәм Хикмәт иясе икәнен бел!» — диде»** «Әл-Бәкара», 260.

Монда сүз Ибраһим пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе булсын) үзенең Раббысыннан үлекләрне ничек итеп терелткәнлеген күрсәтүне сораганы әйтелә. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә аңа дүрт кошны чалырга һәм аларның төрле кисәкләрен тауның әйләнә-тирәсенә ташлап чыгарга, соңыннан аларны үзе янына дәшергә әмер итә. Шулай эшләгәннән соң бу кошлар аның янына очып киләчәкләрен әйтә.

***Алтынчысы:*** анысы тау куышлыгы эчендә озак елларга калган кешеләр турында. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Алар мәгарәдә өч йөз һәм тагын тугыз ел уздырдылар**» «Әл-Кәһф», 25.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Шулай итеп,** (мәгарәдә күпме ятканнары турында) **бер-берсеннән сораштырсыннар дип, Без аларны уяттык**» «Әл-Кәһф», 19.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Шулай итеп, Аллаһның вәгъдәсе хак һәм Кыямәт көненең булуында шик юк икәнлеген белсеннәр өчен, Без алар хакында кешеләргә белгерттек**» «Әл-Кәһф», 21.

***Фикерләүгә нигезләнгән дәлилләргә килгәндә***, үлгәннән соң кире терелеп булачагын төрле юллар белән раслап була.

***Беренчесе:*** беренче тапкыр барлыкка килүгә (*халык кылынуга*) нигезләнеп, икенче тапкыр да барлыкка килеп булганлыгы хакында нәтиҗә ясау. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Ул үзенең яратылганлыгын онытып: «Бу череп беткән сөякләрне кем терелтә алсын?» — дип безгә мәсәл китерә. «Аларны беренче тапкыр Кем барлыкка китергән — менә Ул терелтер. Ул һәр яратылган хакында белүчедер», — диген**» «Йә син», 78-79.

***Икенчесе:*** нәрсәнең дә булса аның капма-каршысыннан барлыкка килә алуына нигезләнеп дәлилләнү, мисал өчен, кызу, коры булган ялкынның яшел, салкын һәм дымлы булган ягачтан барлыкка килүе. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Ямь-яшел булып үскән агачтан Ул сезгә ут чыгарды. Менә шуннан сез ут аласыз**» «Йә син», 80.

***Өченчесе:*** бөек булган нәрсәләрне барлыкка китерә алучы, кечерәк булган нәрсәләрне дә барлыкка китерә алуга нигезләнгән дәлил. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Әллә соң күкләрне һәм җирне барлыкка китергән зат шуңа охшаш тагын башка нәрсәләрне барлыкка китерергә кодрәтле түгел мени?»** «Йә син», 81.

***Дүртенчесе:*** җирнең үлеменнән соң кире терелә ала алганы кебек, мәетләрнең дә терелә аласына нигезләнгән дәлил. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Син җансыз, коп-коры туфракны күрәсең. Бу да Аның дәлилләреннәндер. Без шул коры туфрак өстенә яңгыр яудыргач, туфракка җан керә, бүртә. Аңа җан бирүче, әлбәттә, мәетләрне дә терелтә ала. Аның кодрәте һәрнәрсәгә җитә»** «Фуссиләт», 39.

***Бишенчесе:*** йокыдан соң уяну килә, йокы — үлемнең туганы, ә уяну — үлемнән соң кире терелүгә тиң икәнлегенә нигезләнгән дәлил. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Ул** (Аллаһ) **сезне төнлә, җаныгызны алып үлеләндерә. Ул сезнең көндезен ни кылганыгызны** (ниләр кәсеп иткәнегезне) **белә. Шуннан соң Ул сезне** (сезнең гомергә дип) **билгеләнгән вакыт** (тулысынча) **үтәлсен өчен,** (иртә белән уятып) **яңадан терелтә. Аннан соң** (Кыяммәттә) **сезнең кайту урыныгыз Аның хозурында булачак. Шуннан соң Ул сезгә** (шунда) **кылган гамәлләрегез турында хәбәр итәчәк** (һәм шул гамәлләрегезгә күрә Ул сезне хөкем итәчәк)**»** «Әл-Әнгам», 60.

***Алтынчысы:*** Аллаһның хикмәте, гаделлеге сәбәпле кире терелүнең һәм кылган гамәлләр өчен җавап бирүнең котылгысыз икәнлегенә нигезләнгән дәлил. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Болай гына, кызык өчен генә безне яралтты һәм, чынлап та, Ул безне Үз хозурына кайтармас, — дип уйлыйсызмы?»** «Әл-Мөэминун», 115.

# Әлеге Сәгатьнең якынаю вакыты

Моның хакындагы гыйлемне бары тик Аллаһ кына белә, ә без, бары тик, аның һич көтмәгәндә килүен генә әйтә алабыз. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«(И, Мөхәммәд!) **Алар** (Мәккә мөшрикләре) **синнән Кыямәт Сәгате турында: «Кайчан җитәр икән ул?» — дип сорыйлар. Син** (аларга болай дип) **әйт: «Аның турында булган гыйлем — бары тик Раббым хозурында. Аның вакыты** (Кыямәт Сәгате) **хакында Аннан башка беркем дә ачыклык кертә алмый. Күкләрдә һәм җирдә булган мәхлуклар өчен Кыямәт Сәгате турында белү бик авыр.** (Шуңа күрә, ул билгесез булып калыр). **Ул** (Кыямәт Сәгате) **сезгә кинәт, көтмәгәндә генә килер».** (И, Мөхәммәд!) **Алар синнән, аның турында гыйлемең бардыр дип сорыйлар. Син аларга: «Ул хакта булган гыйлем — бары тик Аллаһ хозурында. Ләкин кешеләрнең күбесе шуны белмиләр», — дип әйт**» «Әл-Әгъраф», 187.

Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «***Мин менә шушы ике бармак кебек Кыямәт сәгате белән бергә җибәрелдем***». Соңыннан ул кулының имән һәм урта бармагын бергә кушты. Әл-Бохари, 6504; Мөслим, 2951.

Шулай ук, Аллаһның илчесе ﷺ Кыямәт көненең якынлашу вакыты хакындагы сорауларга җавап биргәндә, һәрвакыт аның хакында белмәвен, андый сорау бирүчеләргә тиешле эш белән шөгельләнергә, ягъни, бу көнгә ничек итеп яхшырак әзерләнеп булу хакында уйланырга киңәш итә иде. Кайчакта ул кече Кыямәт көне — үлем хакында сөйли иде.

Мисал өчен, Җибрил (Аллаһның аңа сәламе булсын): «Кыямәт көне хакында сөйләп бир әле?» — дигәч, ул аңа:

«***Соралучы сорау бирүчедән артыгын белми***» — дип җавап бирде. Мөслим, 8.

Шулай ук, имам әл-Бохариның «Сахих» һәм башка җыентыкларда икенче хәдис тә китерелә. Көннәрнең берендә ниндидер бер бәдәви (бедуин, чүл кешесе) Пәйгамбәребездән ﷺ: «Бу Сәгать (Кыямәт көне) кайчан якынлашачак?» — дип сорады, ә Пәйгамбәребез ﷺ аңа: «***Хактыр, бу Сәгать якын, ә син ул көнгә нәрсә әзерләдең?***» — дип җавап бирде. Әл-Бохари, 3688; Мөслим, 2639.

Гаишәдән (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителгән икенче бер хәдистә болай диелә: «Бәдәвиләр Аллаһның илчесе янына килгәч ﷺ һәрвакыт аннан: «Бу Сәгать кайчан киләчәк?» — дип сорыйлар иде. (Көннәрнең берендә) Аллаһның илчесе ﷺ алар арасындагы иң яшенә карап: «***Әгәр дә бу малай шактый озак яшәсә, сезнең өчен бу Сәгатьнең ул картаеп бетерешкәнчегә кадәр җитүе мөмкин***», — диде. Мөслим, 2952.

Әмма Коръән һәм Сөннәттә әлеге Сәгатьнең якынаюына күрсәтә торган кайбер билгеләр бар. Мисал өчен, Аллаһ Тәгалә бу Сәгатьнең зур билгеләреннән булган берничәсен әйтеп китә, алардан: Төтен, Гайсәнең (Аллаһның аңа сәламе булсын) икенче килүе, Яҗүҗ белән Мәҗүҗнең чыгуы, кояшның көнбатыштан атуы һәм бер Хайванның чыгуы.

Аллаһның илчесенә килгәндә ﷺ, ул моңа бәйле булган кайбер аерым мизгелләрне искә ала, алардан: Дәдҗәлнең килүе, көнчыгыш, көнбатыш һәм гарәбстан өстендә булачак өч җир убылуы, шулай ук, Йәмән җирлегеннән чыккан, кешеләрне җыелу урынына куып барачак ут. Моннан тыш, Аллаһның илчесе ﷺ, әлеге билгеләр тормышка ашмыйча торып, бу Сәгать якынлашмас диде: бер үк нәрсәгә чакырган ике бөек гаскәрнең бер-берсенә каршы зур сугышта очрашуы; үзләрен пәйгамбәр дип раслаган утыздан артык ялганчының чыгуы; дөньядан гыйлемнең юкка чыгуы; җир

тетрәүләрнең ешаюы; вакытның кыскаруы; вәсвәсәләрнең барлыкка килүе; кешеләрнең бер-берләрен үтерүләре һәм Хиджәздән, Бусра җирлегендәге дөяләрнең муеннарын яктырта алырдай зур ялкынның барлыкка килүе.

Барча шушы һәм бүтән билгеләр зур һәм кече төргә бүленә. Кече билгеләр, үз чиратында, тормышка ашкан һәм тәмам булганга, дәвам иткән, шулай ук, әлеге мизгелдә тормышка ашмаганнарга бүленә. Зур билгеләргә килгәндә, аларның вакыты әле җитмәгән, әмма шулардан берсе генә булса да үтәлсә, аның артыннан башкалары да иярәчәк.

# Үлем һәм кабердәге хәлләр

Соңгы көнгә иман китерү — Коръән һәм Сөннәттә моның хакында аңлатылган бар нәрсәгә дә, бигрәк тә, үлем һәм аннан соң булган вакыйгаларга ышануны күз алдында тота.

Үлем белән бәйле булган иманга түбәндәгеләр керә:

**1.** Бу дөньяда үлем бар тере булганнар өчен дә котылгысыз икәнлегенә ышану. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Һәр җан иясе үлем әчесен татыр. Аннан соң һәркем Безнең хозурыбызга кайтачак**» «Әл-Гәнкәбүт», 57.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Аллаһның Йөзеннән башка һәрнәрсә һәлак булучыдыр. Ул гына хөкем кыла һәм сез Аның хозурына әйләнеп кайтачаксыз**» «Әл-Касас», 88.

**2.** Һәркемнең дә үлем вакыты төгәл итеп билгеләнгән һәм беркемнең дә ул вакытны кичектерергә дә, арттырырга да көче юк икәнлегенә ышану. Үлемне бар кылып кына калмаган, ә һәммәбезнең дә үлем сәбәбен билгеләгән Аллаһ бу вакытның кайчан җитүен белүче.

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Аллаһның теләгеннән башка бер җан иясе дә үлми**» «Әли Гыймран», 145.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Һәр өммәтнең** (кавемнең һәм буынның) **үзенә билгеләнгән яшәү вакыты бар. Әгәр аларның билгеләнгән вакыты** (әҗәле) **килеп җитсә, алар аны бер генә сәгатькә дә кичектерә дә, якынайта да алмыйлар**» «Әл-Әгъраф», 34.

**3.** Үлем вакыты бары тик Аллаһка гына билгеле икәнлегенә ышану. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Бер кеше дә иртәгә үзенең ни кылачагын белми. Бер кеше дә үзенең кайда үләчәген белми. Шик юктыр, Аллаһ — бар нәрсәне дә белүче, бар нәрсәдән дә хәбәрдар**» «Локман», 34.

**4.** Аллаһ Тәгалә үлем алдыннан ни булачагын хәбәр иткәннәргә ышану:

«**...Әгәр инде берәрегезгә үлем килсә, Безнең илчеләребез** (Үлем фәрештәсе һәм аңа ярдәм итүче фәрештәләребез) **аның җанын алыр. Алар эшләренә кимчелек китермиләр** (әмер ителгәнне һич кичектермиләр)» «Әл-Әнгәм», 61.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«(Үлем түшәгендәге кешенең) **җаны бугазына җиткәч, сез аңа карап торасыз. Без аңа сездән дә якын торабыз, әмма сез күрмисез генә**» «Әл-Вәакига», 83-85.

Монда сүз, үлем хәлендәге кешенең җаны бугазына җиткәч, үлем газабы (агония) башланганы хакында бара. Бу вакытта аның янәшәсендәгеләр аңа карап торалар, ә Аллаһ Тәгаләгә килгәндә, Ул үлүче хакында кешеләргә караганда яхшырак белә. Аның фәрештәләре дә үлем хәлендә яткан кешегә аларга (кешеләргә) караганда якын, тик алар моны күрмиләр.

Гөнаһлы, гаделсез кеше үлгәч, ул бар кылган гамәлләре өчен дә үкенәчәк һәм кире бу дөньяга кайтырга теләр. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Аларның берәрсенә үлем килсә: «Раббым, мине дөньяга кире кайтар! Эшли алмый калган изге гамәлләрне башкарырмын!» — дияр. Юк! Бу аның авызыннан чыккан буш сүз генә. Аларның артларында кубарылачак көнгә чаклы кайтудан тыеп тора торган пәрдә бар»** «Әл-Мөэминун», 99-100.[1]

Имансыз кешенең җанын тәненнән алуга килгәндә, Аллаһ Тәгалә моның хакында болай дип әйтте:

«(И, Мөхәммәд!) **Син шул залимнәрне** (гөнаһлыларны) **үлем газабы кичергән чакта күрсәң иде. Җан алучы фәрештәләр аларга кулларын сузалар** (кыерсыталар, газаплыйлар, сугалар)**: «Я инде, җаннарыгызны чыгарыгыз! Бүген сез, Аллаһ турында** (хаклыктан ерак булган теләсә нинди) **ялган нәрсәләр сөйләгәнегез һәм Аның аятьләре** (иманга этәрә торган билгеләре) **каршында тәкәбберләнгәнегез өчен, түбәнсеткән газапка дучар булырсыз!» — дип әйт»** «Әл-Әнгәм», 93.

Бу сүзләр фәрештәләрнең залимнәргә кулларын сузып, аларны җәфалаулары, сугулары хакында.

Имам Әхмәднең «Муснәд» һәм башка җыентыкларда да әл-Бәра бин Гәзиб сүзләреннән җиткерелгән хәдистә (Аллаһ аннан разый булсын) Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «***Иман китергән Аллаһ колы бу дөньяны калдырып киләсе тормышка киткәндә, аның янына күкләрдән йөзләре кояш кебек балкып торган фәрештәләр төшә. Алар үзләре белән кәфенлек, җәннәттән ислемай алып киләләр һәм***

[1] Искәрмә: Аллаһның әлеге сүзләрендә «Кемнең аннан әйләнеп кайтканы бар?!» — дип, үлемнән соң булачак вакыйгаларны кире кагучыларга җавап бар. Бик теләп кайтырлар иде дә бит! Тик кире кайтырга юл юк шул!

***аннан ерак түгел генә утыралар. Соңыннан аның янына үлем фәрештәсе килеп*** (Аллаһның аңа сәламе булсын) ***баш очына утырыр: «И, изге җан! Аллаһның кичерүенә һәм мәрхәмәтенә чык!» — дип әйтер. Су тамчысы савыт авызыннан ничек агып чыккан булса, ул кешенең дә җаны тәненнән шулай*** (җиңел) ***чыгыр. Үлем фәрештәсе аны кабул итеп ала, ә калган фәрештәләр бу җанны бер мизгелгә дә аның кулында калдырмыйча, Җәннәт кәфенлегенә төрәләр һәм Җәннәт ислемайларын сөртәләр. Шуннан соң аннан иң яхшы мускус исе төсле хуш ис тарала башлый һәм алар аның белән бергә күккә күтәреләләр...***».

Дәвам итеп, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Имансыз колга килгәндә, ул бу дөньяны калдырганда күкләрдән кара йөзле фәрештәләр төшәләр, үзләре белән тупас, кыллы кием алып киләләр һәм аннан ерак түгел генә утыралар. Соңыннан аның янына үлем фәрештәсе килеп баш очына утырыр: «И, кабәхәт җан! Аллаһның ачуына һәм ярсуына чык!» — дип әйтер. Шуннан соң, юеш йоннан тимер тешне суырып алган кебек, үлем фәрештәсе бу җанны да тәненнән шул рәвешле йолкып ала, ә башка фәрештәләр аны шул ук мизгелдә тупас киемгә төрергә дип алалар һәм аннан җир йөзендә була торган иң яман ис аңкый башлый. Соңыннан алар аның белән күккә күтәреләләр...***».[1]

Шулай итеп, үлемнән соң бөек һәм мөһим вакыйгалар, аларның бер өлеше кабердә, ә икенче өлеше үлгәннән соң терелгәч булачак.

Кеше белән кабердә менә нәрсәләр булачак:

---

[1] Әхмәд, 4/284; Әбу Дәуд, 2/281;ән-Нәсәи, 1/282; Ибн Мәдҗәһ, 1/496; Әл-Хәким, 1/37. Сахих хәдис. «Сахих әт-тәргиб үә әт-тәрхиб» (3558). Хәдиснең өзеге генә китерелде.

## Кабер сынавы

Үлгән кешене кабергә иңдергәч, ул анда сынауга дучар була. Аның янына ике фәрештә килеп: «Раббың кем? Динең нинди? Сезгә җибәрелгән кеше кем иде ул?» — дип сораячаклар. Иман китергән кешегә килгәндә, ул: «Минем Раббым — Аллаһ, динем — Ислам», — ә өченче сорауга җавап итеп: «Ул — Аллаһның колы һәм Аның илчесе», — диячәк.

Имансыз бәндәгә килсәк, ул бар сорауга да: «Һәә, һәә, мин белмим», — дип, ә икейөзле һәм шикләнүче кеше: «Белмим, мин бары тик кешеләрнең нидер сөйләгәннәрен ишеттем һәм алар артыннан шуны ук кабатладым», — дип әйтәчәк.[1]

## Кабер ләззәтлеге һәм газабы

Үлгән кеше кабердәге сынаудан соң я ләззәтлек кичереп, яки газабка дучар булып Кыямәт көненә кадәр анда калачак. Тәне һәм җаны белән дә, яисә җаны белән генә.

Ике фәрештәнең соравы белән бәйле булган, барча кешене дә көтәчәк кабер сынавы хакында бик күп аятьләрдә, хәдисләрдә әйтелә. Шулай ук кабер ләззәтлеге һәм газабы хакында да. Боларга тулаем һәм аерым алганда да ышанырга кирәк, әмма без боларның ничек булачагын тәфсилләп сөйләп тормабыз.

Моның хакында раслаучы күрсәтмәләр түбәндәгедән гыйбарәт: Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Пакь сүзләр белән иман китергәннәрне Аллаһ бу дөньяда да, ахирәттә дә ныгытыр**» «Ибраһим», 27.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**...Фиргавен токымын исә хәтәр җәзага тартты — алар иртә-кич утка атылачак. Кыямәт купкан көндә**

[1] Шул ук хәдистә килә.

**Фиргавен токымына җәзаның иң хәтәрен бирегез!»** «Әл-Гафир», 45-46.

Ике «Сахих» җыентыгында да әл-Бәра бин Гәзибтан (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «*...Мөселман кешесенә каберендә сораулар бирелә башлагач, ул: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы бер иләһ тә юк һәм Мөхәммәд — Аллаһның илчесе», — дип шәһадәт сүзләре китерер. Аллаһның:* **«Пакь сүзләр белән иман китергәннәрне Аллаһ бу дөньяда да, ахирәттә дә ныгытыр»** «Ибраһим», 27 *сүзләре шуңа ишәра итә*». Әл-Бохари, 1369, 4699; Мөслим, 2871.

Имам Әхмәднең «Муснәд» җыентыгындагы әл-Бәра бин Гәзибның (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән кителгән хәдистә, башта фәрештәләрнең үлгән кешенең җаны белән күккә менүләре, ә соңыннан аны кире җиргә төшерүләре хакында да хәбәр ителә.

Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «*...Җанын тәненә кайтарырлар, шуннан соң ике фәрештә килеп аны утыртырлар һәм: «Раббың кем?» — дип сорарлар. Ул: «Раббым — Аллаһ!» — дип җавап бирер. Соңыннан алар: «Динең нинди?» — дип сорарлар, ул: «Динем — Ислам!» — дип җавап бирер. Соңыннан алар: «Сезгә җибәрелгән кеше кем ул?» — дип сорарлар, «Ул — Аллаһның илчесе!» — дип әйтер. Шул вакытта алар аннан: «Син моны каян беләсең?» — дип сорарлар. Ул: «Мин Аллаһның Китабын укыдым һәм аңа ышандым!» — дип җавап бирер. Шул чагында күктән тавыш яңгырар: «Минем колым дөресен әйтте, аңа Җәннәттән булган урын-җир җәегез һәм каршында Җәннәт ишекләрен ачыгыз!» Шуннан соң аны шатлык биләп алыр һәм ул Җәннәт ләззәтләкләрен ки-*

***черә башлар, кабере күз күреме җиткән арага кадәр киңәер***».[1]

Ә имансыз кешегә килгәндә, аның хакында Аллаһның илчесе ﷺ болай дип әйтте: «***...Җанын тәненә кайтарырлар, шуннан соң ике фәрештә килеп аны утыртырлар һәм: «Раббың кем?» — дип сорарлар. Ул: «Һәә, һәә, мин белмим!» — дип җавап бирер. Соңыннан алар: «Динең нинди?» — дип сорарлар, ул: «Һәә, һәә, мин белмим!» — дип җавап бирер. Соңыннан алар: «Сезгә җибәрелгән кеше кем ул?» — дип сорарлар, ул тагын: «Һәә, һәә, мин белмим!» — дип җавап бирер. Шул чагында күктән тавыш яңгырар: «Ул ялганлый! Аңа уттан булган урынҗир җәегез һәм каршында Җәһәннәм ишекләрен ачыгыз!» Шуннан соң аны җәһәннәм эсселеге биләп алыр, кабере тараер һәм*** (кабере кысылу сәбәпле) ***кабыргалары бер-берсе белән кушылыр***».[2]

Ике «Сахих» җыентыгында да Әнәс бин Мәлик (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән китерелгән хәдистә, Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «***Аллаһ колын кабергә иңдергәннән соң, аның иптәшләре борылып кайтып китерләр, ә ул аларның аяк киеме тавышларын ишетеп калыр. Аның янына ике фәрештә килер, торгызып утыртырлар һәм: «Син бу кеше — Мөхәммәд ﷺ хакында нәрсә сөйләдең?» — дип сорарлар. Ул: «Ул — Аллаһның колы һәм Аның илчесе дип шәһадәт бирәмен!» — дип әйтер. Шуннан соң аңа: «Үзеңнең утта булган урыныңны кара: Аллаһ аны сиңа Җәннәттәге урын белән алыштырды», — дип әйтелер***».

Соңыннан пәйгамбәребез ﷺ болай дип әйтте: «***Һәм ул бу ике урынны да күрер. Имансыз кешегә килгәндә*** (яки

---

[1] Әхмәд, 4/284; Әбу Дәуд, 2/281; ән-Нәсәи, 1/282; Ибн Мәдҗәһ, 1/496; Әл-Хәким, 1/37. Сахих хәдис. «Сахих әт-тәргиб үә әт-тәрхиб» (3558). Хәдиснең өзеге генә китерелде.

[2] Шул ук хәдистә килә.

икейөзле)*, ул* (фәрештәләргә)*: «Белмим, мин бары тик кешеләр ни сөйләгән — шуны гына кабатладым», — дип җавап бирәчәк. Шунда аңа: «Син белмәдең һәм укымадың!» — дип әйтерләр. Шуннан соң аның ике колак арасына тимер чүкеч белән сугырлар. Ул бик каты итеп акырыр, аны кешеләр һәм җеннәрдән кала, якын тирәдә булган барчасы да ишетер*». Әл-Бохари, 1338, 1374; Мөслим, 2870.

Ике «Сахих» җыентыгында Ибн Гәббәс (Аллаһ аннан һәм әтисеннән дә разый булсын) сүзләреннән килгән хәдистә хәбәр ителгәнчә, Пәйгамбәребез ﷺ ике кабер аша узып барганда: «***Дөреслектә, болар газапка дучар, ә аларның газаплanulары зур гөнаһ өчен түгел***»,[1] — дип әйтте. (Күпмедер вакыт дәшми торганнан соң): «***Әйе*** (әлбәттә, аларны зур гөнаһлар өчен газаплыйлар)***! Аның берсе үз бәвеленнән сакланмаган, ә икенчесе гайбәт таратып йөргән***». Шуннан соң ул ялангач пальма ботагы алып килергә әмер итте һәм аны ике өлешкә бүлеп, аларның каберләре өстенә кадады. «Аллаһның илчесе, нигә болай эшләдең?» — дигән сорауга ул: «***Бәлки, ботаклар корыганчы, бу аларның кабердәге газабын җиңеләйтер***», — диде. Әл-Бохари, 216; Мөслим, 292.

Күп кенә хәдисләрдә хәбәр ителгәнчә, Пәйгамбәребез ﷺ, кабер газабыннан саклавын сорап, Аллаһка дога белән дәшә торган булган һәм башкаларга да шуны әмер иткән.

Кабер газабы ике төрле була:

1) Аллаһ Тәгалә әйткәнчә, кешеләр даими рәвештә дучар булып торган газаплар бар:

**«...Алар иртә-кич утка атылачак»** «Әл-Гафир», 46.

2) Башка газаплар исә күпмедер вакыт дәвам итәчәкләр, ә соңыннан тукталачаклар. Аларга кайбер гөнаһлы мөселманнар дучар була. Газапларының авырлыгы кылган гө-

---

[1] Кабердәге кешеләр үзләре моны зур гөнаһ түгел дип уйлаганнар.

наһларының авырлыгына бәйле. Алар өчен кылынган догалар, бирелгән садакалар яки шуның ише эшләр, газапларының җиңеләюенә китерә торган сәбәпләрдән булырга мөмкин.

Туры юлдан адашканнарның кайберләре кешеләрнең кабердә газаплануларын, ләззәтләнүләрен кире кактылар. Алар үлгән кешеләрдән нәрсә булса да сорауларын яки аларның ләззәтлек, газап кичерүләрен үз акылларына таянганга күрә аңлый алмадылар һәм шикләнүләре дә шул сәбәпле булды.

Бу шикләнүләренә түбәндәгечә җавап биреп була:

1) Моның хакындагы бар гыйлемнең дә чыганагы Коръән һәм Сөннәт булганлыктан, мөселман кешесенә бу хәбәрләрне кабул итү һәм тану тиешле. Гаиб булган нәрсәләргә ышанган, Аллаһ илчесенең ﷺ юлы сәбәпле туры юлдан баручы мөселманнар башкалардан шуның белән аерылып тора.

2) Икенче (кабердәге) булган тормышның үз кагыйдәләре һәм аларны, безнең өчен бу тормыштагы гадәти булган нәрсәләр белән чагыштыру дөрес түгел. Бу — без үлгәннәр белән нинди хәлләр булганлыгын тоя алмыйбыз дигәнне аңлата. Без бары тик Аллаһның кодрәте бөек икәнлеген раслый гына алабыз. Аллаһ шулай теләгән — кешеләргә икенче дөньяда була торган хәлләрне күрү һәм ишетү мөмкинчелеге бирелмәгән, югыйсә, алар моны күтәрә алмас иде һәм шул сәбәпле (кабердә булган хәлләрне күрү, ишетү сәбәпле) бер-берләрен җирләмәс дәрәҗәгә җитәрләр иде.[1]

---

[1] Әлеге сүзләр Мөслим җыентыгында Әнәстән (Аллаһ аннан разый булсын) килгән хәдискә нигезләнә: Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: «***Әгәр дә моннан соң бер-берегезне җирләмәс булган булсагыз, мин Аллаһтан сезнең өчен кабердәге газапларны ишетүне рөхсәт итүен сорар идем***». (Мөслим, 2868).

3) Кеше дигән зат бар нәрсәне дә чолгап ала алмый. Мисал өчен, Җибрил фәрештә (Аллаһның аңа сәламе булсын) Пәйгамбәребез ﷺ янына төшеп аралашканын аның янәшәсендә булган беркем дә күрмәгән һәм ишетмәгән. Шулай ук, җиһандагы бар нәрсәнең дә Аллаһны мактап торганы билгеле, әмма без моның ни рәвешле булганлыгы хакында сүз йөртә алмыйбыз.

4) Аллаһ Тәгалә бу тормышта да безгә моңа охшаш нидер күрергә мөмкинчелек бирә. Кеше, кайчакта, төшендә күңелгә хуш килерлек, куанычлы нәрсә, ә кайчакта моның капма-каршысы булган нәрсәләр күрергә мөмкин, гәрчә ул төшендә күргән вакыйгалардан бик еракта — үзенең урыны өстендә йоклап ята, ә аның төшен исә янәшәсендә булганнар тоя алмый.

Хәзерге уйлап табылган нәрсәләр хакында да әйтеп була. Мисал өчен, электр чыбыгында нинди процесслар барганлыгын шул шәрә чыбыкка кулыбызны тигерми торып тоя алмыйбыз. Аңа тигереп карый торган тимер һәм агач предмет арасында да аерма бар.

# Үлеп терелгәннән соң була торган вакыйгалар

## Кабердән тору

Исрафил (Аллаһның аңа сәламе булсын) сур быргысына өргәч, кешеләр каберләреннән торачаклар. Коръәндә аның быргысына өч тапкыр өргәнлеге әйтелә.

**1.** Сур быргысына беренче тапкыр өргәннән соң, барысын да курку хисе биләп алачак. Беренче өрү дөньяда урнаштырылган тәртипне бозачак. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Ул көнне сур быргысына өрерләр, Аллаһ теләгәннәрдән кала, күкләрдә һәм җирдә булган барысы да куркып тетрәрләр**» «Ән-Нәмел», 87.

**2.** Сур быргысына икенче мәртәбә өргәннән соң җир йөзендәге бар тере нәрсә дә үләчәк. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Сур быргысына өрерләр, Аллаһ теләгәннәрдән кала, күктә дә, җирдә дә булганнар үлерләр**» «Әз-Зүмәр», 68.

**3.** Сур быргысына өченче кат өрелгәннән соң кешеләр терелерләр һәм каберләреннән торырлар. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Соңыннан сур быргысына тагын өрерләр һәм аларның барысы да басып, карап-көтеп торырлар**» «Әз-Зүмәр», 68.

## Җыелу

Кешеләрнең каберләреннән нинди кыяфәттә торулары хакында ике «Сахих» җыентыгында килгән хәдистә Гаишәнең (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән хәбәр ителә: «Мин Аллаһ илчесенең ﷺ: «***Кешеләр (ул көнне) яланаяк, ялангач һәм сөннәткә утыртылмаган килеш җыелырлар***», — дип әйткәнен ишеттем», — диде. Әл-Бохари, 6527; Мөслим, 2859.

Мөслимнең «Сахих»ында әл-Микъдәд бин әл-Әсвәд (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән китерелгән хәдистә: «Мин Аллаһ илчесенең ﷺ: «***Кыямәт көнендә кояш кешеләргә якынайтылыр һәм алардан бер миль ара ераклыгында калыр***. (Әл-Микъдәд сүзләреннән әлеге хәдисне җиткерүче Сүләйм бин Гәмир: «Аллаһ белән ант итәм, мин белмим — бер миль[1] дип ул күз алдында нәрсәне тоткандыр — ара берәмлегенме, әллә инде күзгә сөрмә

---

[1] Гарәпләрдә бу ара ераклыгы 1920 м. тәшкил итә.

сөрткәндә куллана торган таякчыкнымы»[1], — дип әйтте). ***Ә кешеләр үзләренең кылган гамәлләре бәрабәренә үз тирләренә батырлар***», — диде. Мөслим, 2864.

Шушы хәлләрдән соң, Адәм, Нух, Ибраһим, Муса, Гайсә пәйгамбәрләр (Аллаһның аларга сәламе булсын) дә бу эшкә алынмагач, пәйгамбәребез ﷺ шәфәгать кыла башлар. Бу — «Бөек шәфәгать» һәм «Мактаулы урын» булып торачак.

## Аллаһ каршына басу һәм хисап

Барча кешеләр дә Кодрәтле, Бөек Аллаһ каршына килеп басачаклар. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Һәм алар берәм-берәм сафка тезелешеп, Раббың хозурына басачаклар. «Иң башта сезне ничек бар кылган булсак, шул рәвештә Безгә килдегез...**» «Әл-Кәһеф», 48.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Ул көнне сез Аллаһның хозурына китерелерсез һәм сезнең бер серегез дә яшеренеп калмас**» «Әл-Хәкка», 18.

Хисап. Кодрәтле, Бөек Аллаһ кешеләргә аларның изге һәм начар гамәлләре хакында хәбәр итәр һәм оныткан нәрсәләрен исләренә төшерер. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Ул көнне Аллаһ барыгызны да терелтәчәк һәм кылган гамәлләрегез турында хәбәр итәчәк. Аллаһ алар үзләре оныткан гамәлләрен санап барды**» «Әл-Мүҗәдилә», 6.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Алар безгә кайтырлар һәм соңыннан алар өстеннән хисап кылырбыз**» «Әл-Гашия», 25-26.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Аллаһ Үзенең илчеләренә биргән сүзендә тормый дип уйлама. Ул — Куәтле, үч алырга кодрәтле. Җир башка җиргә, күкләр башка күкләргә алмаштырылган көн-**

---

[1] Гарәпләрдә ара берәмлеге дә, күзгә сөрмә сөртә торган таякчык та «миль» сүзе белән аталган.

**дә бәндәләр Бердәнбер, Кодрәтле Аллаһ каршына басырлар. Ул көнне син чылбырга богауланган гөнаһлыларны күрерсең. Алар кигән кием сумаладан, ә йөзләрен ут каплап алган булыр. Аллаһ һәрбер җанга кылган гамәленә карап җәзасын бирер. Хактыр, Аллаһ бик тиз хисап итүче»** «Ибраһим», 47-51.

Гамәл дәфтәрләре ачылачак һәм барысы да — илчеләр дә, алар өммәтендәгеләр дә соралачак. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Без (Кыямәт көнне) расүлләр җибәрелгән кавемнәрдән** («Без җибәргән илчеләрне ничек каршы алдыгыз? Алар сезгә җиткергән хәбәрләрне ничек кабул иттегез?» — дип) **сорау алырбыз һәм расүлләрнең үзләреннән дә** («Без әмер иткәннәрне кавемнәрегезгә ирештердегезме? Кавемнәрегез тарафыннан итәгатьлек күрдегезме?» — дип) **сорарбыз»** «Әл-Әграф», 6.

Әмма кешеләргә сорау бирү һәм алар белән хисаплашу төрлечә булачак. Мөселманнарга килгәндә, аларга гөнаһлары күрсәтеләчәк, алар аны таныячак һәм ул гөнаһлар яшереләчәк.

Ике «Сахих» җыентыгында да Гаишәдән килгән хәдистә (Аллаһ аннан разый булсын) хәбәр ителә: «Көннәрдән беркөнне Аллаһның илчесе: «***Кемне хисап кылачаклар, шул газапка дучар булачак***», — диде. Мин: «Әллә соң Аллаһ Тәгалә: «**Китабы уң кулына бирелгән кешегә хисап тоту җиңел булачак**», «Әл-Иншикак», 7-8 — дип әйтмиме? — дип сорадым. Пәйгамбәребез ﷺ: «***Бу бары тик кешегә аның гамәлләрен күрсәтүне генә аңлата, әмма гамәлләре һәр яктан тирәнтен тикшерелгән кеше харап булачак***», — диде». Әл-Бохари, 103; Мөслим, 2876.

Ике «Сахих» җыентыгында да Ибн Гөмәр (Аллаһ аннан һәм әтисеннән дә разый булсын) сүзләреннән китерелгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Дөреслектә, Аллаһ (Кыямәт көнендә) иман әһеленнән булган кешене Үзенә***

***якынайтыр, аны Үзенең ышыгында каплар, кешеләрдән яшерер һәм сорый башлар: «Шундый гөнаһ кылганыңны таныйсыңмы? Шундый гөнаһ кылганыңны танйсыңмы?» Ә ул: «Әйе, Раббым минем!» — дияр. Аллаһ аның гөнаһларын танырга мәҗбүр иткәч, ул кеше үзен харап булдым дип уйлар, Аллаһ Тәгалә әйтер: «Мин синең гөнаһларыңны дөньядагы тормышыңда яшердем һәм Мин аны бүген дә яшерермен!» Шуннан соң аңа изге гамәлләре язылган китабы тапшырылыр***».

«Ә имансыз һәм икейөзле булган кешегә килгәндә, аларның гамәлләренә шаһит булганнар: «**Менә болар Раббыларына каршы ялган сөйләүчеләр. Залимнәр өстеннән Аллаһның ләгънәте булсын!**» «Һуд», 18 — дип әйтерләр» Әл-Бохари, 2441; Мөслим, 2768.

Мөселманнар арасында Җәннәткә хисапсыз һәм газапсыз керүчеләр дә булачак, мәсәлән, ике «Сахих» җыентыгында Ибн Гәббәснең (Аллаһ аннан һәм әтисеннән дә разый булсын) сүзләреннән китерелгән хәдистә җитмеш мең кеше хакында хәбәр ителә. Әл-Бохари, 5705; Мөслим, 220.

Ә имансыз бәндәләргә килгәндә, алар белән хисап изге һәм начар гамәлләре үлчәнелгән кешеләрнеке кебек булмаячак, чөнки аларның изге гамәлләре бөтенләй булмаячак. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Аларның кылган гамәлләренә керешербез һәм аларны очкан тузан кебек юк итәрбез**» «Әл-Фуркан», 23.

Имансызлар белән хисап кылу аларның начар гамәлләрен үзләренә күрсәткәннән соң газапка дучар булуларыннан гыйбарәт.

## Үлчәү

Монда сүз Кыямәт көнендә Аллаһ колларын бер-берсеннән аеру, гамәлләрен, шул гамәлләренең микъдарын үлчәр өчен куелган үлчәү хакында бара. Үлчәү хисап кылынганнан соң

булачак, чөнки хисап нәрсә эшләнгән икәнлеген белү өчен, ә үлчәү — кылган гамәлләренең бәясен алачак кешегә шул кылган гамәлләренең ни торганын күрер өчен кирәк.

Коръәндә дә, Сөннәттә дә әлеге үлчәүләрнең никадәр төгәл булачагына күрсәтә торган бихисап дәлилләр бар. Мисал өчен, Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Кыямәт көнендә Без гадел үлчәүләр куербыз. Ул көнне инде һичбер кемгә нинди дә булса гаделсезлек кылынмас. Әгәр гәрчич орлыгы хәтле генә** (гамәл) **табылса да, Без аны үлчәүгә куярбыз. Үзебезнең хисап кылуыбыз җиткән!**» «Әл-Әнбия», 47.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«(Кыямәт көнендә) **үлчәүләре авыр булган кешегә килгәндә, ул рәхәт** (җәннәт) **тормышта яшәр. Ә үлчәүләре җиңел булган бәндәнең исә урыны җәһәннәм упкыны булыр**» «Әл-Каригә», 6-9.

Әл-Бохариның «Сахих»ында Әбү Һурәйраның (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән китерелгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Рәхимле булган Аллаһ яраткан ике сүз бар, алар тел өчен җиңел, ә Үлчәүдә бик авыр булырлар. Бу сүзләр: «Аллаһ һәр кимчелектән дә пакь һәм Аңа барча мактау, Бөек Аллаһ һәр кимчелектән пакь!»***»[1].

## Гамәлләр язылган битләр

Хисап кылу һәм үлчәү тәмам булганнан соң, адәм баласы кулына гамәлләре язылган язманы алыр һәм анда язылганны укыр. Кешеләр арасында ул язмаларны уң куллары һәм аркалары артыннан сул куллары белән алучылар булыр. Аллаһ Тәгалә әйтте:

---

[1] Әл-Бохари, 6406, 6682, 7563. («*СүбхәәнАллаһи үә бихәмдиһи үә сүбхәәнАллаһи-ль Газыйм*»).

**«Китабы уң кулына бирелгән кеше әйтер: «Менә! Укыгыз минем китабымны! Мин хисап тотачагымны белеп яшәдем». Аңа — җимешләре үрелеп алырдай якында булган югары җәннәттә бәхетле тормыш булыр. Дөньяда яшәгәндә кылган игелекләрегезгә күрә, рәхәтләнеп ашагыз-эчегез! Китабы сул кулына бирелгән кеше: «Китабымны миңа бирмәгән булсалар — хисабым хакында белмәгән булыр идем! Дөньядагы үлемем соңгысы** (яңадан терелмәгән) **булган булса иде! Байлыгым миңа бер файда да бирмәде!** (Бөтен) **патшалыгым кулдан китте!» — дип әйтер»** «Әл-Хәкка», 19-29.

## Сират күпере

Җәһәннәм өстеннән үтә торган күпер шулай дип атала. Әлеге күпердән барчасы да үтәчәк. Аны узган кеше уттан котылыр. Кешеләр әлеге күпердән бары тик хисап урыныннан киткәч кенә уза алачаклар. Иман китергән кешеләр аннан үтә алырлар һәм Җәһәннәмнән котылырлар, ә Җәһәннәмгә эләгергә тиеш булган кешеләр ул күпердән егылып төшәрләр. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Сезнең арагызда анда** (Җәһәннәмгә) **якын килергә тиешле булмаган һичбер кеше юк.**[1] **Бу — Раббыңның котылгысыз булган карары. Соңыннан без тәкъва булганнарны коткарырбыз, ә залимнәрне тезләнгән килеш шунда калдырырбыз»** «Мәрьям», 71-72.

Ике «Сахих» җыентыгында да Әбу Һурәйраның (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән китерелгән хәдистә болай дип хәбәр ителә: «Көннәрнең берендә кешеләр: «И, Аллаһның илчесе! Кыямәт көнендә без Раббыбызны күрәчәк-

[1] Искәрмә: Җәһәннәмгә якын килү дип, Сират күпереннән узу күз алдында тотыла.

безме?» — дип сорадылар. Әлеге хәдистә Пәйгамбәребезнең ﷺ мондый сүзләре китерелә: «*...Җәһәннәм өстеннән Күпер куелыр, ул Күпердән беренчеләрдән булып мин һәм минем өммәтемнән булганнар узырбыз. Ул көндә Аллаһ илчеләреннән кала һичберкем бер сүз дә әйтмәс, ә алар: «И, Аллаһ! Коткар! Коткар!» — дип дәшерләр. Җәһәннәмдә «сәгъдән»* (дөя чәнечкесе) *энәләренә охшаш ыргаклар булыр*»». Әл-Бохари, 806; Мөслим, 182.

Әл-Бохари һәм Мөслимнең «Сахих» җыентыкларында Әбу Сәгийд әл-Худридан (Аллаһ аннан разый булсын) Аллаһка карау һәм шәфәгать кылу хакында китерелгән озын хәдистә, Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «*...Соңыннан Күперне алып килерләр һәм аны Җәһәннәмнең ике сырты арасына урнаштырырлар*». Аннан: «И, Аллаһның илчесе! Бу нинди Күпер соң?» — дип сорадылар. Ул: «*Бу — тайгак юл булыр, ул юлда Нәҗдә җирлегендә очрый торган «сәгъдән» дип аталган* (дөя чәнечкесе)*, ыргаклары, зур энәләре, чәнечкеләре бөгелеп торган үсемлеккә охшаш үсемлек булыр*», — дип җавап бирде. «*Иман әһеленнән булган кешеләр Күпер өстенән күз ачып йомган арада узырлар, кайберләре яшен тизлегендә, башка берләре җил шикелле, кайберләре исә нәселле юртаклар яки җайдаклар тизлегендә үтәрләр. Кемнәргәдер исән-сау котылырга насыйп булачак, бүтәннәр тырналып бетеп булса да котыла алырлар, өченчеләрен исә Җәһәннәмгә тартып төшерерләр*». Әл-Бохари, 7439; Мөслим, 183.

## Күпер

Иман әһелләре Сират күпереннән узып Уттан котылганнан соң, Җәннәткә керер алдыннан, Җәннәт белән Җәһәннәм арасына урнаштырылган икенче бер күпердә туктатылачаклар. Бу — дөнья тормышында кыерсытылганнарның,

үзләрен рәнҗеткән кешеләр белән исәп-хисап кылу өчен булачак. Бер-берләренең хакларын түләп бетергәннән соң аларга Җәннәткә керергә рөхсәт ителер.

Әбу Сәгид әл-Худри (Аллаһ аннан разый булсын) Аллаһ илчесенең ﷺ сүзләрен китерә: «***Иман китергәннәр Җәһәннәм утыннан котылачаклар һәм Җәннәт белән Җәһәннәм арасында булган күпердә туктатылачаклар. Әлеге урында бу дөнья тормышында кыерсытылып яшәгән кешеләр, рәнҗетүчеләреннән җәфа кичергәннәре өчен үз хакларын ала алачаклар. Исәп-хисап кылынып чистарынганнан соң, аларга Җәннәткә керергә рөхсәт ителер. Мөхәммәднең җаны Аның Кулында булган зат белән ант итәм, сезнең һәрберегез бу дөньяда үзенең йортын ничек җиңел тапкан булса, Җәннәттәге үз урынын аннан да җиңелрәк табачак***». Әл-Бохари, 6535.

Әлеге күпер хакында гыйлем әһелләре арасында берникадәр фикер каршылыгы бар. Бер төркем галимнәр бу күперне Сират күперенең тәмамланган урыны, ягъни, Җәннәткә тоташкан урыны дигән булсалар, икенче төркем галимнәр исә аны аерым бер күпер диделәр.

## Сулык

Сүз пәйгамбәребезнең ﷺ сулыгы хакында бара. Әл-Бохари һәм Мөслим «Сахих» җыентыкларында Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гәс (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән китерелгән хәдистә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Минем сулыгым бер ай буе барырлык ара ераклыгына җәелгән һәм аның почмаклары тигез. Аның суы сөттән дә аграк, ә исе — мускусның хуш исеннән дә тәмлерәк. Ярларында булган кувшиннарның саны күктәге йолдызлар саны кебек һәм кем аның суын татып карый, шул кеше бүтән беркайчан да сусау хисен кичермәс***». Әл-Бохари, 6579; Мөслим, 2292.

Әлеге сулык хакында ике «Сахих» җыентыкларыннан кала башка хәдисләр җыентыкларында да бик күп хәдисләр искә алына.

## Җәннәт һәм Җәһәннәм

Җәннәт белән Җәһәннәм — Аллаһ Тәгалә тарафыннан, кылган гамәлләре бәрабәренә, коллары өчен әзерләп куйган ике яшәү урыны булып тора.

Җәннәт — Аллаһка якынайган, Аңа, Аның илчеләренә, алар алып килгән хәбәргә иман китергән, Аллаһка һәм Аның илчеләренә буйсынган, ихластан бары тик Аллаһка гына гыйбадәт кылган, Аның илчеләренә ияргән тәкъва мөэминнәр өчен әзерләнгән югары рәхәтлек урыны һәм аларга карата күрсәтелгән юмартлык булып тора. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Дөреслектә, иман китереп изге гамәлләр кылганнар — Аллаһ яралтканнарның иң яхшылары. Раббылары янында елгалары агып торган җәннәт бакчалары аларга булыр. Алар анда мәңгегә калачак. Аллаһ алардан разый һәм алар да Аннан разый. Менә боларның барысы да Аллаһның җәзасыннан курыккан мөэминнәр өчен әзерләнгән әҗер**» «Әл-Бәййинә», 7-8.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Сез Раббыгызның ярлыкавына һәм күкләр белән җир киңлегендә булган Җәннәткә ашыгыгыз! Ул тәкъва бәндәләр өчен әзерләнде**» «Әли Гыймран», 133.

Җәннәттә изге гамәлләр кылучыларны бу дөньяда беркем дә күрмәгән, ишетмәгән һәм фикерләп тә карамаган бик күп ләззәтләр көтеп тора. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Кылган гамәлләренә күрә бүләк буларак, нинди шатлык, күпме әҗер алачакларын бер кеше дә белми**» «Әс-Сәҗдә», 17.

Аллаһ Тәгалә әйткәнчә, Җәннәткә кергәннәр өчен иң бөек ләззәт булып Раббыларын күрә алу мөмкинчелеге булачак:

**«Ул көнне кайберәүләрнең йөзләре балкып, Раббыларына багып торыр»** «Әл-Кыямәһ», 22-23.

Шул ук хәбәрләр күп кенә хәдисләрдә дә китерелә.

Җәһәннәмгә килгәндә, ул — кәферләрдән булган Аллаһ дошманнарына, Аңа иман китермәгәннәр һәм Аның илчеләренә буйсынмаганнар өчен әзерләнгән газап һәм хурлык урыны булып тора. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Сез кәферләр өчен әзерләнгән Уттан сакланыгыз!»** «Әли Гыймран», 131.

Җәһәннәмдә гөнаһлы бәндәләрне бик күп төрле газапларга дучар итәчәкләр. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Без залимнәр өчен ялкынлы диварлары, төрле яктан чолгап алган Ут әзерләдек. Әгәр алар (сусап) ярдәм сорый калсалар, чырайларны көйдерерлек эретелгән сыек тимер кебек эчемлек бирерләр. Начар эчемлек һәм яман яшәү урыны!»** «Әл-Кәһеф», 29.

Җәннәт белән Җәһәннәмнең тасвирламасы бик күп Коръән аятьләрендә һәм хәдисләрдә китерелә. Анда аларның халык кылынганлыгы һәм бүгенге көндә дә бар икәнлеге, шулай ук, Җәннәттә яки Җәһәннәмдә көтәчәк ләззәтлелек һәм каты газап хакында әйтелә.

Җәннәт тә, Җәһәннәм дә мәңгелек булачаклар һәм беркайчан да юкка чыкмаячаклар.

Аллаһ Тәгалә Җәннәт хакында менә нәрсә хәбәр итте:

**«...Ризыклар корымый, күләгә юкка чыкмый»** «Әр-Рагд», 35.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Дөреслектә, бу — Без биргән ризыклар, алар беркайчан да бетмәс-төкәнмәс булыр»** «Әс-Сад», 54.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«...Һәм алар анда мәңгегә калырлар»** «Әл-Бәййинә», 8.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Алар анда үлем әчесен бер татыганнан соң, икенче кат татымаслар»** «Әд-Духан», 56.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«...Аларны аннан** (Җәннәттән) **беркайчан да чыгармаячаклар»** «Әл-Хиҗр», 48.

Җәһәннәмгә килгәндә исә, аның хакында Аллаһ Тәгалә болай диде:

**«Алар Уттан чыгарга бик теләрләр, тик алар аннан чыга гына алмаслар. Аларга даими газап булыр»** «Әл-Мәидә», 37.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«Алар анда үтерелмәсләр дә, газаплары да җиңеләйтелмәс»** «Әл-Фәтыр», 36.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

**«...Алар анда мәңгегә калачак»** «Ән-Нисә», 169.

## Шәфәгать

Безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ беренчеләрдән булып Җәннәт ишекләрен ачуны сораячак, ә аның өммәте әһелләре анда беренчеләрдән булып керәчәк.

Бары тик безнең пәйгамбәребез генә иман китергәннәрне Җәннәткә кертүне сорап Аллаһка үтенәчәк. Үзләре белән ни булачагын белмичә, Аллаһның әмерен көтеп торганда булачак бөек шәфәгать тә, абыйсы Әбу Талибның газапларын җиңеләйтүне сораган үтенеч тә, бары тик, безнең Пәйгамбәребезгә ﷺ генә биреләчәк.

Шәфәгатьнең башка төрләренә килгәндә, аның белән Аллаһка башка пәйгамбәрләр дә, фәрештәләр һәм иман әһелләре дәшәчәк. Ул төр шәфәгатьләрдән түбәндәгеләрне атарга мөмкин:

1) Гөнаһ кылган тәүхид әһелләренең Җәһәннәмдә янырга лаеклы булуларына да карамастан, анда кертмәүләрен сорап кылынган үтенеч.

2) Җәһәннәмгә кергән шундый гөнаһлы бәндәләрне аннан чыгаруны сорап кылынган үтенеч.

3) Җәннәткә кергән кайберәүләрнең дәрәҗәсен күтәрүне сорап кылынган үтенеч.

Әлеге һәм башка төр шәфәгатьнең уңышлы булуы ике шартка бәйле булып тора:

1) Аллаһның рөхсәте, чөнки Аллаһ Тәгалә болай дип әйтте:

«**Кем** (Кыямәт көнендә) **Аның каршысында** (торганда)**, Аның рөхсәтеннән башка** (берәрсе өчен) **шәфәгать кыла алыр икән?**» «Әл-Бәкара», 255.

2) Шәфәгать кылынасы кешедән Аллаһның разый булуы. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Алар бары тик Аллаһ разый булганнар өчен генә шәфәгать кыла алалар...**» «Әл-Әнбия», 28.

Ахирәт тормышында була торган бар нәрсәне дә — кешенең үлеме белән Кыямәт көне арасында, Кыямәт көнендә, Җәннәттә, Җәһәннәмдә — без боларның барысын да, бу хәлләрнең ничек барачагының барлык нечкәлекләрен белеп бетермәсәк тә, бары тик Коръәннән һәм Сөннәттән генә беләбез, шуңа ышанабыз.

# Тәкъдирнең яхшысына да, начарына да иман китерү

Тәкъдир (*кадар*) дип, Аллаһ тарафыннан барча мәхлукатларына да билгеләнеп куелган нәрсә хакында әйтәләр. Коръәндә дә, Сөннәттә дә тәкъдирнең барлыгына һәм аңа һичшиксез ышану кирәклегенә бик күп күрсәтмәләр килә. Мисал өчен, Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Дөреслектә, Без һәрнәрсәне үз тәкъдире белән яралттык**» «Әл-Камәр», 49.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Аллаһның әмере — язып куелган тәкъдирдер**» «Әл-Әхзәб», 38.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Бар бәхетсезлек** (кайгы-хәсрәт) **бары тик Аллаһның теләге белән генә килә. Аллаһка инанган кешенең күңелен Аллаһ туры юлга юнәлтер**» «Әт-Тәгабун», 11.

Мөслимнең «Сахих» җыентыгында шундый хәбәр китерелә: көннәрнең берендә, Габдуллаһ бин Гөмәр бин әл-Хаттабка (Аллаһ аннан һәм әтисеннән разый булсын) гыйлемгә омтылу йөзеннән Коръән укучы бер төркем кешеләр, шулай ук, аларның вакыйгаларның тәкъдир кылынганлыгын танымаулары хакында хәбәр иттеләр. Ул, әлеге хәбәрне җиткергән кешегә: «Аларны күрә калсаң, минем алар белән, ә аларның минем белән бернинди уртаклык та юк дип әйт! Габдуллаһ бин Гөмәр ант итә, диген, әгәр дә аларның берәрсе изге гамәлләр юлында Ухуд тавы авырлыгы кадәр алтын сарыф итсә дә, тәкъдиргә ышанмыйча торып, Аллаһ аның бу гамәленнән бер нәрсәне дә кабул итмәячәк!» — дип әйтте. Мөслим, 8.

Мөслимнең «Сахих» җыентыгында килгән бер хәдистә, Таус бин Кәйсән болай дип әйткән: «Аллаһ илчесенең ﷺ сәхабәләреннән булган кешеләрне исән чакларында күреп калдым. Аларның барысы да: «Бар нәрсә дә тәкъдир кылынган», — дип әйтәләр иде».

Таус, шулай ук, Габдуллаһ бин Гөмәрнең (Аллаһ аннан һәм әтисеннән разый булсын): «Аллаһның илчесе ﷺ: «***Бар нәрсә дә тәкъдир кылынган, хәтта активлык та, сәләтсезлек тә***», — дип әйтте», — дигән сүзләрен ишетүен хәбәр иткән. Мөслим, 2655.

Мөслимнең «Сахих» җыентыгында Әбу Һурәйра (Аллаһ аннан разый булсын) Аллаһ илчесенең ﷺ: «***Һәрберсендә дә хәерлелек булуга карамастан, көчле мөселман зәгыйфь мөселманга караганда яхшырак һәм Аллаһ каршында күпкә сөйгәнрәк. Сиңа файда китерә торган нәрсәгә омтыл, Аллаһтан ярдәм сора һәм кулларыңны төшермә. Әгәр дә синең белән ни дә булса була калса: «Әгәр дә мин шулай эшләгән булсам!» — димә, ә: «Бу Аллаһ тарафыннан тәкъдир кылынган һәм Ул теләгән нәрсәсен бар кыл-***

***ды», — диген. Чөнки «Әгәр» дигән сүз шәйтан эшләренә юл ача»*** Мөслим, 2664, — дип әйткән сүзләрен китерә.

# Тәкъдиргә ышану түбәндәгедән гыйбарәт

**Беренчесе:** Аллаһның гыйлеме бар нәрсәне дә чолгап алганлыгына ышану. Аллаһ Тәгалә барча кешеләр хакында да аларны бар кылганчы ук аларның барча булган гамәлләре, ризыклары, һәрберсенең гомере, изге гамәлләре, гөнаһлары һәм башкалар хакында алдан ук белгән.

**Икенчесе:** Аллаһ боларның барысын да («Ләүхел Мәхфүз»дә) язып куйган.

Тәкъдиргә ышануны үз эченә алган әлеге ике өлешкә дәлил булып Аллаһның әлеге сүзләрен китереп була:

«**Аллаһка күктә һәм җирдә булган нәрсәләр билгеле икәнен белмисеңме әллә? Дөреслектә, бу — Китапта** (Ләүхел Мәхфүз) **язып куелган. Хактыр ки, бу Аллаһ өчен җиңел**» «Әл-Хәҗ», 70.

Мөслимнең «Сахих» җыентыгында Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гәс (Аллаһ аннан һәм әтисеннән разый булсын) сүзләреннән килгән хәдистә: «Мин Аллаһ илчесенең ﷺ: «***Аллаһ барлык мәхлукатларының язмышын күкләр һәм җир бар кылынганчы илле мең ел алдан язып куйды, ә ул вакытта Аның Тәхете су өстендә иде***», — дип хәбәр ителә. Мөслим, 2653.

Аллаһның гыйлеме белән бәйле булган бу тәкъдир гомуми һәм хас булган бар нәрсәгә дә кагыла. Беренчесенә килгәндә (гомуми), бу — Ләүхел Мәхфүздә барча халык кылынган нәрсәләрнең дә язып куелган гомуми тәкъдире.

Икенчесенә килгәндә, монысы аерым булган тәкъдиргә кагыла һәм ул өч вакыт аралыгы белән бәйле:

• **Бар гомернең дә тәкъдир кылынуы.**

Ике «Сахих» җыентыгында да Габдуллаһ бин Мәсгуд (Аллаһ аннан разый булсын) сүзләреннән китерелгән хәдистә, Аллаһның илчесе ﷺ: «***Дөреслектә, сезнең һәрберегез дә анагызның карынында кырык көн буена тамчы орлык кыяфәтендә формалаша. Соңыннан ул анда шуның кадәр үк кан төере кебек һәм шуның кадәр үк тән кисәге кыяфәтендә була. Соңыннан аңа фәрештә җибәрелә һәм җан өрелә. Ул фәрештә дүрт нәрсәне язып куерга әмер ала: аның (кешенең) ризыгын, әҗәлен, гамәлләрен һәм бәхетле яисә бәхетсез булачагын***», — дип әйтте. Әл-Бохари 3208, Мөслим, 2643.

• **Алдагы бер ел эчендә булачак нәрсәләрнең тәкъдир кылынуы.**

Кадер кичендә алдагы бер ел эчендә булачак бар нәрсәләр дә язылып куела. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Ул кичтә һәр хикмәтле эш хәл ителер**» «Әд-Духән», 4.

• **Кешенең гомере-үлеме, күтәрелүе-түбәнсетелүе һәм башка нәрсәләр белән бәйле булган, тәүлек эчендә булачак вакыйгаларның тәкъдир кылынуы.**

Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**...Аллаһ һәркөн гамәлләр белән мәшгуль**» «Әр-Рахмән», 29.

**Өченчесе:** Аллаһның теләге һәрвакытта да үтәлә икәнлегенә ышану. Әлеге ышану үз эченә түбәндәгеләрне дә ала:

– Аның кодрәтенә бернинди чик тә юк;

– Бары тик Аллаһ теләгән нәрсә генә була, ә Ул теләмәгән бер нәрсә дә булмаячак;

– Күкләрдәге, җирдәге барча нәрсәләр дә бары тик Аның теләге белән генә чынга аша;

– Аллаһ хакимлегендәге бер нәрсә дә Аның теләгенә каршы бара алмый һәм Ул бар нәрсәне дә булдыра ала. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Раббың теләгәнен эшли, ни теләсә, шуны сайлап ала...**» «Әл-Касас» 68.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Дөреслектә, Раббың Үз ихтыярынча хөкем итүче**» «Һуд», 107.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

«**Дөреслектә, Аллаһның кодрәте чиксез. Аның кодрәте бар нәрсәгә җитә**» «Әл-Бәкара», 20.

Аллаһның теләге (тәкъдире) ике төрле була:

1) Яшәешкә һәм тәкъдиргә кагылышы булган, әмма мәхәббәт һәм шәфкатьлелек белән бәйле булмаган теләк (*әл-кадәр әл-кәүни*). Моның хакында Аллаһ Тәгалә болай дип әйтте:

«**Әгәр Аллаһ кемне дә булса һидәяткә күндереп, туры, хак юлга юнәлтергә теләсә, Ул аның күкрәген** (күңелен, йөрәген) **Ислам дине өчен ача, киңәйтә. Ә инде кемне дә булса хак диненнән адаштырырга теләсә, Ул аның күкрәген, күккә менгәндәге** (һава җитмәү сәбәпле сулыш авырайгандагы) **кебек тарайта һәм кыса**» «Әл-Әнгам», 125.

2) Дингә һәм шәригать хөкемнәренә кагылышы булган теләк (*әл-кадәр әш-шәрги*). Мондый теләк мәхәббәт һәм шәфкатьлелек элементларын үз эченә ала. Моңа дәлил буларак Аллаһның әлеге сүзләрен китереп була:

«**Аллаһ сезгә җиңеллек тели, кыенлык теләми...**» «Әл-Бәкара», 185.

Моны ничек аңларга? Әгәр дә Аллаһка буйсыну белән бәйле булган берәр нәрсә була икән, димәк, Аллаһ моны югарыда телгә алып киткән теләкнең беренче төр мисалында теләгән, икенче төрле итеп әйткәндә, Аллаһ моны

тәкъдир кылган һәм моның булуын теләгән. Шулай ук, Аллаһ моны, югарыда карап киткән теләкнең икенче төр мисалында да теләгән, ягъни, Ул моны ярата һәм аның белән канәгать.

Әгәр дә инде Аллаһка каршы килү белән бәйле булган ни дә булса була икән, димәк, Аллаһ моның шулай булуын беренче төр мисалында теләгән, ә теләкнең икенче төр мисалына килгәндә исә, Аллаһ шулай ук моны теләгән, тик Ул әлеге гамәлләрне яратмый һәм аннан канәгать түгел.[1]

**Дүртенчесе:** Аллаһ Тәгалә Халык кылучы, ә калган бар нәрсә дә Аның тарафыннан бар кылынган икәнлегенә ышану. Шулай ук, Аллаһ халык кылган затларның ни дә булса эшләүләре һәм берни эшләмәүләре дә бары тик Аның тарафыннан гына, һәм боларны халык кылучы башка беркем дә, бер Раббы да юк икәнлегенә ышану.

Аллаһ Тәгалә Ибраһим пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе булсын) үз халкына әйткән сүзләрен китерә:

«**Аллаһ барча нәрсәне юктан бар итүче, Ул барча нәрсәнең дә вәкиле**» «Әз-Зүмәр», 62.

Аллаһ коллары билгеле бер мөмкинлеккә, теләккә ия булган кебек, гамәлләр кылырга да кодрәтлеләр. Әмма аларның үзләрен, кодрәтләрен, теләкләрен Халык кылучы булып Аллаһ тора. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Аллаһ сезнең үзегезне һәм сез ясаган нәрсәләрне барлыкка китерүче**» «Әс-Саффәт», 96.

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте:

---

[1] Искәрмә: Әлеге тема Ислам нигезләре белән әле генә таныша башлаган кешеләргә аңлау өчен берникадәр авыр булырга мөмкин. Китапның асылыннан читкә тайпылмаска тырыштык, шуңа күрә дә тәфсилләп, бәйнә-бәйнә аңлатып китүне үз өстебезгә алмадык. Шулай да, китабыбызның ахырында «Искәрмә» темасы астында яшәеш һәм шәригать белән бәйле булган тәкдирънең аермасын аңлатып китергә тырыштык.

**«Туры юлдан барырга теләгәннәрегез өчен... Ләкин, шунысы да хактыр, галәмнәрнең Раббысы теләмәсә, сез теләгегезгә ирешә алмассыз»** «Әт-Тәкъвир», 28-29.

Шулай итеп, Аллаһ Тәгалә кешеләрнең теләкләре барлыгын әйтеп китте, ләкин алар ул теләкләрен бары тик Аллаһның теләге белән генә тормышка ашыра алалар.

Аллаһ коллары гамәлләр кылу кодрәтенә ия һәм аларның үз теләкләре (сайлау мөмкинчелеге) бар, аларга илчеләр җибәрелгән, Китаплар иңдерелгән, болар исә Аллаһның Үзенең колларына дәлилләрен күрсәткәнлеген, җиткергәнлеген аңлата. Димәк, Аллаһтан күрсәтмәләр килгән икән, алар кылган гамәлләре өчен я әҗер алачаклар, я газапка дучар ителәчәкләр. Шунлыктан, Аллаһ колы Аның тәкъдиренә ышанырга, Аның кануннарына, хөкемнәренә буйсынырга һәм Аллаһтан үзен туры юлдан алып баруын сорарга тиеш. Моннан кала, аңа Аллаһка тәвәкәлләп, теләгенә ирешү юлында Аннан ярдәм, җиңеллелек һәм үзеннән шәригать тарафыннан хупланылмаган нәрсәләрне юк итүне сорап, файда китерә торган барча нәрсәгә дә омтылырга, дөньяви һәм дини эшләренә зарар китерердәй булган барча нәрсәне дә инкарь итәргә кирәк. Әгәр дә сайлап алган сәбәпләре аңа файда китерә калса, ул Аллаһка шөкер итергә һәм Аны мактарга тиешле; әгәр дә бу аңа файда китермәсә, ул тынычлык сакларга тиешле, чөнки ул булдыра алганын эшләде. Шулай ук сабыр булырга, Аллаһның әҗеренә өмет итәргә һәм Аннан моңа алмашка тагын да яхшырагын насыйп итүен сорарга кирәк. Аллаһ Тәгалә әйтте:

**«Аллаһ беркемгә дә көче җитмәслек эш йөкләми (булдыра алмаслыкны әмер итми). Һәр кешенең изгелекләр эшләп алган әҗере үзе өчен була. Начарлыклар эшләп җыйган гөнаһларның зарары да — бары тик үзенә»** «Әл-Бәкара», 286.

Аллаһның илчесе ﷺ бер хәдисендә: «***(Сезгә нәрсә әмер ителгән — шуны) эшләгез, ни өчен халык кылынган булгансыз*[1]*, (һәрберегез өчен дә) шуның гамәлләрен кылу җиңеләйтелер***», — дип әйтте. Әл-Бохари, 4949; Мөслим, 2647.

Шулай ук Пәйгамбәребездән ﷺ килгән бер хәдистә болай дип хәбәр ителә: «***Гаҗәп тә соң мөселман кешенең хәле! Дөреслектә, бар нәрсә дә аның өчен хәерле һәм бу бары тик иман китергән кешегә генә кагыла. Әгәр дә аның белән берәр төрле куанычлы хәл була калса, ул Аллаһка шөкер итә һәм бу аның өчен хәерле. Әгәр аңа кайгы килсә, ул сабыр итә һәм бу да аның өчен хәерле була***». Мөслим, 2999.

Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка мактаулар булсын, шулай ук Аның илчесе Мөхәммәдкә ﷺ, аның гаилә әһелләренә, сахәбәләренә һәм аларның юлыннан барган барча мөселманнарга да Аллаһның салаватлары, сәламнәре ирешеп торсын! Әмин!

---

[1] Җәннәт яки Җәһәннәм.

# Искәрмә

Аллаһның ике төр тәкъдире, аларның аермасы хакында бераз аңлатып китү бик урынлы булыр. Югарыда телгә алганча, тәкъдир (Аллаһның теләге) ике төрле була:

1) Яшәеш белән бәйле булган тәкъдир (*әл-кадәр әл-кәүни*);

2) Шәригать белән бәйле булган тәкъдир (*әл-кадәр әш-шәрги*).

Аллаһ кайчакта Үзенең яшәешендә, ә кайчакта Үзенең шәригатендә нидер тели. Боларның аермасы нидә соң? Коръән аятьләрен, хәдисләрне дөрес аңлар өчен боларның аермасын белү бик мөһим.

Бу аерманы өчкә бүлеп карап була:

**Беренче аерма**

Аллаһның яшәештәге теләге бары тик яшәешкә генә кагыла, ягъни, Аның мәхлукатлары, аларның яшәешләре белән генә бәйле.

Ә Аллаһның шәригатьтәге теләге бары тик шәригать мәсьәләләренә генә кагыла: ул да булса, Аллаһның акыл ияләреннән булган җеннәр, кешеләргә карата булган әмерләре, тыюлары.

**Икенче аерма**

Аллаһның яшәештәге теләгендә Аның өчен сөекле булган әйберләр дә (мөселманнар, намаз, садака һ.б.), шул ук вакытта, Ул яратмаган нәрсәләр дә булырга мөмкин (Иблиснең барлыгы, көферлек, бидгатьләр, гаделсезлек, үтерүләр һ.б.). Кемдер: «Ә ни өчен Аллаһның мәхлукатларында Ул Үзе яратмаган, разый булмаган нәрсәләр булырга мөмкин? Югыйсә, алар бит Аллаһ барлыкка китергән нәрсәләр? Әгәр ни дә булса Аллаһка сөекле түгел икән, нигә соң ул нәрсә бар?» — дип сорау бирергә мөмкин. Моның ише сорауга без, беренчедән, Аллаһның сүзләре белән җавап бирербез:

«**Аллаһ Үз гамәлләре өчен** (беркем каршысында да) **җавап тотмас, ә алар —** (кешеләр, үзләренең кылган эшләре өчен) **җавап бирәчәкләр**» «Әл-Әнбия», 23.

Икенчедән, без моны алтын кагыйдә итеп истә калдырырга тиеш: Аллаһ нәрсә генә кылмасын, сөекләме ул Аңа, юкмы, кеше дигән зат өчен бу ничек кенә күренмәсен — бу гамәлләрнең барысында да бөек хикмәт бар!

Аңларга җиңел булсын өчен берничә мисал китереп китик: Еш кына үзебезнең тормышыбызда да шундый хәлләрнең, мисалларның булганы бар. Мәсәлән, кешеләрдән берәү, бер карашка, безгә аңлашылмаган нинди дә булса гамәл кыла һәм без шуның өчен аны гаеплибез, ризасызлыгыбызны белдерәбез. Ә соңрак, менә шушы гамәлләренең нәтиҗәсе яхшы, файдалы булганына шаһид булгач, бу кешенең хикмәтле адым ясаганына гаҗәпләнәбез, таң калабыз. Әлеге мисаллардан Аллаһ Тәгалә өстен, әлбәттә.

Хәзер, әйдәгез, Пәйгамбәребезнең ﷺ тормышында булган вакыйганы мисал итеп китерик.

Һәммәбез дә «Һөдәйбия килешүе» тарихын белә. Аның хакында тулырак итеп Әл-Бохариның «Сахих» җыентыгындагы 2731, 2732 номерлы хәдисләрдән таныша аласыз. Әйтергә теләгән фикеребезне аңларга җиңел булсын өчен, кыскача гына ни булганлыгын бәян кылып китәрбез.

Һиҗри ел белән алтынчы елда Пәйгамбәребез ﷺ һәм сәхабәләре, гөмрә кылу нияте белән Мәккә шәһәренә юнәләләр. Мәккә мөшрикләре әлеге хәбәрне ишеткәч, союздаш кабиләләре белән, аларга гөмрә кылырга комачаулау максатыннан, Мәккә чигенә чыктылар.

Әмма Пәйгамбәребез ﷺ Мәккәгә икенче юл белән китеп, Һөдәйбия[1] дип аталган урында тукталды. Мөселманнар да, мөшрикләр дә бер-берсенә илчеләр җибәрделәр һәм мөселманнар янына тынычлык килешүе төзергә дип Сүһәйл ибн Гәмр килде.

Әлеге тынычлык килешүе берничә өлештән тора иде, күбесе мөселманнар өчен бер дә файдага булмады. Шул сәбәпле сәхабәләрнең кәефе төште, хәтта, бөек сәхабәләрнең берсе — Гөмәр ибн әл-Хаттаб та (Аллаһ аннан разый булсын) моның белән килешә алмады. Пәйгамбәребез ﷺ янына да, Әбу Бәкер (Аллаһ аннан разый булсын) янына да килеп үзенең үпкәсен белдерде: нигә шундый түбәнсенүгә барабыз, без бит хак юлда, ә алар адашуда! Пәйгамбәребезнең дә ﷺ, Әбу Бәкернең дә (Аллаһ аннан разый булсын) җавабы бер сүзгә кайтып калды: мин Аллаһның илчесе һәм Ул теләгәнне үтим.

Югарыда телгә алганча, сахәбәләр бик каты үпкәләделәр, чөнки мөшрикләр бары тик үзләренә генә кулай булган шартларны куйдылар, ә Пәйгамбәребез ﷺ моның белән ризалашты! Сез бу хәлне күз алдыгызга китереп карагыз әле! Әмма... Әмма, ахыр чиктә, нәкъ менә шушы килешүне Аллаһ Тәгалә мөселманнар өчен бик зур җиңүгә сәбәп кылды. Шуңа күрә дә, Габдуллаһ ибн Мәсгуд: «Сез «җиңү», дип Мәккәне җиңеп алуны уйлыйсыз, әмма без «җиңү» дип Һөдәйбиядә булган тынычлык килешүен атыйбыз!» — диде. Әл-Бохари, 2731, 2732.

Әлеге мисалларны ни өчен китердек? Безнең инануыбыз селкенми торган кыя кебек булырга тиеш — Аллаһ нәрсә генә кылмасын, сөеклеме ул Аңа, юкмы, кеше дигән зат өчен бу ничек кенә күренмәсен — бу гамәлләрнең барысында да бөек хикмәт бар! Ни өчен Иблис бар? — монда бик зур хикмәт яшеренгән! Ни өчен Җәһәннәм бар? — монда бик зур хикмәт яшеренгән...

Югарыда карап киткән «Һөдәйбия килешүе»нең нәтиҗәсен күргәч, Пәйгамбәребезнең ﷺ хикмәтенә таң калып була! Шаккатмалы! Аллаһның илчесе булуына да карамастан, ул бит бары тик кеше генә, Аллаһның колы. Ә Аллаһның хикмәте никадәр булырга тиеш?! Аллаһу әкбәр!

[1] Һөдәйбия — иске кое булган урынның атамасы, Мәккәдән 9 миль ераклыкта булган.

Темабызга әйләнеп кайтыйк: Аллаһның яшәештәге теләгендә Аның өчен сөекле булган әйберләр дә, шул ук вакытта, Ул яратмаган нәрсәләр дә булырга мөмкин, дидек.

Аллаһның шәригатькә бәйле булган шәргый теләге исә, бары тик Аңа сөекле, Ул разый булган нәрсәгә генә карый.

**Өченче аерма**

Аллаһ Тәгалә яшәештә теләгән бар нәрсә дә, һичшиксез, тормышка ашырга тиеш. Ә шәригатьтә теләгән нәрсәләр исә тормышка ашырга да, ашмаска да мөмкин.

Аллаһ Тәгалә шәригатьтә бар кешеләрнең дә мөселман булуын тели. Ләкин, кемдер мөселман, кемдер мөселман түгел. Аллаһ Тәгалә әйтте:

«**Аллаһ сезгә җиңеллек тели, авырлык теләми**» «Әл-Бәкара», 185.

Җәннәттән дә яхшы нинди җиңеллек булырга мөмкин? Җәһәннәмнән дә начар нинди авырлык булырга мөмкин? Аллаһ безнең өчен Җәннәт тели, ә Җәһәннәмне теләми! Ләкин, шуңа да карамастан, кешеләр барыбер Җәһәннәмгә керәчәк.

Шуңа күрә дә, Аллаһ шәригатьтә теләгән нәрсә булырга да, булмаска да мөмкин. Бу Аллаһның мәхлукатлары хакындагы гыйлемнең киңлеге һәм Үзенең хикмәтенең камиллеге белән бәйле.

Сер түгел, күпләрегездә сораулар тугандыр. Тәкъдир белән бәйле булган сорауларны галимнәребезнең, гыйлем эстәүче кардәшләребезнең хезмәтләре аша тирәннәнрәк таныша аласыз. Китабыбызның максаты — иман нигезләрен кыскача гына аңлату иде.

# Эчтэлек

**КЕРЕШ СҮЗ** ...... 3
Дин — ул Аллаһка гыйбадәт кылу кагыйдәләре җыелмасы ...... 5
Йөрәк гамәлләре — гыйбадәтнең асылы ...... 10
Йөрәк гамәлләренең төрләре ...... 12

**АЛЛАҺКА ИМАН** ...... 20
Аллаһны раббылыкта берләү (тәүхид әр-рубубия) ...... 22
Аллаһны исем–сыйфатларында берләү (тәүхид әл-әсмә үә әс-сыйфат) ...... 28
Аллаһны иләһлегендә берләү (тәүхид әл-улүһия) ...... 43
«Ләә иләәһә иллә-Лләһ» шәһадәте — тәүхид сүзләре ...... 48
«Ләә иләәһә иллә-Лләһ» шәһадәт сүзләренең шартлары ...... 50
Гыйбадәтнең әркәннәре ...... 56
Ширек, көферлек, монафикълык ...... 59

**ФӘРЕШТӘЛӘРГӘ ИМАН** ...... 70
Фәрештәләрнең төрләре ...... 73

**КИТАПЛАРГА ИМАН** ...... 76

**ПӘЙГАМБӘРЛӘРГӘ ИМАН** ...... 78
Гаять кыюлыкка ия булган расүлләр (Улүлгазм) ...... 80
Мөхәммәд ﷺ — барча җеннәр һәм кешеләр өчен дә Аллаһның илчесе ...... 81
Мөхәммәд ﷺ — соңгы пәйгамбәр ...... 84

**СОҢГЫ КӨНГӘ ИМАН КИТЕРҮ** ...... 87
Әлеге Сәгатьнең якынаю вакыты ...... 93
Үлем һәм кабердәге хәлләр ...... 95
Үлеп терелгәннән соң була торган вакыйгалар ...... 104

**ТӘКЪДИРНЕҢ ЯХШЫСЫНА ДА, НАЧАРЫНА ДА ИМАН КИТЕРҮ** ...... 117
Тәкъдиргә ышану түбәндәгедән гыйбарәт ...... 119
Искәрмә ...... 125